КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

**Т.Ш.ГЫЙЛАҖЕВ**

# МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ

Казан
2011

КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ҺӘМ ТАРИХЫ ФАКУЛЬТЕТЫ
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ ҺӘМ ТЕОРИЯСЕ КАФЕДРАСЫ

**Т.Ш.ГЫЙЛАҖЕВ**

# МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ
# (1891-1928)
## Тормыш юлы һәм иҗаты

*Уку-укыту әсбабы*

Казан (Идел буе) федераль университеты
2011

**УДК 821.512.145**
Печатается по решению Редакционно-издательского совета ФГАОУВПО
Казанского (Приволжского) федерального университета
Учебно-методического совета факультета татарской филологии и истории
Протокол № 5 от 16 февраля 2011 г.
заседания кафедры теории и истории татарской литературы
Протокол № 7 от 19 января 2011г.
Автор – составитель
доц., канд. филол. наук Т.Ш.Гилазов
Научный редактор
доктор филол. наук, профессор А.Г.Ахмадуллин
Рецензенты:
канд. филол. наук, доц. А.М.Закирзянов
канд. филол. наук, доц. М.И.Ибрагимов
Уку-укыту әсбабы Казан (Идел буе) федераль университетының татар әдәбияты тарихы һәм теориясе кафедрасының 2011 елның 19 гыйнварындагы утырышында расланды (7 номерлы беркетмә).
Татар филологиясе һәм тарихы факультеты Уку-методик советының 2011 елның 16 феврале карары нигезендә басыла (5 номерлы беркетмә).
Төзүчесе
филология фәннәре кандидаты, доцент Т.Ш.Гыйлаҗев
Фәнни мөхәррир
филология фәннәре докторы, профессор А.Г.Әхмәдуллин
Рецензентлар
филология фәннәре кандидаты, доцент Ә.М.Закирҗанов
филология фәннәре кандидаты, доцент М.И.Ибраһимов

Мирхәйдәр Фәйзи: Тормыш юлы һәм иҗаты / Уку-укыту әсбабы / Т.Ш.Гыйлаҗев. – Казан: Казан (Идел буе) федераль университеты, 2011. - 92 б.

«Мирхәйдәр Фәйзи: Тормыш юлы һәм иҗаты» уку-укыту әсбабы «XX гасыр башы татар әдәбияты тарихы» предметын үзләштерүче студентларга йөз тотып эшләнде. Классик язучы М.Фәйзи иҗатын монографик планда өйрәнү максаты куелган әсбапта әдипнең биографиясе, иҗат чорлары, әсәрләренең идея-эстетик үзенчәлекләре, милли сүз сәнгатенә алып килгән яңалыгы яктыртыла. Язучы иҗатына бәйле гыйльми-тәнкыйди материал, текстлар һәм әдәбият исемлеге урнаштырыла. Иҗади биремнәр, контроль эш сораулары, фәнни-тикшеренү эшләренең темалары тәкъдим ителә.

© Казанский университет, 2011
© Гилазов Т.Ш., 2011

## Кереш сүз

Әдип иҗатын монографик планда өйрәнгәндә, әдәби-тарихи чорның вәкиле буларак тәкъдим ителгән язучының рухи мирасын иҗтимагый-сәяси вакыйгалар һәм әдәби-мәдәни җирлек белән тыгыз бәйләнештә яктырту, аның художник һәм фикер иясе буларак үзенчәлеген ачу, әдәби осталыгын, шәхси сыйфатларын, тарихи-фәлсәфи һәм эстетик карашларын ачыклау максатлары куела.

«Мирхәйдәр Фәйзи: Тормыш юлы һәм иҗаты» уку-укыту методик әсбабы Казан (Идел буе) федераль университетындагы татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентларының «XX гасыр башы татар әдәбияты тарихы» курсыннан белемнәрен тирәнәйтү максатыннан эшләнде. Мәгълүм ки, теләк-омтылышларын, җирдә яшәү мәгънәсен халкына хезмәт итүгә багышланган М.Фәйзинең яңа дәвер татар әдәбиятында күренекле урыны бар. Ул романтизм кануннары һәм фольклор эстетикасына таянып иҗат ителгән пьесалары һәм классик «Галиябану» музыкаль драмасы белән милли драматургия тарихында «яңа агым, мәктәп» (Г.Ибраһимов) тудыра, профессиональ татар театрын үстерүгә үзеннән лаеклы өлеш кертә. М.Фәйзинең күпкырлы эшчәнлеге моның белән генә чикләнми: ул шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче, публицист, фольклорчы, җәмәгать эшлеклесе буларак танылу ала.

М.Фәйзи иҗатын җентекләп өйрәнү, язучының хосусый үзенчәлекләрен, иҗат йөзен ачу XX гасыр башы әдәби хәзинәсе хакында студентларның гомуми күзаллавын киңәйтергә, теоретик белемнәрен системалаштырырга, чор сүз сәнгатендәге яңа әдәби-мәдәни күренешләрне аңларга, шәрехләргә, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, төп сыйфатларын барлап, гомумиләштерүләр ясарга һәм, шуларга нигезләнеп, XX йөз башы әдәби яңарышының фәлсәфи нигезләрен табарга һәм татар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгеләргә ярдәм итә.

Соңгы елларда уку йортларында яңа белем-күнекмәләр бирүнең, әхлак-этик сыйфатлар, профессиональ осталык тәрбияләүнең яңа технологияләрен файдалану белән беррәттән, студентлар эшчәнлегенең мөстәкыйль формаларына, ысул-юлларына игътибар артты. Бу методик әсбапта, классик университетларның өстенлеге булган фундаменталь

филологик белем бирү максаты саклану белән бергә, вузларга бүгенге көн ихтыяҗы, заман куйган таләпләр дә күз алдында тотылды.

Уку-укыту методик ярдәмлегенең төзелешен М.Фәйзи иҗатының студентлар тарафыннан мөстәкыйль үзләштерелүенә юнәлгәнлек билгеләде. Язучы иҗатын монографик өйрәнүне өлешләргә бүлеп оештыру мөмкинлегеннән, әдип рухи мирасының идея-эстетик үзенчәлекләреннән, казанышларыннан чыгып, әсбап үз эчендә шартлы рәвештә берничә бүлекне берләштерә. Язучының һәр иҗат тармагын комплекслы гыйльми күзаллау максатыннан, бүлекләрдә темага кагылышлы гыйльми-тәнкыйди материал лекцияләр формасында урнаштырылды, аның буенча сораулар һәм контроль эш темалары бирелде. Гамәли дәрес темасы билгеләнеп, аңа әзерләнү өчен, әдәби текстлар һәм чыганаклар, фәнни-методик әдәбият исемлеге тәкъдим ителде. М.Фәйзинең тормыш сукмакларын һәм иҗат юлын тулаем өйрәнеп чыкканнан соң, белем-күнекмәләрне системалаштыру, материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү өчен, тест биремнәре урын алды. Белем-мәгълүмат үзләштерү, профессиональ компетенцияләр формалаштыру процессы студентларның гыйльми эзләнүләре белән үрелеп баруын истә тотып, иң соңгы өлештә төрле баскыч фәнни-тикшеренү эшләренең темалары тәкъдим ителде.

## Әдипнең тормыш юлы һәм иҗатының өйрәнелү тарихы

Матур төсләргә кереп, һәрберсе серле һәм үзенчә җемелдәгән әдипләр йолдызлыгында М.Фәйзинең дә кабатланмас урыны бар. Романтик табигатьле, «ямь бәйләме» – авылын үз күңел бакчасына кәгъбә иткән, кешеләр рухи дөньясында һәм үзара мөнәсәбәтендә дә матурлык, табигатьтә гүзәллек эзләгән М.Фәйзи замандашларыннан холкы белән дә, тыйнак яшәеше белән дә, әдәбият һәм мәдәният дөньясында танылу-бәяләнү җәһәтеннән дә аерыла. Нечкә күңелле, моңлы, шигъри җанлы, әйләнә-тирәгә, дуслар сайлауга талымлы язучы татар әдәбиятында шактый соңарып барлыкка килгән драматургияне сайлый һәм аны яңа сыйфатлар белән баетырлык әсәрләр тудыра. Аның иҗатына жанр төрлелеге дә хас: ул – комедия, мелодрама, музыкаль драма, музыкаль комедия, хикәя, нәсер, шигырь, поэма, публицистик мәкалә, көндәлекләр, тәнкыйди язмалар авторы да.

М.Фәйзи (Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзуллин) 1891 елның 19 октябрендә (яңа стиль белән 1 ноябрьдә) элекке Оренбург губернасы Орск өязенең Күкшел авылында туа. Атасы Мостафа чыгышы белән Чистай якларыннан. Ул, бәхет эзләп, Оренбург якларына килеп чыга һәм миллионер Хөсәеневләрнең Күкшел утарына эшкә керә. Оренбург янындагы Каргалы авылыннан башкорт кызы Зәйнәпкә өйләнеп, 8 ир бала һәм 3 кыз үстерәләр. Утарда әүвәл приказчик, аннан управляющий булып озак еллар эшләгәннән соң, Орск шәһәрендә йорт сатып ала һәм 1907 елдан Фәйзуллиннар гаиләсе шунда яши башлый. Балаларыннан берничәсе, шәһәрдән ерак түгел Җүнәй дигән бер авылда йорт салып, иген игәргә керешәләр.

Мирхәйдәр гаиләдә унберенче – төпчек бала булып дөньяга килә, балачагын Күкшел, Җүнәй авылларында, Орск шәһәрендә җитеш, мул тормышта, табигать кочагында үткәрә. Заманына күрә укымышлы һәм ачык фикерле булган әнисе Зәйнәп Мирхәйдәрдә укуга-белемгә мәхәббәт тәрбияли. Ике ел абыстайга йөреп, апасы һәм абыйсы булышлыгы белән дә ул укырга-язарга өйрәнә. 1902-1904 елларда Мирхәйдәр Орск шәһәрендәге Габдулла хәзрәт Мәгази мәдрәсәсендә башта Фазылҗан хәлфәдән, соңрак Мәгазинең яңа салынган мәдрәсә бинасында Зыя хәлфәдән белем ала. Дини бәйрәмнәрдә утарга кайтып йөри. Туган

ягының гүзәл табигатенә, татар халкының милли йолаларына, гореф-гадәтләренә мәхәббәт шушы елларда тәрбияләнә.

Нечкә күңелле, «иркә булып, матур, бәхетле тормыш эчендә үскән», «матурлыкка, ямьнәргә бай булган утар»да яшәгән Мирхәйдәр мәдрәсә тормышына күнегә алмый, тора-бара укуга дәрте сүрелә. Мәдрәсәдәге мохиттән тыш, уку-укыту программасы, ысул-методлары да шәкертне канәгатьләндермәгән булса кирәк. Салкын акыл, коры истә калдыруга, логик фикерләүгә корылган предметлар Мирхәйдәрнең җанына җим бирмәү сәбәпле, ул, рухи азык эзләп, газета-журналларга тартыла. Мәгълүм булганча, 1905 елгы Беренче рус инкыйлабының шифалы җилләре тәэсирендә татар халкының рухи-мәдәни күтәрелеше өчен мөмкинлекләр ачыла: сүз иреге игълан ителеп, татарлар оешып яшәгән төбәкләрдә газета-журналлар нәшер ителә башлый, матбагалар челтәре киңәеп китеп, китаплар басыла, милли профессиональ театр барлыкка килә, татар әдәбияты яңару юлына баса.

Иҗтимагый активлык барлыкка килеп, милли үзаң формалашкан шартларда татар зыялылары милләтнең бүгенге хәле һәм киләчәге хакында уйлана башлыйлар. Бу гамьнәрнең бер өлеше милли мәгарифне үзгәртү, үстерү юллары белән бәйләнгән була. Яшүсмер егетне, иң беренче нәүбәттә, газета-журнал битләрендә мәдрәсә тормышын яктырткан язмалар кызыксындыра. Алардагы үз уйлануларына авраздаш фикерләр М.Фәйзидә данлыклы уку йортларында белем алу теләген тагын да ныгыта. Аннан соң вакытлы матбугат битләрендә яңа язылган шигырьләргә, хикәяләргә зур мәйдан бирелү сәбәпле, укучыларга әдәби хәрәкәт белән танышып бару мөмкинлеге туа. Нәкъ шушы язмаларда романтик табигатьле Мирхәйдәр үз күңеленә теләктәшлек таба, алардан алынган тәэсирләр егеттә иҗатка дәрт уята. Ул бу халәтне көндәлегенә болай дип теркәп куйган: «Бу кыш мин мөхәррир булырга һәвәсләнә башладым. «Татар туе» исеме белән бер вакыйгадан алып язылган пьесамны җиңгиләргә укып, аларны хәйран да калдырдым. Бәетләр, шигырьләр язуга бирелеп киттем» [Фәйзи, 1957; 372]. Язучының тормыш һәм иҗат юлын монографик планда өйрәнгән Б.Камал бу елларның әһәмиятен шулай бәяли: «Яшь Мирхәйдәрнең тирә-юньгә, тормышка күзе ачыла башлау 1905-1907 елгы рус революциясе тудырган конкрет иҗтимагый шартларга бәйле» [Камалов, 1987; 11]. Шушы елларда

М.Фәйзи белем алуны Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Шәкертлек чорында әдәбият белән кызыксынуы тагын да көчәя. Татар язучылары әсәрләреннән тыш, төрек һәм фарсы телендә язылган китаплар укый. Шул ук вакытта русча өйрәнүе, рус әдәбияты һәм театры белән кызыксынуы билгеле.

Шунысы мәгълүм, «Хөсәния» мәдрәсәсенең рухы булачак язучыга уңай тәэсир итә. Ул монда үзен иркенрәк хис итә, активлыгы арта төшә, замана җилләре аның тирәлеккә, шул исәптән мәдрәсәнең уку-укыту системасына, тормышка тәнкыйди мөнәсәбәтен формалаштыра. М.Фәйзинең Оренбургта нәшер ителгән “Чүкеч” журналының 1908 елның 1 гыйнвар санында басылган беренче мәкаләсе мәдрәсә мөгалимнәренең эшчәнлегендә урын алган гаделсез эш-гамәлләрне тәнкыйть итә. Шушы вакыйгадан соң язучы чорның актуаль иҗтимагый-милли мәсьәләләрен яктырткан язмаларын «Чүкеч», «Әльислах», «Идел», «Бәянелхак», «Вакыт», «Шура», «Аң», «Сөембикә» журнал-газеталарында даими бастыра башлый.

Кызганыч ки, сәламәтлеге начар булу сәбәпле, аңа Оренбургта ике елдан артык укырга туры килми. Әмма белемгә омтылган үсмер күңел төшенкелегенә бирелми, үзлегеннән төрек әдәбияты, рус классикасы, татар сүз сәнгате белән танышуын дәвам иттерә. Абыйлары алдырткан газета-журналларны даими укып бара. Шушы шартларда әдәби иҗатка килүнең тәүге адымнарын ясый. Рус театрында караган «Два Ивана Петровича» исемле комедиягә ияреп, «Ике Хәсән» дигән пьеса яза. Кулъязмасы сакланмау сәбәпле, аның идея-эстетик үзенчәлекләре хакында сүз алып барып булмый.

М.Фәйзи гомеренең күп өлешен Орск шәһәрендә үткәрә. 1911 елда булачак әдип тормышында аның яшәү рәвешенә зур йогынты ясаган вакыйгалар була. Казан Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган И.Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендә Оренбург шәһәрендә оешкан труппа татар халкының мәдәни тормышында танылып өлгерә. Аның эшчәнлеге үрнәгендә Орски яшьләре дә тамаша оештыру теләге белән янып йөри башлыйлар. Ә бу әдәби-мәдәни хәрәкәтне башлап йөрүчеләрнең берсе М.Фәйзи була. Бу көннәрдә «Сәйяр» труппасы Орск шәһәре клубында спектакль уйнап, татар сәхнәсендә беренче адымнарын ясаган яшьләр күңелен рухландырып җибәрә. Труппаның уеннарында

җирле һәвәскәрләр дә катнаша. Профессиональ актерлар белән очрашу, алар ярдәмендә һөнәри осталык мәктәбе үтү М.Фәйзинең күңелендә мәңгелеккә уелып кала. Орск шәһәренең мәдәни хәятындагы шушы вакыйга язучының иҗат юнәлешен, яшәү мәгънәсен билгели, әдәбият-сәнгать, театр сәнгате аның гомерлек юлдашына әверелә. Әлеге тарихи мизгелләрдән соң Орск шәһәренең аңлы, укымышлы, кыю яшьләре бер-бер артлы «Югалган хатын», «Түләшү», «Бүләк өчен», «Кияү эзләү» һ.б. пьесаларны сәхнәләштерә. М.Фәйзи шәһәрнең әдәби-мәдәни тормышында кайный башлый, татарлар арасында милли әдәбият һәм сәнгатьне таратучыга әверелә һәм тыйнак, ярдәмчел, кешелекле, сабыр холыклы егет татар зыялыларының, яшьләрнең тирән ихтирамын казана. Оештыручы, режиссер, гример, актерлык эшчәнлегеннән тыш бу елларда ул шагыйрь һәм тәрҗемәче буларак та танылa.

Бу вакытта М.Фәйзи, бертуган абыйсы Мортаза Фәйзуллинның мануфактура кибетендә кассир вазифасын башкару белән бергә, язучылык эшенә ныклап керешә. 1911-1913 еллар – аның әдәби эшчәнлегенең беренче тәҗрибәләр ясаган башлангыч чоры. «Яшьләр алдатмыйлар» (1911) комедиясен драматургның оригиналь пьесаларыннан беренчесе итеп санарга кирәк. Аның артыннан ук иптәше Габдулла Әмиров белән бергәлектә «Бизәнү» (1912) дигән көлке әсәре иҗат ителә. 1911-1912 елларда язылган «Ватылган көзге алдында» исемле бер пәрдәлек комедиясе әдипнең архивында кульязма хәлендә саклана. Драматургның каләм сынау дәверендә ясалган иҗат күнекмәләре «Кызганыч» (1913), «Тәкъдирнең шаяруы» (1913) мелодрамаларында тулы канлы драматик характерлар тудыруга, көчле конфликтлар оештыруга җирлек-нигез әзерли. Лирик әсәрләр авторы М.Фәйзинең күңелендә халык шагыйре Г.Тукай белән очрашу теләге уяна. Бу нияте якыннарында яклау тапкан яшь шагыйрь 1912 елның май аенда татар-төрки халыкларның фән, әдәби-мәдәни үзәге булган Казанга юл тота. Беренче сәфәрләре белән чагыштырганда, М.Фәйзи монысында иҗат кешесе буларак, дөньяга башка күз белән карый. Сәяхәт вакытында аның күңелендә татар халкының ерак тарихындагы шанлы вакыйгалар яңара, Идел елгасының зурлыгы, матурлыгы аны әсир итә. Г.Тукай белән очрашу насыйп булмаса да, чал Казан шәһәре, аның тарихи урыннары, борынгы һәйкәлләре, әдәби-мәдәни мохите М.Фәйзи күңелендә җуелмас эз калдыра. Беренчедән,

М.Фәйзинең 1912 елда Казан типографиясендә басылып чыккан «Милли шигырьләр» исемле тәүге җыентыгы шушы сәяхәтнең кыйммәтле истәлеге булып тора. Аннан соң «Яшь күңел» (1913) дигән яңа китабын нәшер итү өчен юллар ачыла. Казанга сәяхәт М.Фәйзинең әдәби-эстетик карашларын яңарта, әдәбият-сәнгатьнең татар халкы язмышындагы роле хакында тирәнрәк уйлануларга этәреп, аның иҗат активлыгын арттыра.

Гомеренең иң кызыклы һәм нәтиҗәле өлешен М.Фәйзи милли-мәдәни тормыш кайнап торган Орск шәһәрендә үткәрсә дә, аның күңеле һәрдаим авылга тартыла. Аңа ата-бабалары туып-үскән, я булмаса бай нәселле туганнары, кан-кардәшләре төпләнеп, ныклы тормышта гомер кичергән Оренбург, Киров өлкәләре, Татарстан һәм Башкортстан республикаларының төрле авылларында яшәргә, тормыш тәҗрибәсе тупларга туры килә. Аерым алганда, Җүнәй, Дүрткүл, Шода, Юлык авылларының сихри һәм гүзәл табигате, алар тирәсендә бормаланып-бормаланып аккан елгалары, саф сулы чишмәләре, иң әһәмиятлесе авыл халкының яшәеше, гореф-гадәтләре, йолалары, физик һәм рухи яктан бай, матур күңелле яшьләр дөньясы, халык иҗаты М.Фәйзигә җан азыгы, әдәби эшчәнлегенә саекмас материал бирә. «Җүнәйгә кайтып йөри башлагач инде, - дип яза Л.Хәмидуллин, - ул авыл яшьләреннән тартынмый башлый. Кыскасы, Җүнәйнең Хәлил, Галиябанулары, Дүрткүлнең яки Шоданың Мәрьямбану, Хәсән, Исмәгыйльләре белән якыннан аралаша» [Хәмидуллин, 2002; 112]. Шул рәвешле, аның әдәби эшчәнлегендә зур сыйфади үзгәрешне хәбәр итеп, атаклы «Галиябану» музыкаль драмасы язылуга әзерлек баскычы булган «Авыл бәйрәме» (1915) комедиясе иҗат ителә. Халык яшәешенең матур бизәкләренә соклану белән бергә, 1914 елгы сугыш афәтен, физик һәм рухи гариплекләрне, гади халык җилкәсенә төшкән авырлыкларны да күреп, М.Фәйзинең җаны сыкрана, якты күңеле караңгылана. Аның сизгер җаны сугыш тудырган иҗтимагый гаделсезлекләрне, социаль контрастларны, канкойгыч сугышның империалистик характерын тоемлый. 1916 елның июль аенда көндәлегенә ул болай дип язып куйган: «Уйлап торсам, җаннарым әрни; сугыш тормышны бәрбад итте (җимерде – Г.Т.). Никадәр ямьле, яшь егетләр әрәм булды, була. Никадәр яшь өметләр илләреннән, сөйгән ярларыннан җода булып читтә тилмереп михнәт чигәләр. Туганнар бер-берсен үтерә, кан коя. Элек җан кыйган кешене себер җибәрәләр иде,

хәзер кешене күп үтергән саен мактап медальләр тагалар. Кан, күз яше, аһ-зар, бөлгенлек, ятимнәр, ачлар, мәкрухлар, каберләр белән дөнья тула. Миллионнарча кешеләр корбан булалар. Ни өчен?» [Фәйзи, 1957; 386].

М.Фәйзи авылда яшәгән көннәренең бер генә мизгелен дә файдасыз үткәрми. Җырга-моңга гашыйк егет яшьләрнең кичке уеннарында, бәйрәм-мәҗлесләрендә, печән чапканда, иген сукканда я булмаса солдатка алынган никрутлардан ишеткән җырларны, такмакларны, бәетләрне күңел дәфтәренә теркәп бара, үз күңел дөньясын гамьле уйлар, матур типлар белән баета. Шундый кичәләрнең берсендә «күңеле зур куаныч белән бәйрәм иткән» Мирхәйдәр үз тәэсирләрен гыйсъяннарча менә ничек язып куйган: «Урамда «Моң-зар» көенә Галимулла абзый белән Гатиятнең алмашлап-берсе калынрак, берсе нечкәрәк тавыштан җырлаулары каршында үз-үземнән югалдым. Бу күренеш каршында оҗмахларын бер тиенгә сатып җибәрү миңа бернәрсә дә түгел. Әй, ходаем, мине җәннәтең белән хур итмә! Җир яменнән аерма!» [Фәйзи, 1957; 383]. Шушы елларда ул бар көчен, тырышлыгын куеп, чын күңелен биреп, халык җырларын җыя, аларны фәнни яктан шәрехләүнең тәүге адымнарын ясап, тематик, жанр ягыннан төркемләп, «Халык җырлары» исеме астында җыентык итеп әзерли һәм фольклорчы буларак танылa. «Бу ел «Халык җырлары» исеме белән күңелемнең тәсбихы, зикере, кәгъбәсе, юанычы булган ил җырларын, төрле бүлемнәргә бүлеп, күп төрләргә аерып бер мәҗмуга тәртип иттем» [Фәйзи, 1957; 385], - дип яза ул. Әйтергә кирәк, бу хезмәт драматургка әдәби осталыкка ирешү мәктәбе дә була.

1916 елның җәй айларында драматург поезд, пароход юллары аша Малмыж өязенең Шода авылында яшәүче бертуган абыйсы Сәетгәрәйләргә сәфәр кыла. 51 көнгә сузылган сәфәренең юлъязмасы бик җентекләп көндәлек дәфтәрләренә теркәлгән. Юлда озакка сузылган сугышның бәла-казалары, бәхетсезлекләре М.Фәйзинең күңелен хәвефләндерсә дә, Малмыж, Шода авылына килеп урнашкач, аның бәргәләнгән җаны тынычланып кала. Тормышка гашыйк драматург табигать, гади халык яшәеше бизәкләрен, халык иҗаты җәүһәрләрен күңеленә сеңдерә. Кире кайтканда, Казан шәһәрендә була, аерым зыялылар белән очраша. Орскига кайтып ирешкәч, бер көй тарихы буларак һәм Казан ягы авылларында алынган тәэсирләр нәтиҗәсендә дә «Галиябану» исемле драма язу уена килә: «Казан ягы авылларында йөреп

кайттым, бу яктагы авылларда күргән матур күренешләрдән файдаланып «Сәгадәтбану» («Галиябану») исемле пьеса язу уе туды. Көннәрем шул хакта мәшгуль булып уза башлады» [Фәйзи, 1957; 391]. 1916 елның елның декабрендә драматург аны тәмамлый һәм 1917 ел башында Оренбургка Вәли Мортазин-Иманскийга җибәрә. Аның киңәшләре белән пьесаны камилләштерә һәм исемен «Галиябану» дип үзгәртә. Шушы көннән классик «Галиябану» музыкаль драмасының гаять дәрәҗәдә бай сәхнә тарихы башлана.

1917 елгы Февраль революциясе, аннан соң Октябрь борылышы Мирхәйдәр Фәйзинең моңа кадәр җай гына аккан тормышында кыенлыклар, каршылыклар тудыра. Дөрес, ул Россиядә хөкем сөргән чуалышларга, җәмгыятьнең астын өскә китергән тарихи вакыйгаларга 1917 елның март аенда язылган көндәлек битләрендә уңай мөнәсәбәт белдергән: «Бөек ихтилал хәбәре белән рухланып, җилкенеп киттек. Падишаһ очкан ди, малай. Илә җәһәннәмә зөмәра! Оч, шул кирәк иде <...> Көннән-көн революция ныгый. Гакыл ирешмәслек әллә ниләр булып бетте. Алган юлыма бик якын торган бу үзгәреш мине дәртләндереп җибәрде. Без җиңгән кебек, «алар» җиңелгән кебек булып китте. Бу үзгәреш минем теләгемә таба бара; идеал йолдызымның балкуына әллә кемнәр дә ярдәм итешә кебек тоелды. Сәясәт белән эшем булмаса да, бу ел, бикле яткан серләремне иркәләп, әллә нинди матур бәхетләр белән сөенче алды. Көтәм» [Фәйзи, 1957; 393]. Бу юллар укучыда күпмедер күләмдә шик-шөбһә уятырга мөмкин, чөнки каләме белән халкына хезмәт итү юлы сайлаган драматург әдәби-мәдәни хәяттә кайнап яшәсә дә, заманының иҗтимагый-сәяси мәсьәләләреннән, социаль үзгәрешләреннән читтә тора. Гади –гадәти күренешләрдә матурлык эзләгән М.Фәйзинең яшәү рәвеше дә, тормыш фәлсәфәсе дә, муллыкта гомер кичергән туганнар даирәсе дә, дини тәрбиясе дә инкыйлаби вакыйгаларга һәм илдә башланып киткән гражданнар сугышына тиз арада ачык бәя бирерлек җирлек әзерләми, нигез бирми, аның «фикер ачылу тарихы» шактый озакка сузыла. Көндәлегенең соңгы битләрендә урын алган фактлар, бәя-хөкемнәр дә шушы икеләнүне ныгыта. Совет власте урнашып, үз көчен ныгыткан һәм җәмгыятьтә кайбер уңай үзгәрешләр дә күзәтелгән елларда М.Фәйзи еллар буена язып киленгән көндәлеген кулына ала, андагы аерым фактларга мөнәсәбәтен, уй-гамьнәрен чор идеологиясенә

яраклаштырып үзгәртә, кайбер битләрен ертып алып, бөтенләй юкка чыгара: «Көндәлек дәфтәремне карап чыгарга керештем. Йолам, йолкам, цензурлыйм. Элек бик Аллага җегенүчән булганмын. Гражданский сугышлар вакытында үтә битарафлык саклаганмын. Сәясәттә надан булганмын. Аннан соң үтә вак нәрсәләр язып беткәнмен. Шулай ук кешеләргә белдертмәстәй нәрсәләр язылып беткән. Хәзер шуларны ачуланып-ачуланып ертып алам. Хәзерге нык динсезләнгән сәясәттән күзем ачылган заманымда алар бик ачуымны китерәләр. Фикерем ачылу тарихын югалтмас өчен генә, көндәлегемне бөтенләй югалтмый калдырам» [Фәйзи, 1957; 459].

М.Фәйзи 1917 елда берара «Галиябану» пьесасын сәхнәләштерү белән шөгыльләнеп алгач, авылга китүне мәгъкуль күрә: «Авылга китәм инде мин. Революционер булу шәрәфенә лаек түгел мин. Анлык көч тә юк, коры куык, камыр батыр булып йөреп хикмәт чыкмый. Эшләүчеләргә комачаулап йөргәнче, <...> күңелем кәгъбәсе булган авылга юнәлим дә күңел көчемне баетыйм: шул юл белән хезмәт итим халкыма» [Фәйзи, 1957; 393]. Чыннан да, ул бу елларда үз көчен авыл халкын агартуга, мәгърифәт нуры чәчүгә багышлый, әдәби эшчәнлеген тагын да активлаштыра. Дөрес, эзләнүчән, тынгысыз иҗат кешесе буларак М.Фәйзи авылда гына яши алмый, ул Орск шәһәрендә еш булып, аның әдәби мәдәни тормышында актив катнаша, чөнки гражданнар сугышы бәла-казаларына карамыйча, тормыш үз кануннары буенча хәрәкәт итә. Авыл тормышын уңай якка үзгәртүгә нисбәтле үз идеалын гәүдәләндергән «Урал суы буенда» (1918) пьесасын, «Бакырган» дини-әхлакый китабындагы «Ярты алма» хикәясен файдаланып, «Ярты алма», «Чүмечбаш» комедияләрен яза.

Шушы болгавыр заманда М.Фәйзи Оренбург губернасына караган Юлык авылына земство карамагындагы китапханә-уку залының мөдире итеп җибәрелә. 1919-1921 елларны үз эченә алган вакыт аралыгы язучы тормышында аерым урын били. Авылда М.Фәйзинең киңкырлы әдәби-мәдәни эшчәнлеге өчен мөмкинлекләр ачыла: авыл халкында китапка мәхәббәт уяту, үзешчән сәнгатьне оештыру, аның эшен җайга салу, авыл яшьләрен әдәбият-сәнгатькә тарту, активлаштыру һ.б. Шушы елларда әле кызыллар, әле аклар кулына күчеп йөргән Юлык авылында язучының тарихи вакыйгаларга үз позициясе формалаша. Юлык авылы тормышы

әдипкә бай материал бирә, әдәби әсәрләрендә тасвирланачак вакыйгаларның шаһите була, әдәби геройларының прототиплары белән аралаша, таныша. М.Фәйзинең башка әсәрләре белән чагыштырганда, иҗтимагый-социаль яңгырашлы «Кызыл йолдыз» (1923) нәкъ менә Юлык авылы материалында иҗат итела.

Иҗтимагый-сәяси яктан чыныгу гына түгел, М.Фәйзи рухи яктан байый, әдәби-эстетик карашлары тирәнәя, кызыксыну даирәсе киңәя. Һәм әйтергә кирәк, әдип яңа җәмгыятькә, аның яшәү нормаларына, директив күрсәтмәләренә яраклашырга да мәҗбүр була, шушы зарурият алдында кала. Ул Көнчыгыш һәм Көнбатыш  әдәбиятларын укый, алардагы идея-эстетик казанышларны үзләштерә: И.С.Никитин, С.Я.Надсон, В.Гюго, В.Шекспир, А.М.Горький һ.б.ларның әсәрләрен укый.

1920-1924 еллар – М.Фәйзи әдәби эшчәнлегенең иң актив һәм нәтиҗәле еллары. Алда исемнәре саналган әсәрләрдән тыш, «Асылъяр» (1918-1920), «Ак калфак» (1922-1923), «Адашкан күңел» (1922-1923), шул чорның имансызлык, дәһрилек шаукымын гәүдәләндергән атеистик эчтәлекле, антиклерикаль тенденцияле «Кәкре каен» (1923), заман сулышын чагылдырган «Коммунага» (1924) бер пәрдәлек агитпьесалары иҗат итела.

Юлыктан киткәч, кантон үзәге Темәстә М.Фәйзи урындагы театрга җитәкчелек итә, бер үк вакытта «Кызыл Урал» газетасы хәзмәткәре булып эшли, әдәби түгәрәк оештыра. 1923 елның җәен М.Фәйзи хәзерге Балтач районының  Шода авылында үткәрә. Казанга килеп, Тукай урамындагы Үзәк Шәрекъ китапханәсенә эшкә керә. Язучылардан Г.Ибраһимов, бигрәк тә Г.Кутуй белән җылы, дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыра. Берничә айдан табиблар кушуы буенча Казаннан китәргә мәҗбүр була. Драматург туган якларына кайтканда, киләчәктә герой шагыйрь булачак М.Җәлил белән таныша. М.Фәйзи Казаннан китүне романтикларча тирән драматизм белән авыр кичерә: «Хуш, Казан! Мин үзем генә кайтып киттем, күңелем синдә калды. Ул сиңа мәңгелек бүләк булсын. Казан! Мин моңарчы гел алга атладым. Ләкин синдә тора алмый китәргә мәҗбүр булуны артка китү дип атыйм. Мин кире Урал таулары белән өретелеп ятып калырга, ят халыклар арасына, туган илем булса да, күңелем иле булмаган җирләргә ташланам. Мин мәгънән үлдем. Теләкләремә җитә алмый чигендем. Соңгы көннәрем

Татарстан өстендә сайрап очкан күңелемнең авазлары белән генә юанып узар» [Фәйзи, 1957; 443].

Иҗат иреге чикләнеп, матур әдәбият сәяси һәм идеологик кысаларга кертелгән саен, М.Фәйзинең иҗат шәме сүнә, аның уты зәгыйфьләнә. Кешелек җәмгыятен хәрәкәт иттерүдә, буыннар алмашында мәхәббәтнең һәм матурлыкның көченә ихлас ышанган драматург социаль заказ буенча сыйнфый көрәш темаларын, күңел кәгъбәсе булган авылдагы социалистик үзгәртеп кору хәрәкәтен сурәтләүгә күчә алмый.

Баймакта эшчеләр арасындагы тормышка, яңа мохиткә авыр күнегә. Рус, татар, башкорт яшьләре белән аралашу булыштыргаласа да, көннәре бер төслерәк ага башлый. Китапханәдә эшнең күплеге аның бөтен көчен һәм вакытын алу аркасында, иҗаты бөтенләй тукталып кала, сәламәтлеге какшый. Бу еллар шәхси тормышы хакында менә нәрсә яза ул: «Китапханәдә эш күп. Нык эшлим. Арыйм. Урынымнан чыгарга теләп заявление биргән идем, райком үзе, Кырымга җибәреп ял иттерергә булып, калдырды. Бер дә әдиплек эшемне алып бара алмау вакыт-вакыт бик эчемне пошыра. Бөтенләй урында хезмәтне ташласам, каләм хакы белән генә яхшы торып булмас, хезмәт итсәң, язарлык көч калмый. Нишләргә инде» [Фәйзи, 1957; 447]. Көндәлектә әйтелгәнчә, беркадәр ял иттереп кайтару максатыннан, Тау эшләре профсоюзы тарафыннан аңа Кырымга юллама бирелә. Мәскәү аша кителү сәбәпле, М.Фәйзи дә һәрбер совет баласы кебек Кызыл мәйданда була, Мавзолейда пролетариат юлбашчысы В.И.Ленинны күреп, зур горурлану хисләре кичерә. Кара диңгез, Кырымның шифалы һавасы, табигатенең сихри гүзәллеге, карлы түбәләре күккә ашкан тауларының могҗизаи матурлыгы М.Фәйзинең күңеленә хуш килә, җанын дәвалый. Язучы гомер юлының соңгы айлары Баймак шәһәрендә үтә. Йөрәгенең зәгыйфьлеге белән һәрдаим килешеп яшәргә мәҗбүр булган М.Фәйзигә башка авырулар да өстәлә. 1928 елның 9 июлендә талантлы әдип туберкулез авыруыннан вафат була. Ул гражданнар сугышы каһарманнары каберлегенә җирләнә.

* * *

М.Фәйзинең тормыш сукмаклары һәм иҗатының өйрәнелү тарихы башка әдипләрнеке белән чагыштырганда артык бай түгел. XX йөз башында аның шигъри иҗатын, я булмаса драма әсәрләрен әдәби-гыйльми фикернең алкышлап алуы күзәтелми, алар киң яңгыраш тапмый.

Мәсәлән, чагыштыру өчен Г.Исхакыйның бер әсәренә генә әдәби тәнкыйтьнең мөнәсәбәтен мисалга китерик. Аның «Мөгаллимә» пьесасы 1913 елда языла. (Ә бу вакытта М.Фәйзи драматургиядә талантлы гына каләм белән язылган пьесалар бирә башлый). Г.Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасына дистәдән артык мәкалә һәм рецензияләр басылып чыга. Ә М.Фәйзинең пьесалары тәнкыйтьчеләр, әдипләр игътибарыннан читтә кала. Бары тик «Гыйшык» шигыре матбугат битләрендә басылып чыккач, аңа С.Рәмиев тарафыннан тәнкыйть язылуын М.Фәйзи үзенең «Көндәлек дәфтәрләре»нә теркәп калдырган. Ә бит язучының «Галиябану» музыкаль драмасы шушы еллар татар драматургиясендә яңа юнәлеш, «яңа мәктәп» ачып җибәрә. Халык, тамашачылар тарафыннан хуплап каршы алына, әмма аның драма төренә алып килгән яңалыгын, идея-эстетик кыйммәтен бәяләгән, әдип осталыгын тулы ачкан күләмле язмалар вакытлы матбугат битләрендә күренми. Монда, күрәсең, чорның үзенчәлеге, кырыслыгы, иҗтимагый-сәяси, мәдәни алмашынулар мәгълүм роль уйнагандыр. Октябрь борылышыннан соң М.Фәйзи иҗатын, аеруча драматургия төрендә эшчәнлеген гыйльми күзаллауда җанлану күзәтелә. «Галиябану» пьесасының «Казанда гына ел буенча унбиш-егерме мәртәбә уйналу» фактына нигезләнеп, Татарстан Җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты 1922 елда «Галиябану»ны аерым китап итеп бастырып чыгара, аңа Г.Ибраһимов «Галиябану» хакында бер-ике сүз» дигән исем астында сүз башы урнаштыра. Пьесага И.Рәминең тәнкыйть язуы билгеле.

Г.Ибраһимов музыкаль драманы яңа иҗтимагый-сәяси, икътисади шартлар тәэсирендә әдәбият-сәнгать мәйданында күзәтелә башлаган тенденцияләр яктылыгында шәрехли. Совет әдәбияты эчтәлегенең төп категориясе буларак тәкъдим ителгән сыйнфыйлык ноктасыннан якын килеп, «Галиябану» әсәрендә авылның төрле социаль катлау кешеләре арасында сыйнфый каршылыкларның сурәтләнүен драматургның татар әдәбиятына алып килгән тема яңалыгы төсендә бәяли: «Тормышның һәр катлавында, һәр дәверендә төрле төстә, төрле зәминдә (җирлектә – Г.Т.) була килгән сыйнфый каршылыклар, бу каршылыкның мәхәббәт, гыйшык тотуларында да, гаилә төзү эшләрендә үзен китереп чыгаруы ачык күрсәтелә» [Ибраһимов, 1978; 302]. Шулай ук «Галиябану»ның иҗат ысулы да тәнкыйтьче тарафыннан реализм юнәлеше белән генә чикләнә.

Язма әдәбият белеме өчен драманың сәнгати үзенчәлекләрен, драматург мөрәҗәгать иткән алымнарны һәм яңа детальләрне ассызыклавы белән әһәмиятле. Бу яктан пьесада музыканың, халык җырларының яңа идея-эстетик максатларда кулланылышы ассызыклана. «Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны бер иттифакый зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә кыйлып кертүедер. Буны «Галиябану» башлап җибәрде» [Ибраһимов, 1978; 303], – дип яза Г.Ибраһимов.

Мәгълүм булганча, Г.Сәгъдинең 1926 елда XX йөз башы әдәби хәрәкәтен монографик планда яктырткан «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәте дөнья күрә. Галим драматургка махсус бер бүлек багышлый. М.Фәйзинең иҗаты 1910 еллар татар драматургиясе белән тыгыз бәйләнештә шәрехләнә. Хезмәт авторы язучының «Авыл бәйрәме» (1915), «Галиябану» (1916), «Асылъяр» (1918-1920) пьесаларына үз игътибарын юнәлтә. XX гасыр башы татар әдәбияты тарихын язганда, чор әдәби тәнкыйте, теоретик фикере күзәтүләрен киң файдаланган Г.Сәгъди М.Фәйзинең милли сүз сәнгатендә урынын билгеләгәндә дә, Г.Ибраһимовның «Галиябану» әсәре турындагы бәя-хөкемнәренә таяна, аларны иҗади үстерә: «Фәйзинең «Авыл бәйрәме»ндә сыйнфый каршылык ачылмастан, тик крестьян яшьләренең яшьлек дулкыннары, яшүсмерлек кызыклары, үзләренчә, яшьләрчә яшәргә омтылулары, кыскача әйткәндә, анда тик яшьлек, картлык көрәше тасвир ителгән иде. «Галиябану»да шулар өстенә сыйнфый каршылыкларны күрсәтү хосусияте дә кушылды... М.Фәйзи татар театр әдәбиятында, шулай итеп, чыннан да яңа бер әдәби сукмак салды» [Сәгъди, 2008; 167]. Әдип каләменең матур, халыкчан стиле, тел байлыгы күрсәтелә. Чор гыйльми-нәзари фикере һәм үзе тарафыннан ассызыкланган хосусиятләргә таянып, Г. Сәгъди М.Фәйзине «татар классик әдипләре тезмәсенә» кертә. Күренә ки, драматургның иҗатын бәяләгәндә, художество, форма мәсьәләләренә игътибар ителсә дә, социаль-сыйнфый принцип ноктасыннан якын килү өстенлек итә.

1920-1930 еллар татар әдәби тәнкыйтендә һәм әдәбият белемендә әдипләр иҗатын социаль чыгышлары белән бәйләп тикшерү, иҗтимагый-сәяси карашлары аша алар мирасының әһәмиятен билгеләргә омтылу

кебек мавыгулар М.Фәйзине дә читләтеп узмый, ул «вак буржуа» әдибе буларак бәяләнә. Р.Шәрәфиев «Мин синнән ераклармын, ераклармын, ераклармын» мәкаләсендә тәнкыйтьчеләрдән Г.Гали, Г.Толымбайскийның, каләмдәшләре Һ.Такташ, С.Җәләлнең, мөхәррир Ш.Рәмзинең, Раун тәхәллүсле берәүнең М.Фәйзинең 1920 еллар иҗатына, беренче чорда языла та, хәзер генә басылган кайбер әсәрләренә берьяклы, аерым очракларда вульгар социологик карашларын, бәя-хөкемнәрен күздән кичерә, аларның «авторга карата шактый ук аяусыз булуын» фактлар белән раслый. Аерым алганда, 1920 елларда рәсми тәнкыйть тарафыннан үзе үк нык кыйналган Һ.Такташ Татар театрында «Адашкан күңел» куелгач, «Татарстан» гәзитендә болай дип язып чыга: «Мондагы урынсыз җырлар, Фәйзинең һәрбер әсәрендә кабатланып килгән биюләр чүп өстенә чүмәлә булып төшәләр. Әсәрдәге шахтерлар типларын алсак, алары белән Фәйзи үзеннән көлдерү белән генә калмый, ачуны да китерә» [Шәрәфиев, 2006; 51]. Х.Хәйри, М.Фәйзинең вафат булуына ун елы тулгач, «Талантлы драматург» исемле мәкалә белән чыгыш ясый. Аны язучының тормыш юлын һәм әдәби эшчәнлеген шактый тулы яктырткан беренче күләмле хезмәт дип карарга мөмкин, тәнкыйтьче анда Фәйзи шигырьләренең үзенчәлекләрен дә әйтеп китә. 1930 елларның ахырларында әдәби тәнкыйтьтә классик мирасны бәяләүдә чикләнгән карашлардан арына барып, аның идея эчтәлеген объективрак ачуга омтылыш көчәйсә дә, Х.Хәйри, әле заман рухына ияреп, әдип әсәрләренә социологик анализ ясый. Автор М.Фәйзинең 1913-1917 еллар драматургик эшчәнлегенә түбәндәге бәяне бирә: «Ул революциягә кадәр язган байтак пьесаларында вак буржуа демократизмы карашларын чагылдырды» [Хәйри, 1941; 23]. Г.Кутуйның истәлек-хатирәләре, рецензияләре, Җ.Вәзиева, М.Гайнуллиннар төзегән дәреслек-хрестоматияләрдә М.Фәйзигә багышланган аерым бүлекләр дә аның иҗатын фәнни-гыйльми тикшерүгә мәгълүм өлеш кертәләр.

Шулай да аның тормыш юлын һәм әдәби мирасны өйрәнү юлында борылыш, безнең карашыбызча, 1970-1980 елларга туры килә. Бу күтәрелеш Г.Халит, И.Нуруллин, Б.Камалов, А.Әхмәдуллин, Н.Ханзафаров, М.Фәйзуллин, Д.Абдуллина, Г.Минский, М.Мөлеков һ.б.ларның исемнәре белән бәйле. Бу баскычта М.Фәйзинең иҗат биографиясен тикшерү-бәяләү һәм язучының тормыш сукмакларын, ул

булган төбәкләрдә әдип эзләрен барлау юнәлешләрендә эш алып барыла башлый. Драматург иҗатын өйрәнү сыйфади үзгәрешләр кичереп, язучы рухи мирасының аерым аспектларын шәрехләүдән монографик планда гыйльми күзаллау баскычына күчә.

Драматургия белгече А.Әхмәдуллинның «Аның сәнгатьчә ачышлары» (1971), «Ак калфак» (1976) мәкаләләрендә һәм шушы еллар гыйльми эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак дөнья күргән «Татарская драматургия: Истоки и формирование социалистического реализма» (1983) дигән монографик хезмәтендә М.Фәйзи драматургиясенең идея-эстетик үзенчәлекләре тикшерелә, татар драматургиясен формалаштыруда аның урыны билгеләнә: «М.Фәйзи дөньяда бары тик 37 ел тора. Кыска иҗат гомерендә ул 16 пьеса һәм йөзләгән шигъри әсәр, уннарча хикәя һәм нәсер, балалар өчен әсәрләр язып калдыра. Эш хәтта әсәрләр санында гына да түгел, - дип яза А.Әхмәдуллин «Аның сәнгатьчә ачышлары» дигән мәкаләсендә, – ул бары тик бер «Галиябану» драмасын гына язган булса да, аның исеме халык күңелендә мәңгегә урын алган булыр иде инде. М.Фәйзи исә күбрәк эшләгән, димәк, ул күбрәк бәягә лаек. Аның иҗат җимешләре бүген дә халык күңелендә матурлык һәм юмартлык чәчеп яшиләр» [Әхмәдуллин, 1980; 146].

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче И.Нуруллинның йөз башы татар әдәби хәрәкәтен колачлап тикшергән «XX йөз башы татар әдәбияты» (1966, 1982) дигән хезмәтендә язучы иҗатына бер бүлек багышлана. И.Нуруллин тарихи-мәдәни мәктәпнең төп кагыйдәләре ноктасыннан М.Фәйзинең идея-эстетик карашларының үсешен өйрәнеп, иҗат баскычларын аерып чыгара. Беренчеләрдән буларак, язучы шигъриятендәге лирик геройның романтик табигатен, романтик сыйфатларны барлый һәм лирикада туплаган иҗат традицияләренең «күңел биреп эшләгән өлкәсе драматургиядә» иҗади үстерелешен, дәвам ителүен билгели. Шулай ук М.Фәйзи иҗат дөньясында характер тудыру алымнары, сәнгатьчә фикерләү принциплары, алымнары гыйльми күзаллана. Тәкъдир, язмыш, сызлану фәлсәфәсе сызыгында язылган драмаларының идея-эстетик үзенчәлекләре жанр сыйфатлары ноктасыннан торып анализлана. И.Нуруллин тарафыннан язучының «революциягә кадәрге татар драматургиясенең иң зур казанышларыннан» булган «Галиябану» музыкаль драмасына ясалган җентекле анализы

әдәбият белеменең җитди казанышы булырга хаклы. Шулай да галимнең, әсәрдәге аерым романтик сыйфатларны таныган хәлдә, пьесаны тәнкыйди реализм кысаларында шәрехләве, Исмәгыйль, Бәдриләрнең характер сыйфатларын, эш-гамәлләрен бары тик марксизм-ленинизм тәгълиматының сыйныфлар хакында өйрәтүләренә таянып мотивлаштыруы укучыда сорау уята.

М.Фәйзинең әдәби эшчәнлеге диссертацион хезмәтләрдә өйрәнелә башлый. Моңа кадәр аз билгеле булган архив материалларына таянып, М.Мөлеков язучының беренче дәвер иҗатында әдәби эстетик карашларының, сәнгатьчә фикерләвенең үсеш-үзгәрешен «Дооктябрьская драматургия М.Файзи (Эволюция творческого метода)» дигән кандидатлык диссертациясендә тикшерә.

Әдәбият галиме Н.Ханзафаров тарафыннан «Татар әдәбияты тарихы»ның өченче, дүртенче томнарына әзерләнгән «Мирхәйдәр Фәйзи» дигән монографик бүлекләрдә язучы иҗат биографиясен гыйльми-нәзари күзаллау системалы төс ала. Мәкаләләр авторы М.Фәйзинең драматургиягә шигърияттә каләм сынау дәверен үтеп килүен билгели һәм XX гасыр башы драматургиясенең идея-эстетик кыйммәтен әдип пьесаларының сюжеты нигезендә яткан конфликт, характерлар бәрелеше яссылыгында шәрехли. М.Фәйзи иҗат концепциясенең төп сыйфатлары төсендә ирекле, илаһи мәхәббәт, фольклор эстетикасы белән баетылган романтизм ысулы, табигать гармониясе, «табигый кеше» күрсәтелә. «Галиябану» музыкаль драмасының идея-эстетик үзенчәлекләрен романтик һәм реалистик алымнарның табигый рәвештә үрелүе, романтизм һәм реализм синтезы сызыгында бәяләве галимнең драматург иҗат дөньясын бәяләүгә алып килгән яңалыгы буларак та кабул ителергә хаклы.

Н.Ханзафаров М.Фәйзинең 1920 еллар драматургиясен язучының иҗат традицияләре, көнчыгыш һәм рус әдәби бәйләнешләре, илдәге социаль-икътисади, иҗтимагый үзгәрешләр белән бәйләнештә карый. Сыйнфый көрәш сызыгы, социаль каршылыклар калкуландырылган әсәрләрендә, мәсәлән «Кызыл йолдыз» (1923) да, реалистик сыйфатның, тормышчанлыкның артуы билгеләнә. Әмма галимнең «Асылъяр» (1918-1920), «Ак калфак» (1922-1923) драмаларында байлар һәм морзалар тормышын тасвирлауда, характер тудырудагы берьяклылыкны күрмәскә тырышуы, «М.Фәйзинең өлгергән иҗаты әнә шундый сыйфатлары белән

чын мәгънәсендә партиячел, сыйнфый һәм халыкчан» [Ханзафаров, 1986; 267] дип заман рухында нәтиҗә ясавы бүгенге көн таләпләренә җавап бирә алмый.

М.Фәйзинең тормыш сукмакларын һәм әдәби эшчәнлеген тулы, җентекләп өйрәнүгә багышланган Б.Камаловның «Мирхәйдәр Фәйзи (Мирхәйдәр Фәйзинең тормыш һәм иҗат юлы турында)» дигән монографиясе 1987 елда дөнья күрә. Хезмәттә М.Фәйзинең иҗат гомере тәүге адымнарыннан башлап соңгы көннәренә кадәр язучы яшәгән тирәлек, әдәби-мәдәни мохит һәм иҗтимагый хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә тикшерелә. М.Фәйзинең, кыска булуга карамастан бай, кызыклы шәхси тормышы, эзләнүләре, табышлары, замана җиле тәэсирендә вакыт-вакыт мавыгып алулары, иҗатының гуманистик яңгырашы, художество эшләнешендәге яңалыклар, иҗат лабораториясе, стиль индивидуальлегенең чагылышы булган шәхсилекнең әдәби эшчәнлегенә йогынтысы һ.б. мәсьәләләр күздән кичерелә. Ә инде язучы иҗатының аерым үзенчәлекләренә социалистик реализм әдәбиятына куелган таләпләр, бәяләү бизмәннәре, сәяси-идеологик кануннар ноктасыннан якын килү шул чорның атмосферасы белән аңлатыла.

Шушы елларда М.Фәйзинең тормыш юлын, иҗат эшчәнлеген барлау, гомер юлындагы билгесез, ачык булмаган вакыйгаларны ачыклау һәм шәхси архивын фәнни яктан эшкәртеп, гыйльми әйләнешкә кертү юнәлешендә нәтиҗәле эшләр эшләнә. Бу юлда язучының туганнары, мәсәлән, журналист һәм тәрҗемәче С.Фәйзуллин, И.Фәйзуллин һ.б., якташлары, Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәре Д.Абдуллина зур хезмәт куялар. Эш барышында язучының нигездә көндәлек һәм куен дәфтәрләрен үз эченә алган шәхси тасвирламасын аерым китап итеп бастырып чыгару фикеренә киленә: «Мирхәйдәр Фәйзи. Шәхси архивының тасвирламасы» (1988).

XX-XXI гасыр чикләрендә М.Фәйзинең тормыш юлын һәм әдәби эшчәнлеген яңача, яңа идея-эстетик концепция яктылыгында өйрәнү, монографик планда булмаса да, дәвам итә. Матбугат битләрендә аерым эзләнүләр, мәкаләләр, әдипнең тууына 110 ел тулу уңаеннан Ф.Мусин, Г.Арсланов, Т.Миңнуллин, М.Мөлеков, Л.Хәмидуллин һ.б.ларның язмалары урын алды. Юбилей уңаеннан үткәрелгән әдәби-мәдәни чараларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә шагыйрь һәм драматургның

иҗаты хакында яңа бәя-хөкемнәр яңгырады, әлеге бай һәм гуманистик эчтәлекле әдәби мирасны гыйльми өйрәнүнең киләчәк перспективалары билгеләнде. Соңгы елларда әдипнең иҗат юлында һәм тормыш сукмакларындагы аерым фактлар тирәсендә әдәби бәхәсләр дә булып алды. Дөрес, алар М.Фәйзинең иҗат таҗы булган «Галиябану» музыкаль драмасы тирәсендәрәк барды. Бәхәстә Ф.Фәтхи, Р.Шәрәфиев, Ә.Галиев, Ф.Исламов, З.Әкбәров, Р.Вәлитова һ.б. лар катнашты. Күпсанлы язмаларның авторларын мәшһүр «Галиябану» пьесасының язылу сәбәпләре, урыны, төп каһарманнарның прототиплары, классик хәзинәне заман шаукымына бирелеп, «заманчалатып» сәхнәләштерү мәсьәләләре борчый һәм уйландыра. Күренә ки, аерым бер чорларда берьяклы мавыгулар күзәтелсә дә, шагыйрь һәм драматург М.Фәйзинең тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнү татар әдәбият белемендә үз сукмагын булдыра һәм язучы иҗат дөньясы хакында гыйльми күзаллау тудырыла..

## Сораулар һәм биремнәр

1. М.Фәйзине шәхес һәм язучы итеп формалаштырган даирәне һәм әдәби-мәдәни мохитне тасвирлагыз.
2. Язучының әдәби-эстетик идеалын ачыклагыз.
3. Аның тормыш позициясе, дөньяга карашлары, яшәү фәлсәфәсе замандашларыннан кайсы яклары белән аерыла?
4. 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси вәзгыять язучы шәхесенә һәм яшәү рәвешенә ничек тәэсир итә?
5. М.Фәйзинең дөньяга карашларының һәм сәнгатьчә фикерләвенең үзгәрешен күзәтегез.
6. Язучының тормыш юлы – иҗатының синхрон таблицасын төзегез.
7. «М.Фәйзи күңелендә Казан каласы» дигән темага инша языгыз.
8. М.Фәйзи тормыш сукмакларын һәм рухи мирасын өйрәнгән нинди галимнәрне беләсез?
9. Соңгы елларда вакытлы матбугат битләрендә “Галиябану” драмасы тирәсендә барган әдәби бәхәсләр.

## Контроль эш темалары

1. Авыл - М.Фәйзинең күңел кәгъбәсе.

2. М.Фәйзи һәм Тукай.
3. М.Фәйзи әсәрләрендә автобиографик җирлек.
4. 1970 елларга кадәрге гыйльми эзләнүләрдә М.Фәйзи иҗаты.
5. М.Фәйзинең татар профессиональ театрын үстерүдәге эшчәнлеге.
6. Б.Камаловның «Мирхәйдәр Фәйзи» монографиясендә язучы тормыш сукмакларының яктыртылышы.
7. Б.Камаловның М.Фәйзи шигъриятен бәяләү принциплары һәм үлчәмнәре.
8. Н.Ханзафаров гыйльми эшчәнлегендә язучы рухи мирасында фольклор эстетикасы проблемасы.
9. А.Әхмәдуллин гыйльми эшчәнлегендә "Галиябану" пьесасы сәхнә тарихының яктыртылышы.
10. И.Нуруллин гыйльми эшчәнлегендә драматургның 1910 еллар иҗатын бәяләү принциплары.
11. Л.Хәмидуллин эзләнүләрендә М.Фәйзи.
12. Р.Шәрәфиев тәнкыйди эшчәнлегендә һәм эзләнүләрендә М.Фәйзи.

**Гамәли дәрес. Тема: Әдипнең тормыш юлы һәм иҗатының өйрәнелү тарихы**

1. М.Фәйзи шәхесе формалашкан тирәлек һәм әдәби-мәдәни шартлар. Язучының шәхси тормышы, хәят юлындагы әһәмиятле вакыйгалар.
2. Әдипнең иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи карашлары, тормышка бәя-мөнәсәбәте.
3. М.Фәйзинең эстетик идеалы һәм әдәбият-сәнгать хакындагы карашлары.
4. Язучы иҗатын барлау һәм өйрәнү баскычлары. Бу юлда 1910 елларда ясалган беренче адымнар. 1920-1960 елларда аның рухи мирасын өйрәнүнең торышы һәм нәшер ителгән басмалар.
5. 1970 елларда М.Фәйзи тормыш юлын һәм иҗатын гыйльми тикшерүнең яңа этабы башлану: фәнни биографиясен эшләү, монографик хезмәтләр язылу һ.б.
6. XX-XXI гасыр чикләрендә М.Фәйзи рухи мирасын өйрәнү мәсьәләләре.

## Әдәбият


1. Арсланов Г. «Асылъяр», «Галиябану»лар туганда // Арсланов Г. Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар. – Казан: Мәгариф, 2008. – 251-257 б.
2. Әхмәдуллин А. Аның сәнгатьчә ачышлары «Ак калфак» // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. – 141-146 б.; 293-296 б.
3. Даутов Р. Татарның «Ромео-Джульетта»сын язган драматург // Мирас. – 2006. - № 11. – 58-64 б.
4. Исламов Ф. Әдип рухын рәнҗетмик // Ватаным Татарстан. – 1994. – 6 июль.
5. Закирҗанов Ә. «Кызганыч»та нәрсә кызганыч? (М.Фәйзи иҗатына күзәтү) // Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре (әдәбият укытучылары өчен методик кулланма). – Казан: «Мастер Лайн», 1997. – 69-77 б.
6. Камалов Б. Мирхәйдәр Фәйзи (Мирхәйдәр Фәйзинең тормыш һәм иҗат юлы турында). – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 160 б.
7. Камалов Б. Драматургиябез горурлыгы (Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 80 ел) // Казан утлары. - 1971. - № 10. - 179-181 б.
8. Кумысников Х. Вечно юная классика // Советская Татария. – 1981. – 30 октябрь.
9. Минский Г. Әдипне искә алганда (Мирхәйдәр Фәйзи) // Минский Г. Онытылмас очрашулар / Чорыбыз һәм үзебез турында. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1973. – 87-95 б.
10. Миңнуллин Т. Хәлил әйбәт егетме? // Мәгариф. – 2000. - № 3. – 32-33 б.
11. Мусин Ф. Мирхәйдәр Фәйзи һәм XX йөз татар әдәбияты // Шәһри Казан. – 2002. – 4 гыйнвар.
12. Мөлеков М. Мирхәйдәр Фәйзи – тәрҗемәче // Совет мәктәбе. – 1975. – № 5. – 39-41 б.
13. Мөлеков М. Халык рухын саклый // Мәгариф. – 1996. - № 3. – 19-21 б.
14. Мөлеков М Халык күңелендә калган моң // Казан утлары. – 1981. - № 10. – 176-181 б.

15. Мирхәйдәр Фәйзи. Шәхси архивының тасвирламасы. / Төз. Д.Абдуллина. - Казан: Казан университеты нәшрияты, 1988. - 150 б.
16. Нуруллин И. Мирхәйдәр Фәйзи // XX йөз башы татар әдәбияты: Урта мәктәп укытучылары һәм югары класс укытучылары өчен дәреслек –кулланма. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1982. – 261-282 б.
17. Сәгъди Г. Мирхәйдәр Фәйзи // Габдрахман Сәгъди. Фәнни-биографик җыентык. / Төз.: Д.Заһидуллина, Ч.Гыйлаҗева – Казан: Җыен, 2008. – 163-168 б.
18. Файзуллина Д., Абдуллина Д. Мирхайдар Файзи: повествование о жизни. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 120 с.
19. Фәйзуллин М. Казанда Мирхәйдәр Фәйзи эзләре // Социалистик Татарстан. – 1986. – 30 ноябрь.
20. Фәйзуллин И. Шодадагы көннәремнең таҗы // Казан утлары. – 1981. - № 10. – 181-183 б.
21. Фәтхи Ф. Әдип юлыккан Юлык // Мәдәни җомга. – 2004. – 5 ноябрь.
22. Фәтхи Ф. Җан рәхәте кичергән мизгелләр // Татар иле. – 2005. - № 1 (гыйнвар).
23. Ханзафаров М. Мирхәйдәр Фәйзи // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. – 3 том / XX йөз башы. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. – 421-435 б.
24. Ханзафаров М. Мирхәйдәр Фәйзи // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. – 4 том / Татар совет әдәбияты (1917-1941) .- Казан: Тат.кит.нәшр., 1989. – 259-270 б.
25. Хәйри Х. Талантлы драматург // Эзләнүләр: Әдәби-критик мәкаләләр. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 3-37 б.
26. Хәмидуллин Л. Әсәрләре гасырлар кичә // Ак төннәр хәтере. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. – 107-119 б.
27. Хәмидуллин Л. Мирхәйдәр Фәйзи эзләреннән // Казан утлары. – 1991. - № 11. – 170-174 б.
28. Чанышев С. Мирхәйдәр Фәйзи // Казан утлары. – 1972. - № 1. – 116-122 б.
29. Шәрәфиев Р. Уятмакчы булсаң // Казан утлары. – 1997. - № 4. – 168-180 б.; Халкыбызның көнкүреше әдип көндәлегендә // Татарстан. –

1998. - № 3. – 3-8 б.; Халыкка ул бәхет юрады: Мирхәйдәр Фәйзинең туууына 110 ел // Мәдәни җомга. – 2001. – 21 декабрь;
30. Шәрәфиев Р. Мин синнән ераклармын, ераклармын, ераклармын... Моңлы гашыйклар җырчысы // Татар эзләү: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 38-44; 45-53 б. һ.б.

## М. Фәйзи шигърияте

Татар әдәбиятының Исхакыйлар-Тукайлар чоры вәкиле буларак М.Фәйзи, замандашларыннан калышмыйча, үз каләм көчен шигърияттә дә сыный. Лирика төрендә М.Фәйзинең иҗат мөмкинлеге һәм таланты икенчел дәрәҗәдә булса да, унынчы еллар поэзиясенең эчтәлеген һәм юнәлешен билгеләүдә аның үз урыны бар. Фикри-мәгънәви һәм форма яңалыгы алып килгән пьесалар язуда, гомумкешелек кыйммәтләрен, мәңгелек темаларны гәүдәләндерүдә һәм хис-калеб белән яшәүче характерлар иҗат итү осталыгында М.Фәйзинең шигъри таланты, тәҗрибәсе сизелерлек роль уйный. Әдип лирикасындагы төп мотивлар, пьесаларында ижади файдаланылып, аның драматургиясен баета, сәнгати яктан камилләштерә һәм матурлый.

М.Фәйзи әдәби эшчәнлеген, гәрчә аларын үз иҗат фондына кертмәсә дә, бер пәрдәлек пьесалар («Татар туе», 1905; «Ике Хәсән», 1909) белән башлап җибәрә. Аннан соң шигырьләр, бәетләр язу белән мавыга башлый. 1910 елларда «Шура», «Аң», «Ялт-Йолт», «Вакыт», «Идел», «Акмулла» һ.б. газета-журнал сәхифәләрендә шигырьләрен укучы хөкеменә тәкъдим итә һәм ул аларны туплап, ике җыентык рәвешендә бастырып чыгара: «Минем шигырьләрем» (1912), «Яшь күңел» (1913).

М.Фәйзи XX гасыр башы татар поэзиясенең романтик юнәлешен дәвам итә һәм аны яңа үзенчәлекләр белән баета. Ул, берьяктан, Г.Тукай, С.Рәмиев, М.Гафурилар буыны тудырган халыкчан һәм гуманистик традицияләргә тугры булып калса, икенче яктан, аның әсәрләрендә милли шигъриятькә унынчы елларда килгән Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, Г.Харис, Г.Сөнгати, З.Бурнашева, Х.Шаммасова, З.Сәгыйдә һ.б.лар иҗатында калкуланган яңа мотивлар, поэтик бизәкләр дә чагыла. Шагыйрь буларак лирикада ул үз юлын табарга, үз кичерешләрен җырларга омтыла.

М.Фәйзи шигърияте мотивлар төрлелеге, тел-сурәтләү чараларының байлыгы белән характерлана. Анда халык, милләт, социаль контрастлар, яшәү, үлем, тәкъдир, дини мотивларны аерып чыгарырга мөмкин. Табигать, музыка, мәхәббәт культы кебек романтик эстетика атрибутлары тотрыклы төс ала. Шулай да аның иҗатын замандашларыныкыннан аерып торган сыйфат төсендә авыл мотивының калку гәүдәләнүен күрсәтергә кирәк. Шигъри мирасының буеннан-буена күзәтелгән бу тема туган як

төшенчәсен белдерүгә хезмәт итә. Шагыйрь үз күңеленә кәгъбә иткән, яшәешенә ямь өстәгән «авыл – ал гөл» темасы М.Фәйзи әсәрләрендә ваклап, кечкенә өлешләргә бүленеп, детальләштерелеп тасвирлана һәм мондый шигырьләр бер шәлкем тудыралар. Романтик рухлы герой егет-кызларның җырлы-биюле уеннарын, җыен күренешләрен күреп соклана («Чишмә буенда»). «Печән чапканда» шигырендә печән чабу, физик хезмәт романтикасы белән хозурланган лирик «мин»нең тирән күңел кичерешләре, хисләре авыл, туган якка мәхәббәтенең бер өлеше буларак гәүдәләнеш ала. Күкрәгеннән ак күгәрчен очыру детале лирик геройның ашкынулы, дәртле хисләрен зурайтып, арттырып җибәрә:

Тиңлимен ил кызларын мин гөл белән,
Яшь йөрәктән пакъ мәхәббәт гарыз итәм (аңлатам)
Күкрәгемнән ак күгәрчен очрамын,
Саф сәламнәр илтүен җилдән көтәм.

Бай, шат һәм моңлы сурәтләр аша тасвирланып, кабатлаулар, сынландырулар аша тергезелгән табигать күренешләрен («Табигать манзарасы», «Хәйран булам»), лирик геройның күңелен җилкетә, җан, ямь бирә торган ел фасылларын («Җәйге төн») сурәтләгән әсәрләр дә шушы шигъри бәйләмнең гаҗәеп матур бизәкләре булып торалар:

Сергә чумылып, чолганып ак нур белән
Күренә ап-ак тезмә таулар төркеме,
Күренәләр юллар еландай ялтырап,
Ямьлиләр күлләр табигать күркене.

(«Җәйге төн»)

Шагыйрьгә табигать һәм табигыйлеккә якын торган авыл матур күренә. Автор туган авыл, табигать матурлыгына хәйран калып, аны гөл дип атый. Туган як төшенчәсен, авыл матурлыгын моңлы музыка-уен коралларында, моңлы халык җырларында да («Җырчы Хәсәнгә», «Халыкча»), физик яктан көчле, дәртле егетләрендә дә, «нечкә билле, ак тәнле» кызларында да таба ул. Авыл темасына соңрак язылган шигырьләрендә мәгънә һәм форма ягыннан яңа, кабатланмас бизәкләр, төсләр өстәлә.

Бөтенне өлешләр аркылы гәүдәләндерү алымы аша авыл илнең бер өлеше итеп карала. «Илем» шигырендә автор авылга дан җырлый. Җан яме, ямь бәйләме, алтын тәхет шартлы-романтик образлары лирик

геройның үз авылы белән горурлану, соклану хисләрен сурәтлиләр. Авылның җиле, давылы, кешеләрнең яманы, дусы кебек детальләр ярдәмендә туган як төшенчәсе төгәлләштерелә. Күренә ки, шигырьнең эчтәлеге булган авылны ярату хисе, лирик геройның рухи дөньясын күрсәтеп кенә калмыйча, шагыйрьнең гражданлык позициясен, дөньяга карашларын да белдерә. Халык теләк-омтылышлары белән яшәп, яшәү мәгънәсен халыкка хезмәт итүдә билгеләгән авылы өчен «аккош» булырга хыяланган лирик герой үз белемен, бәхетен, хәтта үз гомерен дә аның белән бүлешергә әзер:

Мин телим Хактан белем, бәхетем белән гомрем гелән,
Һәммәсен бүлмәк булам халкым белән, авылым белән.
Тырышамын авылым өчен, аккош булыйм дип бәхетенә,
Нурлы бер аккош булыйм дип авылым – алтын тәхетемә.

Ә инде «Юлык», «Юлык моңнары» шигырьләрендә бу теманы сурәтләүне шагыйрь конкрет яссылыкка – үз тормыш юлында, яшәешендә зур урын тоткан, җаны-рухы белән тойган, һәр күренешен үз калебе аша үткәргән Юлык авылына күчерә. Аларда лирик геройның кичерешләре күпмедер күләмдә шәхсиләштерелә, автор белән якынайтыла. Шигырьнең беренче строфасында лирик герой үзенең изге хыялын, идеалын Юлык авылы белән бәйләп куя. Алдагы строфаларда күңел мотивы килеп керә. Шәркый формаларга – гөл һәм былбыл образларына мөрәҗәгать итеп, автор аларны яңа мәгънә, эчтәлек белән баета. Лирик герой үз күңел-былбылын авыл-гөл белән бәйләп, аның матурлыгын сайрый:

Әллә күңелемне игез иткән авыл белән,
Ямьләп килде күңелемне ул авыл гелән;
Авыл – ал гөл, минем күңелем былбыл аңа,
Рухланадыр былбыл гелән, ал гөл белән.

Теләк-омтылышларына, идеалына «Юлык авылы аша юлыгу» өчен лирик герой дөлдел атларга менеп чаба. Соңгы строфаларда ярату, хозурлану хисе иң югары ноктага җиткерелә. Аңа «чәчәкләрдән күңелләремә ямьнәр ява», «күктә йөзгән йолдызлардан ямьнәр ява», «Юлык авылы җир җәннәте – ямь бишеге» кебек сүз-сурәтләр, чиктән тыш арттыру, чагыштыру алымнары ярдәмендә ирешелә.

Шул рәвешле М.Фәйзинең аерым шигырьләрендә төп мотив булып килгән халык, табигать, моң, музыка, кызлар матурлыгы, егетләрнең

физик вә рухи ныклыгы, табигыйлек, кичке уен, җыен, печән чабу күренешләре, хезмәт романтикасы берләшеп, авыл темасын гәүдәләндерәләр, матур һәм төрле төсләрдәге бер мозаика тудыралар.

М.Фәйзи шигъриятендә Тукай темасының гәүдәләнеше иҗади бәйләнешләр, әдәби йогынты мәсьәләсе ноктасыннан шәрехләнә ала. Татар халкының Мәккәсе, рухи кыйбласы булган Казанга М.Фәйзи, Г.Тукай белән очрашу максатыннан, бу шәһәргә тагын бер кат махсус сәяхәт кыла, үзенең шигъри остазы, рухи таянычы белән күрешергә тели. Аңа шагыйрь белән очрашу насыйп булмый, әмма бу сәфәр «Габдулла әфәнде Тукаев наменә» (1912) дигән шигыре туугa сәбәп була. Әсәрдә М.Фәйзинең Тукайга тирән ихтирамы, аның татар халкы хәятында, әдәбиятында тоткан олылыгын, зурлыгын тою хисләре гәүдәләнгән. Мәгълүм булганча, бу темага унынчы елларда күп шагыйрьләр мөрәҗәгать итә, ул Тукайның вакытсыз үлеме белән тирән фәлсәфи, иҗтимагый төсмер алып калкуланып та китә. Бу әдипләрнең «шагыйрь һәм халык», «шагыйрь һәм милләт» концепциясе тирәсендә уйлануларның нәтиҗәсе дә булып тора. Шагыйрьләр яшәү мәгънәсе, иҗат кыйбласын ачыклау юлында милли идеалның әхлакый һәм фәлсәфи нигезләрен билгеләргә омтылалар, милли идеал хакында эзләнүләр алып баралар. Тукай үз иҗаты, тормышы, яшәеш үзенчәлеге белән башкаларга идеал, үрнәк, өлге ролен үти, ул гына түгел, аның шигъриятендә идеал шагыйрь образы калыплаша. М.Фәйзи шигырендә Тукай образы Урта гасыр татар, суфичылык, Х1Х гасыр мәгърифәтчелек әдәбиятлары традицияләрендә шартлы романтик сурәтләр ярдәмендә идеаллаштырылып тасвирлана:

Әллә исмең гали, җисмең бер нур,
Хакның җиргә иңгән мәләге (фәрештәсе)
Әллә зур күңелле, көчле телле
Безгә хакның махсус бүләге.

Әсәрдәге традицион-символик образлар шигырьне Кол Галинең «Кыйссай Йосыф» дастанына, конкретрак әйтсәк, Йосыфны сурәтләү алымына китереп бәйли. Автор шагыйрьне җәмгыятьтә кешеләр арасында изгелек таратучы, яктылык иңдерүче «нур»га тиңли. Суфичылык әдәбиятында киң файдаланылган гөл - былбыл, сандугач образлары, яңа иҗтимагый мәгънә алып, татар милләте мәнфәгатьләрен кайгырту, аның язмышы, киләчәге турында уйлану, халык өстенә төшкән авырлыкны,

кайгы-хәсрәтне кичерү, уртаклашудан Тукай язмышының аерылгысызлыгын раслыйлар. Аурупа-рус әдәбиятларындагы пәйгамбәр образының иҗади үстерелеше буларак, шагыйрьне Аллаһы Тәгалә тарафыннан җиргә иңдерелгән фәрештә аша гәүдәләндерү шигырьнең фәлсәфи эчтәлеген, гуманистик яңгырашын тирәнәйтеп җибәреп, Тукайны халыкка, иҗтимагый хәятка тагын да якынайта. «Зур күңелле», «көчле телле», «уктан үткен, нурдан якты тәмле шигырь» язучы Тукайны «җан азыгы бирүче», кайгыларны таратучы итеп таный, аның милләт язмышындагы гаять зур ролен раслый. Шигырьдә гәүдәләнгән лирик геройның хис-кичерешләре иҗтимагый-тарихи эчтәлек ала: М.Фәйзинең Тукай турында уйланулары милләт язмышы, яшәеше хакында карашлар белән кушылып китә. Алар әсәрдә халыкның, татар милләте вәкилләренең уртак кичерешләре кебек тәгәлләшә, аның хисләрен ача, тасвирлый һәм шигырь гражданлык лирикасының үрнәге булып тора:

Рух өрдең син, халкың тергездең син
Гали күңлең чәчте кодси (саф, изге) нур,
Тыныч булсын җаның, рухта намең (исемең)
Ихтирамым сезгә таудан зур.

М.Фәйзи шигъриятендә Г.Тукай иҗаты белән бәйләнеш гомумән көчле, ул һәрдаим шагыйрь традицияләренә тугрылык саклый. Шагыйрь әдәби иҗатта гына түгел, ә яшәештә, катлаулы хәятта Фәйзигә үз кыйбласын, мәсләген билгеләргә булыша, юл күрсәтә. Аеруча яшәү мәгънәсе, шагыйрьлек миссиясе, аның халык, милләт язмышындагы роле турында уйлануларын тасвирлаган «Фәрештә» (1912) шигыре Тукайның «Тәм һәм ләззәт нәрсәдә» (1907) әсәре йогынтысында язылган. Биредә, беренчедән, «Габдулла әфәнде Тукаев наменә» шигырендәге «фәрештә» образы тагын килеп керә, аның әсәрдәге тоткан урыны тирәнәеп китеп, фәрештә шагыйрьгә киңәш, үгет-нәсыйхәт бирә. Яшәү, тормыш тәмен, мескен-фәкыйрьләргә теләктәшлек итеп, милләт һәм халыкка хезмәт итүдә күрә. Ул автор тарафыннан Аллага якынаеп, аның ризалыгын алып, чын кеше булуның бер юлы буларак тәкъдим ителә:

Бер Аллага итеп коллык, фәкыйрь-мескенне
кызгансаң,
Керешсәң, милләткә хезмәт өчен җиңнәрне сызгансаң,
Менә шунда бу тормышның тәмен белсәң белерсең син,

Менә шунда тәмам чын-чын кеше булсаң,
булырсың син.

Халыкчан нечкә юмор белән сугарылгын «Ата белән бала» (1912), «Егет илә кыз» (1912) шигырьләрендә дә Тукай рухын күрү кыен түгел. 1913 елда язылган «Мөнбәр вә мендәр» шигырендә антитеза алымы ярдәмендә халык мәнфәгатьләренә, ихтыяҗларына аркасы белән торган, миллионнар белән эш итүче байлар катлавы Тукайча сатирик үткенлек белән тәнкыйтьләнә:

Ул йөри дишла белән гел, мендәре йомшак мамык
(Шундый бер бай, милләтем дип йөрмәс инде вакланып).
Ач туганнар, ярлы милләт бармы? - Уйлап бакыйм да.
Калмый шантан (күңел ачу урыны) һәм трактир,
тик йөри ахмакланып.

Яшәү идеалын милләткә хезмәт итүдә билгеләгән көчле ихтыярлы, сынмас рухлы галим образы  байга каршы куелып гәүдәләнгән. Шагыйрь лирик геройның аларга мөнәсәбәтен тирәнәйтү, ике чынбарлык каршылыгын тагын да конкретлаштыру максатыннан мөнбәр - мендәр, бер тиен - миллион кебек антиномияләргә мөрәҗәгать иткән.

М.Фәйзи үз шигырьләрендә замандаш шагыйрьләренең идея-эстетик үзенчәлекләрен, төп мотивларын, сурәтләү алымнарын, поэтик нәкышләрен иҗади файдалануның оста үрнәген күрсәтә. 1910 елларның урталарында иҗат ителгән әсәрләрендә шагыйрьнең Дәрдемәнд, С.Рәмиев лирикасына мөрәҗәгать итүе сиземләнә. Моның сәбәпләре шагыйрьнең яшәү һәм үлем, тәкъдир, язмыш кебек фәлсәфи мәсьәләләр турында гамьнәргә бирелүе белән аңлатыла. Беренче бөтендөнья сугышы еллары татар әдәбиятында  рухи һәм физик үлем  темаларының, төшенкелек, өметсезлек, дини мотивларның калкулануы да аның иҗатына тәэсир ясый. Менә бу сыйфат үзгәрешләре М.Фәйзи шигъриятенең идея-эстетик яктан катлаулануына, анда психологик анализның тирәнәюенә китерә. Аурупа - рус әдәбиятларында формалашкан модернистик агымнардан экзистенциализм, экспрессионизм билгеләре, аларга хас сурәтләү чаралары ярдәмендә лирик геройның каршылыклы, газаплы кичерешләре тасвирлана башлый.

1913 елда М.Фәйзинең «Яшь күңел» исемле китабы дөнья күрә. Бу җыентыкка тупланган шигырьләрне күңел мотивы, лирик геройның

каршылыклы – кайгы-хәсрәтле һәм шатлыклы күңел халәтен гәүдәләндерү берләштерә. Китапны шагыйрьнең «Үз иркемә куй» әсәре ачып җибәрә. Тәкъдир, язмышка мөрәҗәгать итеп язылган бу шигырьдә лирик герой, кеше туганчы ук, аның гомере, фани дөньяда ниләр күрәчәге Аллаһы тарафыннан билгеләнеп куела дигән дини өйрәтмәгә, кагыйдәгә каршы чыга. Әсәрдә лирик геройның гыйсъянчылык сыйфатлары да чагыла. Беренче-икенче строфалардагы кеше яшәешен, аның эш-гамәлләрен бер тәртипкә, тар рамкаларга салган тәкъдиргә ризасызлык хисе өченче строфада рәнҗүгә кадәр үсеп җитә:

Ихтыяр юк үз теләгем берлә эш күрмәк өчен,
Иркемә каршы төшәсенә, сарыф итеп син бар көчең.
Ул синең золмың чиген чыкмак санап мөмкин түгел,
Кыска холкың берлә тар рамкаң өчен рәнҗи күңел.

Күңелне бәйдә тоткан тәкъдиргә гипербола алымы ярдәмендә арттырылган ирекле вөҗдан («вөҗданымны программаңнан мең артык беләм») каршы куела. Шәхес иреге, күңел хөрлеге кеше өчен иң кирәкле, иң зур кыйммәт буларак тәкъдим ителә. Кешенең җирдә үзенә хуҗа булып яшәү теләге шулкадәр көчле, аның үтенече тормышка ашкан очракта, ул Аллаһыга, язмышка тел-теш тидермәскә вәгъдә бирә. Алар хакына лирик герой, язмышка буйсынып, Аллаһыга шөкер итеп, булганга канәгать булып яшәгән мөселманга бакыйлыкта вәгъдә ителгән җәннәт тормышыннан – алтын, байлык, матур яр, былбылларыннан да баш тарта. Соңгы строфада риторик эндәш формасында бирелгән лирик геройның үтенече, фәләккә ялваруы, аның чарасызлык, гаҗизлек баскычында торуын дәлилли. Шигырьнең тулысынча тәкъдиргә, фәләккә мөрәҗәгать рәвешендә язылуы, чиктән тыш арттыру, «тоткын», «тырнак», «тар рамка», «программа» кебек образлар-детальләр хис-кичерешне көчәйтә.

Лирик герой күңеленең кайгылы халәтен тергезгән шигырьләр тезмәсеннән шагыйрьнең «Үткән вакыт» шигыренә мөрәҗәгать итик. Әсәр 1910 елда иҗат ителә һәм беренче тәҗрибәсе булуына карамастан талантлы каләм белән язылган. Автор шигырьдә ретроспектив вакытны файдалана. Зарлы, хәсрәтле күңел дөньясына лирикада еш сурәтләнгән яшьлек тә, үткәндә калган нурани мәхәббәт тә түгел, ә сирәк очрый торган саф, шатлык һәм ямь тулы сабыйлык чорын каршы куя. Сабыйлык тормышының сурәте зифа талдан ясалган атка атланып чабулар, балык

тоту, су керү, кызыклы уеннар уйнау, җиләк җыю, Урал, су буйларында күңел ачып йөрү детальләре ярдәмендә тудырыла һәм җанландырыла. Пакъ вөҗүд, мәгъсум, саф калеб-кара тап, кер антиномияләре шигырьдәге каршы кую алымын тирәнәйтә, кайгы хисен югары дәрәҗәгә күтәрә. Лирик герой, күңеленең хәзерге халәтен сабыйлык чоры белән чагыштырып, үз-үзенә риторик сорау куя:

Уйлап-уйлап үткән вакытларны,
Чагыштырып соңгы хәлемә, -
Нигә элек алай? Хәзер болай? –
Хәйран булам дөнья хәленә.

Соңгы строфада лирик геройның үкенеч хисе чарасызлык хисенә күчә. Ул Аллага эндәшеп, аны кайгысыз, рәхәт, уйнап, сикереп чабып йөргән сабыйлыкта калдырмыйча, үстергәне өчен ризасызлык, үкенеч хисен белдерә. Шигырьдә гыйсъянчы герой сыйфатлары да күренеп кала.

Шагыйрьнең аерым шигырьләрендә сызлану фәлсәфәсе ярдәмендә яшәешкә, тормышка бәя-мөнәсәбәт белдерелә. Ш.Бабичның шул исемдәге әсәре йогынтысында иҗат ителгән «Зарлану» шигырендә «дөньядан рәхәт көзләгән» лирик герой дустына эндәшә, ямьле тормыш, ямьле йөз урынына аның ялган, үлем оясы булуын күреп сызлана. Өченче строфада лирик герой, үзенең борчулы, дөнья гаделсезлегеннән арган күңеленә тынычлык эзләп, изге эзгә – файдалы эш-гамәлләргә үз күңелен юнәлдерә, әмма шатланган калеб янәдән үзенең алдануын төшенә:

Аптырыйсың һәм арыйсың, күзлисең бер изге эз.
Булмый, тормыш изде безне, җөмлә юллар кан  гына.
Кайвакытта калебләр әллә нидән шатлана,
Күп тә үтми ут калебтә, булган ул ялган гына.

Шушы хәлдән, халәттән чыгу юлын эзләгән герой ирреаль дөньяга мөрәҗәгать итә, әмма анда да җәһәннәм, сызылып сызланучы җанны гына күрә. Соңгы юлларда дөньядан ямь, бәхет очратудан, яктылык табудан, өметен өзгән лирик геройның калебенә дуслардан гына нурлар иңелү мөмкинлеге, өмете аңа юану хисләре алып килә. Сүз-сурәт катламындагы рәхәт-ялган, шатлык-корбан егълау, изге эз – канлы юл, ямь-җәһәннәм антиномияләр лирик геройның сызлану хисен, зарлы халәтен көчәйтә. Автор риторик мөрәҗәгать, риторик сорау, күп нокталар, «җөмлә юллар

кан гына» гиперболасы, антитезалар, символик образ ярдәмендә лирик геройның чарасызлыгын, сызланулы халәтен тулырак ачуга ирешә.

«Бәхет» шигырендә лирик геройның күңел кичерешләре авторныкына якынайтыла. Аңа геройның халәтен вакыт ягыннан төгәлләштерү аша ирешелә. Әсәр М.Фәйзинең үз тормышы, язмышы турында бәян итүе кебек кабул ителә башлый. Фани дөньяда унтугыз ел яшәп тә бәхетне күрмәгән, тоймаган геройның сызланулы күңеле әсәрнең сурәтләү объекты булып тора:

Мин туганга унтугыз ел, һич тә бәхет күрмәдем,
Бер вакыт соң ул миңа да койрыгын болгар микән?

Шигырьне мәгънәви яктан өч өлешкә аерырга мөмкин. Беренче өлештә лирик геройның борчылу, кайгыру сәбәбе – көтеп-көтеп тә килмәгән бәхет. Шушы халәттә сызланып яшәргә мәҗбүр ителгән герой бәхет килүенә өметен өзми. Бәхеткә мөрәҗәгать итү, аны чакыру алымы лирик геройның гаҗизлеген белдерү чарасына әверелә. Икенче өлештә лирик геройның хис-кичерешләре үзгәрә, өмет хисе өметсезлеккә күчә. Борчылу сәбәбе дә үзгәрә. Бәхетнең барлыгына шик-шөбһә белдергән лирик герой, инде чит кешеләр мактаганга күрә генә, аны үзенә чакыра. Бәхет килсә дә, аның башы түбән иелгән, рухы сүнгән, күңеле боек лирик геройның кайгылы-хәсрәтле халәтен уңай якка үзгәртә алуына ышанычы калмаган. Соңгы өченче кисәктә лирик герой гомер буе көткән, эзләгән, әмма соңарып килгән бәхетеннән баш тарту югарылыгына күтәрелә. Аның сәбәбе фәлсәфи планда бирелә – гомер үткән, үлем вакыты җиткән:

Эзләнеп, бәхтем куып йөрим тагын гафләт (ваемсызлык) белән,
Газраил җаным  алырга күптән интизар (зар булып) икән.
Юк, алайса, вакыт үтте, килмәсен бәхте миңа!
Нишлим ул бәхте илә? Җитте үлем вакыт миңа.

«Рәхәт кайда?» шигыренең эчтәлеге алдагы ике әсәрдә гәүдәләнгән идея-фикерләрнең мантыйкый үстерелеше һәм төгәлләнеше кебек кабул ителә. Ул лирик геройның күңел сыкрануларына, эзләнүләренә чик куя. Әсәрдә экзистенция баскычындагы лирик геройның кичерешләре тасвирлана. Җир тормышында рәхәт тәмен татуга, бәхеткә ирешүгә өмете киселгән, өзелгән лирик герой дөньядан ваз кичү хәленә җиткән:

Тудым, тордым, гиздем дөньясын да,
Аһлар ордым, рәхәт тапмадым.

Кудым бәхтен комын, сулар кичтем,
Мәгәр рәхәт тәмен татмадым.

Тау кадәр дип вәгъдә ителгән бәхетнең алдау, күз буяу икәнлеген төшенгән лирик герой «яшәешкә – имансыз дөнья», «канлы җиргә ләгънәт» укый. Тискәре якларын, гаделсез кануннарын бер-бер артлы санау алымы ярдәмендә дөньяга нәфрәт белдергән лирик герой, яшәүдән баш тартып, Аллаһы әмере белән бакый дөньяга күчә. Әлеге экзистенциаль чиктән соң лирик геройның кичерешләре үзгәрә: сыкрану, сызлану шатлык белән алышына. Үлем аңа шатлык китерә, горурлык хисе пәйдә була. Ләхеттәге тынлык, бәхет гөлләренә ирешү, шәфкать күлләрен күрү лирик геройның халәте, кичереше үзгәрүнең сәбәбе булып тора:

Монда рәхәт икән, монда тынлык,
Монда күрдем бәхет гөлләрен.
Тапмаганда анда тамчысын да
Монда күрдем шәфкать күлләрен.

«Җир өсте гөл, асты ут» дигән фикеренең ялгыш икәнлеген төшенгән герой кабергә салган өчен Раббысына рәхмәт хисләрен белдерә. Дөньялыкта үлем, ләхет сүзләреннән куркып, алардан саклауны сорап Аллаһыга сыгынганы һәм шул сәбәпле ирреаль дөньяга күчүе соңарган өчен әле лирик герой үкенү хисен дә белдереп куя. Яшәү – үлем, дөнья – кабер, гөл – ут, тамчы – күл, ирешмәгән бәхет – күрелгән бәхет, канлы җир – якты ләхет антитезалары ярдәмендә җир тормышы белән бакый дөнья, яшәү һәм үлем каршылыгы көчәйтелә. Үлем, ләхетне ак бәхет белән чагыштырган юлларда лирик геройның күңел бакчасындагы шатлык хисенең иң югары дәрәҗәсе күрсәтелә. Шигырьдә үлем, чынбарлыктан мәңгелек дөнья күчү бәхетсез, гаделсезлек, караңгылык каплаган дөньяга ризасызлык белдерү, ахыр чиктә аннан котылу чарасы, юлына әверелә.

«Соңгы теләк» шигыренең эчтәлеге дә, экзистенциаль яңгырашка ия булып, шушы юнәлештә иҗат ителгән. Аның язылу тарихы үзенчәлекле: үзенә кул салган кешенең кесәсеннән чыккан язу шагыйрьне кулына каләм алырга этәрә. Шигырь кешеләрне изү, кысуны идеал иткән дөньяның усаллыгы-явызлыгына, җәбер-зәһәренә түзә алмыйча, чарасызлык баскычына атлап, үз-үзенә кул салган лирик геройның уйлануларын, төгәлрәк әйткәндә бу гамәленә бәя-мөнәсәбәтен тасвирлый.

Башкалардан аермалы буларак, геройның күңел халәте, кичерешләре аның дини ышанулары, дини кануннар, Коръән тәгълиматы белән үрелеп сурәтләнә. Шагыйрь Коръән-Кәримнең «Шүгәра» («Шагыйрьләр») сүрәсендәге Аллаһы Тәгаләнең дөньяны һәм шул исәптән кешеләрне бар итүе һәм бары тик аның әмере белән генә адәмнең бакый дөньяга күчүе турындагы аятькә таяна. Лирик геройның борчылу сәбәбе дә дини өйрәтмәләр белән бәйләнгән: үз-үзеңә кул салу Раббы каршында белеп кылган иң зур гөнаһлардан исәпләнә. Ул гөнаһларны бер Аллаһ Сүбхәнәү вә Тәгалә генә гафу итә ала. Башка беркем дә гафу итә алмый. Лирик герой Аллаһыга эндәшеп, дөньялыкта кылган гөнаһларыннан ярлыкауны сорый:

Әй Иляһым! Күп гөнаһым, кыл гафу бар гаебеме,
Монда күргән хурлыгымның, анда биргел гаедене!

Ул үзен мөрдар-шакшы, кәбәхәт дип атаучыларга Коръән белән тулган күңелен каршы куя һәм үзен андыйлардан аралый.

Дөньяның тискәре якларын күрсәтү максатыннан әсәрдә файдаланылган санау алымы («юк сафасы, юк вафасы, күп җәфасы дөньяның») лирик геройның аңа нәфрәт хисен тирәнәйтә. Дини дога мотивлары, Коръән-Кәримнән цитаталар күзәтелү, шигъри остазы Г.Тукайның «Васыятем» шигыреннән алынган «тулган иман садремә» реминисценциясе М.Фәйзинең әдәби-эстетик, дини карашларын укучыга җиткерү алымнары булып торалар.

«Чын дуст» шигыре шушы дулкында иҗат ителгән. Коръән-Кәримнең «Шүгәра» сүрәсенең бер аятендә дусларны Аллаһы Тәгаләдән сорау һәм Кыямәт көнендә үз дуслары белән бергә кубарылу турында әйтелә. Бу дөньялыкта изге, яхшы, тәртипле кешеләр белән аралашуның әһәмияте хакында сөйли. Әсәр лирик геройның матди хәленә карамыйча – баймы ул, фәкыйрьме, мәгъсум калебле, саф күңелле, кыю, батыр, булдыклы дус табу өметен тасвирлый:

Биралмыйм әһәмиятен байлыкка, бай булсын, фәкыйрь булсын,
Фәкать булсын калеб мәгълүм, күңел саф һәм гаюр (кыю) булсын.
Йөзендә бер хәят уйнап, сүзендә тәм—үтем булса,
Гакыл там (тулы), холкы киң, әхлак җирендә, хис бөтен булса!

Дусның үз татарыннан, мөэмин-мөселман булуы да шарт ителә. Кәферләрне, мөшрикләрне дус тотуның гөнаһ икәнлеге Коръәндәге

«Мүмтәхинә» сүрәсенең беренче аятендә әйтелә. Йөзендә хәят уйнаган, сүзендә тәм-үтем, гакылы бөтен, холкы киң булган әхлаклы дус камил инсан дәрәҗәсенә җиткерелә. Якын иптәшнең сыйфатлары субъектның, ягъни лирик геройның характеры буларак та аңлашыла башлый. Алга таба лирик «мин»нең дуска килгән шатлыкны да, кайгы-көенечне дә, авырлыкны да бүлешергә әзерлеге әйтелә. «Дусым яклап, намын саклап җаваплармын җаным берлән» дигән соңгы юлларда хис көчәйтелә: дус хакына лирик геройның җанын да кызганмавы турында хәбәр ителә.

Ә инде «Дустым өчен. Фәләк», «Дустым» шигырьләре чын дусты вафат булган лирик геройның төрле баскычтагы күңел кичерешләрен тасвирлый. «Үткән вакыт» шигырендә үзен сиздереп куйган гыйсъянчылык мотивы беренче шигырьдә калку төс ала. Якын дустын югалту ачысы белән газапланган, сызланган лирик герой, аны вакытсыз үз куенына алган Аллага каршы чыга. Картлар белән бергә яшьләрнең дә үлүен Аллаһының гаделсез гамәле буларак бәяләгән лирик герой аның үзен яратып, бар иткәннән соң, кайгы-хәсрәтле, газап-михнәтле дөньяга ыргытуына ризасызлык белдерә:

Алыр булгач, безне нишләп яраттың?
Яраттың да бу дөньяң эченә аттың.
Китә картлар белән яшьләр дә бергә,
Синең җәбрең белән яшьләй кабергә.

«Кайчан[1] комсызлыгыңдан бер туярсың? Кайчан инсан белән уйның куярсың?» дигән юлларда кулланылган риторик сорау алымы лирик геройның ризасызлык хисен нәфрәт, ләгънәт дәрәҗәсенә үстерә. Шул ук вакытта әлеге гаделсезлекне үзгәртә алмаудан лирик герой күңелендә ачыну төсмерләре дә барлыкка килә. Бер җан, бер тән булып яшәгән дустын югалткан лирик геройның кайгы-хәсрәтле күңел халәте градация алымы ярдәмендә – күңел төшкән, үзем мәэюс, күзем яшь, рухым егълый – сурәтләнә, тергезелә.

1912 елның мартында язылган «Дустым» шигыре газиз дусты үлеп күпмедер вакыт үткәннән соң газапланып, сызланып гомер кичерүче лирик геройның рухи дөньясын күз алдына бастыра. Әсәр лирик герой белән «гыйдар» (алдакчы) дөнья каршылыгына корылган. Биредә лирик геройның гыйсъянчылык рухы сүрелгән, ул үз язмышы белән килешкән.

[1] Авторда *качан*.

Сызланулы халәт дусты исән чагындагы рәхәт тормыш, үткән вакыт белән хәзер караңгылык каплаган, күз яшьләре тулы, аһ-зарлы яшәеш каршылыгы белән көчәйтелә:

Рухан, җисмән синең берлән бер улгач,
Минем һәм төште рухым, дустым, син үлгәч,
Сине уйлыйм да бәгъзан җырлый башлыйм,
Моңаям-моңланам да егълый башлыйм.
Синең хатирәң алдында бөгәм баш,
Тәмам мәгъсум сабыйдай мин түгәм яшь.

Әсәрдәге күз яшьләре детале сызланучы лирик геройның кайгы-хәсрәтле күңел халәтен һәм дөньяга ләгънәт белдерү чарасы да булып тора. Шигырьнең соңгы строфасында дустының кабере янында әйтелгән ант сүзләрендә лирик герой үз сүзләренең, хисләренең дөреслегенә, ныклыгына тагын бер кат ишарә ясый. Алар кайгы-хәсрәт хисенең юану төсмере белән баюын да күрсәтәләр. Дуслык мотивын гәүдәләндергән шигырьләр циклы лирик геройның нечкә күңелле, тормышта рухи таянычка мохтаҗ, драматик шәхес булуын дәлилли.

Билгеле булганча, «тоткын» темасының Шәрекъ, Гареб әдәбиятларында бай традициясе бар. XX йөз башында аңа татар шагыйрьләре дә мөрәҗәгать итә. Әдипләр «тоткын», «мәхбүс» темасын аның Көнчыгыштагы формаларына, Көнбатыш поэзиясендәге традицияләренә таянып, XX йөз башындагы татар әдәбияты алдында торган идея-эстетик бурычлар яктылыгында дәвам иттерәләр һәм үстерәләр. Шушы мотив М.Фәйзи шигъриятенә дә килеп керә һәм 1914 елда язылган үзенчәлекле төзелешле «Тоткын» шигырендә гәүдәләнеш таба. Г.Тукай, С.Сүнчәләй һ.б.ларның рус, Гареб әдәбиятларыннан тәрҗемә ителгән әсәрләреннән аермалы буларак, «уктай үткен», «зур күңелле», «ир йөрәкле» тоткын милли тормышка, халыкка тагын да якынайтыла:

Басты яшьлек дәвереӊ иң изге алтын тәхетенә,
Икте гомер, түкте нурлар халкының яшь бәхетенә.
Чын күңелдән ихтирам саклар асыл зат – бүз бала,
Халкына һәм илгә хезмәткә мәхәббәт кузгала.

Халыкка мәгърифәт тарату, илгә хезмәт юлында ул киртәләргә, каршылыкларга очрый һәм зинданга ябыла. Өч ел инде тоткынлыкта

изелә, утсыз җәһәннәмдә яна, чылбыр газабы чигә. Тоткынны фаҗигале язмышка дучар иткән көчләр «карга», «боз йөрәк», «канлы кул», «ямьсез эссе җилләр», «төтен» һ.б. шартлы-романтик, экспрессионистик сурәтлелек ярдәмендә күрсәтелә:

Бәдбәхет язмыш рәхимсез, боз йөрәк ул, канлы иде,
Өзде тамырын саф чәчәкнең, алды чорнап, салды кул.
Исте ямьсез эссе җилләр, кипте күлләр, җитте төн,
Шиңде гөлләр, сүнде нурлар, каплаган бәхетен төтен.

Лирик чигенештә егеткә «матур наз кызлары»ның тирән психологик нечкәлек белән тасвирланган мәхәббәте, иректә яшәү ләззәтләре тоткынның рухи халәтен тагын да киеренкеләндерә, караңгы, шыксыз чынбарлык белән аның конфликтын тирәнәйтә төшә. Әсәрдә шагыйрь иҗтимагый гаделсезлекләргә, патша самодержавиесенең милли колониаль сәясәтенә ишарә ясый, шул вакытта шигырь социаль явызлыкка, кеше бәхетен җимерүче көчләргә каршы тирән нәфрәт белән сугарылган.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң М.Фәйзинең лирика төрендә иҗаты сүлпәнәя. Шагыйрь «Куанычлы хәбәр», «Менә кызыл чәчәкләрне», «Их, нинди күңелле» һ.б. әсәрләрендә ирекле, матур тормыш өчен көрәш юлына баскан лирик геройның күтәренке хисләрен, өмет-хыялларын гәүдәләндерә.

М.Фәйзи поэзиясе милли шигъриятнең романтик юнәлешенә карый. Аның әсәрләре тематик төрлелек, сурәтләү чараларының байлыгы белән аерылып тора. Шагыйрьнең әсәрләрендә Рус-Аурупа әдәбиятлары тәэсиренә караганда, замандаш каләмдәшләренең йогынтысы көчлерәк күзәтелә һәм ул әдипнең үзенчәлекле сыйфаты буларак та ассызыклана ала. Аеруча Г.Тукай шигъриятендә, шагыйрьнең яшәү үрнәгендә М.Фәйзи үзенә рухи таяныч таба. Язучы лирикасында табигать матурлыгын, авыл, крестьян егет-кызларының күңел сафлыгын, гадилеген, мәхәббәт хисләрен һәм хезмәт романтикасын җырлау кызыл җеп булып сузыла. Аның бер өлкем шигырьләрендә тормыш-яшәеш проблемалары, экзистенциаль мотивлар калкытып куела. Бәхет, рәхәтлеккә омтылып та, аның урынына газапланып яшәүгә дучар ителгән лирик герой җир тормышын кире кагу баскычына күтәрелеп, аны ләгънәтли һәм каһәрли. Аерым әсәрләрендә дөньявилыкта сызланган лирик «мин», аны рәхәтлеккә ирештергән үлемгә, җәннәткә мәдхия укый. Әсәрләрендәге сүз-сурәт, алым-чаралар

катламы да төп фикерне белдерүгә буйсындырыла. Сурәтлелекне баету юлларын ул фольклордан да, телдән дә, музыкадан да, дини мифологиядән дә эзли. М.Фәйзи Тукай чоры поэзиясенең лаеклы бер вәкиле буларак санылырга хаклы, шагыйрь иҗатында индивидуаль сыйфатлар булуга карамастан, ул татар поэзиясенең гомумхәрәкәтеннән аерылгысыз. Аның шигърияте татар халкының рухи хәзинәсенә әверелгән классик драмалар язу юлында мөһим бер этап та булып тора.

## Сораулар һәм биремнәр

1. М.Фәйзи шигъриятендә төп мотивларны барлагыз.
2. Шагыйрь поэзиясендә лирик герой кичерешләре төрлелеген билгеләгез.
3. М.Фәйзинең авыл мотивын гәүдәләндергән шигырьләрендә алымнар һәм тасвирый чараларны күрсәтегез.
4. Әдип шигъри иҗатында нинди традицион һәм яңа образларны файдалана?
5. Экзистенциаль мотивлар сурәтләнгән шигырьләрдә лирик геройның сызлану сәбәпләрен ачыклагыз.
6. Лирик геройның күңел дөньясын бирүдә М.Фәйзи каләменә нинди үзенчәлекләр хас?
7. М.Фәйзи лирикасы татар шигъриятенең кайсы юнәлешенә карый? Фикерегезне дәлилләгез.

## Контроль эш темалары

1. М.Фәйзи шигъриятендә авыл культы.
2. Шагыйрь әсәрләрендә физик хезмәт романтикасы.
3. Әдип лирикасында яшьләр темасы.
4. М.Фәйзи иҗатында Г.Тукай.
5. М.Фәйзи поэзиясендә экзистенциаль мотивлар.
6. М.Фәйзи шигъриятендә интертекстуальлек.
7. Шагыйрь иҗатында мәхәббәт мотивы.
8. М.Фәйзи – фольклорчы.
9. Шагыйрь әсәрләрендә җыр, музыка культы.

**Гамәли дәрес. Тема: М.Фәйзи шигърияте**

1. М.Фәйзинең күпкырлы эшчәнлеге. Язучы рухи мирасында жанр төрлелеге: шигырь, поэма, хикәя, драма, көндәлек – хатирә һ.б. Аның халык җырларын барлауга һәм туплауга керткән өлеше.
2. Әдип поэзиясендә романтик эстетика атрибутларының чагылышы. Нечкә күңелле, моңлы, матурлыкка гашыйк лирик герой. Иҗатында мотивлар төрлелеге («Хәйран булам», «Табигать манзарасы», «Гыйшык», «Егетләр», «Печән чапканда» һ.б.).
3. Шагыйрь шигъриятендә әдәби бәйләнешләр, замандашлары белән уртак сыйфатлар: Г.Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ш.Бабич иҗатларының йогынтысы; («Габдулла әфәнде Тукаев наменә», «Егет илә кыз», «Фәрештә», «Зарлану» һ.б.).
4. М.Фәйзинең шигъри иҗатында экзистенциаль мотивлар, фәлсәфи фикерләр, дини-суфичыл традицияләрнең чагылышы. Автор мөрәҗәгать иткән алымнар һәм образлы сүз, тасвирый чаралар («Үз иркемә куй», «Соңгы теләк», «Рәхәт кайда», «Бәхет», «Чын дус» һ.б.).

**Текстлар**

1. Фәйзи М. Ил корабын җил сөрә: ХХ йөз башы татар поэзиясе / Төз.-ред.: Р. Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2001. – 175-177 б.
2. Татар шигърияте: ХХ гасыр башы / Төз.: З.Рәмиев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 296-303 б.
3. Фәйзи М. Минем шигырьләрем. – Казан: Матбагаи Кәримия, 1912. – 16 б.
4. Фәйзи М. Яшь күңел. – Казан: Өмет, 1913. – 24 б.
5. Фәйзи М. Сайланма әсәрләр. 2 томда. 1 –том /Пьесалар, шигырьләр, халык җырлары/. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1957.  – 360 б.
6. Фәйзи М. Әсәрләр /Төзүче һәм кереш мәкалә авторы Т.Гыйлаҗев./. – Казан: Мәгариф, 2007. – 32-73 б.

**Әдәбият**

1. Гыйлаҗев Т. Мирхәйдәр Фәйзи шигъриятенең идея-эстетик үзенчәлекләре // Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – 171-178 б.

2. Гыйлаҗев Т. Мирхәйдәр Фәйзи шигъриятендә фәлсәфи мотивлар // Фәнни язмалар. – 2006. – Казан: Казан дәүләт университеты нәшрияты. – 2007. – 147-153 б.
3. Нуруллин И. Мирхәйдәр Фәйзи // XX йөз башы татар әдәбияты: Урта мәктәп укытучылары һәм югары класс укытучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1982. – 261-264 б.
4. Халит Г., Шәйдуллин С. Унынчы еллар поэзиясе // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-том / XX гасыр башы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – 234-267 б.
5. Ханзафаров М. Мирхәйдәр Фәйзи // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-том / XX гасыр башы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – 422-424 б.

## М.Фәйзинең 1910 еллар драматургиясендә конфликт һәм характерлар

М.Фәйзи 1911-1912 елларда матур әдәбиятның драматургия төрендә нәтиҗәле эшли башлый һәм әдәби хәзинәбезне баетырлык әсәрләр тудырып, язучы буларак җитлегү чорына аяк баса.

Әдипнең беренче оригинал әсәре булган «Яшьләр алдатмыйлар» (1911) комедиясендә азгынлыгы аркасында яшьләр корган тозакка эләккән Гали мулланың көлкеле хәле сурәтләнә. Вакыйгалар Гали мулла өендә бара. Беренче күренештә Мәгърүфә монологында сизелә башлаган үзәк каршылык икенче күренештәге Гали мулла белән Сәлимә арасындагы сөйләшүдә ачыкланып бетә: ул кадим Гали мулла белән Шакир мөгаллим арасында. Аны яңалык белән искелек арасындагы каршылык дип бәяләргә мөмкин.

Комедиядә төп конфликтны тирәнәйтеп, мулланың кимчелекле сыйфатларын тирәнрәк ача торган ярдәмче каршылыклар да бар. Сәлимә иренең кырын эшләрен сизенеп, аның ялгызын гына асрау, хезмәтче кызлар белән калдырырга теләми. Яшьләргә каршы көрәштә берләшкән Гали мулла белән Сәлимә арасындагы ярдәмче каршылык ир белән хатын арасында ышаныч булмауны ача.

Гали мулла белән аның кызы Мәгърүфә арасындагы каршылык аталар белән балаларның милли чынбарлыкка мөнәсәбәтнең, бәянең төрлелеген, яшьләрнең аек акылын күрсәтә. Мәгърүфәнең «Хатыныңа хыянәт итеп, син асраулар белән уйнап йөрисең, динчелек исеме күтәреп, суфилык сатып, яңа фикерләрне сүгеп, үзеңнең шәригать буенча йөрүең шушымыни?» дигән сүзләрендә дин битлеге астына яшеренеп, суфи булып йөргән Гали муллага чыгарылган иң зур хөкем яңгырый.

Соңгы күренештә яшьләр ятьмәсенә эләгеп, көлке хәлгә калган Гали мулланың куркаклыгы, икейөзлелеге фаш ителә. Халык арасында тәүфыйкълы, әхлаклы булып күренергә тырышкан мулла чын йөзе – азгынлыгы, йөгәнсезлеге ачылудан куркып, үзе авылдан куарга йөргән җәдит Шакир мөгаллимгә кызын кияүгә бирергә мәҗбүр була.

Комедия татар тормышының актуаль, мөһим мәсьәләләрен күтәрә. Гали хәзрәт белән Шакир арасындагы үзәк каршылык татар зыялылар катлавы - руханиларның бер төркеменә бәя бирә. Алар – кадим, икейөзле,

кире, азгын. Автор мондыйларны татар тормышын үзгәртеп коруда, милли алгарышта башлык, җитәкче итеп булмый дигән фикер үткәрә. Ата-ана – кыз каршылыгында шәхес иреге, никах иреге, гаиләдә, җәмгыятьтә хатын-кыз урыны мәсьәләләре дә калкып чыга. М.Фәйзи Гали мулланың тискәре сыйфатларын фаш итеп, милли чынбарлыкны алардан арындырырга, чистартырга тели. Шакир авторның уңай идеалын гәүдәләндерсә дә, ул әле драматург идея-фикерләрен йөртүче генә булып чыгыш ясый, абстракт формада гына бирелгән. Мулланың көлкеле хәлен сурәтләү өчен, ул аның бозыклыгын чамадан тыш арттыра. Асрау кыз дип белеп ир-егетнең кулларын тотуы, битеннән үбеп алу, аңа мәдхия уку детальләре Гали мулла характерына яңа сызык өсти, аның көлкеле хәлен көчәйтә. «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясендә көлүнең юмор төре өстенлек итә. Соңгы күренештә Гали хәзрәтнең азгынлыгыннан ачы итеп көлү уйланылса да, аңа юмор килеп кушыла.

Әдипнең икенче дәвер иҗаты чор әдәби, гыйльми-нәзари эзләнүләре белән тыгыз бәйләнештә үсә. Мәгълүм булганча, унынчы еллар татар драматургиясендә чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндерүнең романтик төре өстенлек итә башлый. Ул гына түгел, тормыш-чынбарлыкның төрле катламнарына үтеп кереп, аны аңлау, танып белү омтылышы көчәю; кеше, яшәеш, үлем һәм яшәү мәсьәләләренә игътибар арту; гомернең чикләнгәнлеген, галәм, Алла каршында кешенең кечкенәлеген, көчсезлеген төшенү татар әдипләренең сәнгатьчә фикерләүдәге реализм, романтизм төрләреннән тыш модернизм, экзистенциализм кебек әдәби, фәлсәфи агымнарга мөрәҗәгать итүенә китерә. Бу үзенчәлек М.Фәйзи иҗатында да чагыла.  Язучы кеше җанын, рухи бергәләнүләрен, күңел сыкрануларын гәүдәләндерүдә романтизм принципларына, алым-чараларына өстенлек бирсә дә, аның бу чор иҗаты сентиментализм, модернизм билгеләре, сурәтләре белән баетыла.

Драматург «Кызганыч» (1913) әсәрендә фаҗигале мәхәббәт тарихын сурәтләүгә алына. Вакыйгалар яхшы фикерле дип тәкъдим ителгән Сөләйман бай гаиләсендә бара. Беренче күренештә мелодраманың үзәк конфликты ачыклана: Сөләйман бай белән аның улы Заһид арасында барлыкка килә. Сәбәбе – Сөләйман байның улын Гани бай кызына өйләндерү теләге. Ә Заһид әтисенең кызлар мәдрәсәсендә мөгаллимә булып эшләүче Гәүһәрне ярата. Ә.Закирҗанов хезмәтендә мелодраманың

үзәк конфликты пьесада күтәрелгән проблемалар белән тыгыз бәйләнештә ачыклана: «Үзәктә шәхес иреге, кешенең мәхәббәткә һәм бәхеткә хокукы мәсьәләсе тора. Вакыйгалар барышында ул милләт язмышы проблемасы белән эзлекле ялганып китә… Бер яктан, күтәрелгән мәсьәләләр геройларның шәхси свйфатларына бәйле булса, икенче яктан, ирек, бәхет төшенчәләре социаль тигезлек дигән «стена»га бәрелеп юкка чыгалар. Әсәрнең төп конфликты, беренче чиратта, Сөләйман-Заһид каршылыгында хәл ителә» [Закирҗанов, 1997; 47]. Шушы каршылык бер-берсен яратучы яшьләр күңелендә тирән драматик кичерешләр уята. Кызларны көчләп кияүгә бирү, угылларны көчләп өйләндерү заманының үтеп барганлыгын аңлаган Сөләйман бай, үзенең максатын яшерү өчен, гакыл белән өйләнү фәлсәфәсен тәкъдим итеп карый, әмма ул Заһид тарафыннан кире кагыла.

Заһид әтисе Сөләйманның яшьлектәге мәгънәсез күңел ачулары урынына китапларын, бозыклык юлындагы иптәшләре урынына «укыган, аңлы, мәгърифәтле» дусларын каршы куя. Бу каршылыкта татар яшьләре арасында бозык, надан, азгын егетләрдән тыш милләтнең таянычы булырдай укымышлы, тәрбияле, әхлаклы яшьләр дә булуы раслана. Тормышны аңлау, үз-үзеңә һәм тирә-юньгә дөрес бәя бирү, яшәешнең мәгънәсен билгеләү турындагы карашлар әсәрнең фәлсәфи катламын да барлыкка китерә.

Җиңелүен аңлаган Сөләйман бай ике арада туган каршылыкны үз файдасына хәл итүнең соңгы чарасына керешә: тиешле мал-мөлкәттән улын мәхрүм итеп, өйдән куып чыгару белән яный. Атаның әлеге эш-гамәле яшь каһарманнарның характерын икенче яктан ачып җибәрә: аларның яңа күңел бәргәләнүләрен, өстәмә каршылыкларны тудыруга юл ача. Мәхәббәтне бар нәрсәдән дә өстен куйган яшьләр, ата тарафыннан куелган шартка әһәмият бирмичә өйләнешеп, үз теләкләренә ирешерләр иде. Әмма мирас милләткә хезмәт итү өчен, халык файдасына тоту өчен кирәк. Күренә ки, үзәк каршылык геройларның милләткә хезмәткә итү, халык турында уйланулары тудырган иҗтимагый-милли эчтәлекле ярдәмче каршылыклар белән тирәнәйтелә.

Беренче пәрдәнең беренче-икенче мәҗлесләрендә үк фикер-караш каршылыклары төсмерләнә башлый. Пьесада төп һәм ярдәмче каршылыкларның тууына сәбәпче булган никах иреге мәсьәләсенә

нисбәтле Сөләйман бай белән аның хатыны Мөнирә арасында беренче ярдәмче каршылык формалаша. Мөнирә, Гәүһәрдән аерып, икенче кызга өйләндерүнең Заһидка бәхет, шатлык китерүенә шикләнеп карый. Ике арадагы бәхәстә яңаруга борылган татар җәмгыятенә бәя дә яңгырап китә. Мөнирәнең «Көчләп күндерүләр белән бу заманда эш итү кыен. Халыкның теленә калырга кирәк, хәзер инде ирләрне түгел, кызларны да көчләп бирүләр бетеп бара» дигән сүзләрендә милли чынбарлыкның искергән гореф-гадәтләре кире кагыла, кешенең шәхес хөрлеге, никах иреге яклана. Шулай ук Сөләйман байның, тәҗрибә туплап, акыл утыртып, 25 яшьләр тирәсендә өйләнү фәлсәфәсенә яшьлектәге мәхәббәтнең дә бәхетле гаилә коруга нигез була алуы турындагы фикер каршы куела.

Икенче ярдәмче каршылыкны Заһид күңелендәге акыл һәм хис тартышы тудыра. Аның Гәүһәрне, үз янына чакырып, икесе бергә булу теләгенә, Гәүһәр китсә, милләт балаларының шәфкатьле «ана»дан мәхрүм калулары хакындагы фикер каршы төшә: «Ни дим, Гәүһәр?.. Ни дим?.. менә мин шул икенең арасында изеләм, синнән башка миңа сәгадәт юк. Синнән башка мәдрәсә балаларына яхшы тәрбия юк», – дип сызлана ул.

Өченче ярдәмче каршылык Гәүһәр белән Сөләйман бай арасында. Киләчәктә халыкка хезмәт итү юлында кирәк булачак мирастан Заһидны мәхрүм итү белән Гәүһәрне куркытып, Сөләйман бай үз дигәненә ирешә. Бу ярдәмче бәрелештә, үз теләгенә ирешү өчен, әхлак кагыйдәләре аша сикереп, теләсә нинди начарлыкларга әзер Сөләйман байның куркыныч, түбән җанлы кеше икәнлеге ачыклана.

Чарасызлык баскычында торган Гәүһәрнең, байлыктан, акчадан, мөгаллимлектән баш тартып, Заһид белән кавышып бәхетле булу мөмкинлеге турындагы күңел бәргәләнүләрендә, иҗтимагый вазифа һәм хис көрәшендә дүртенче ярдәмче каршылык оеша: «Малдан да, мөгаллимлектән дә кул селтәгәндә, без икәү кавышып мәсгуд (бәхетле) булачак идек. Бу мәсгудият бары икебезгә генә махсус булачак иде. Әмма бу халык өчен үз бәхетебезне корбан итәбез... Халкыбызның хәзерге көндә акчага бик мохтаҗлыгын уйлап, дөньяда ясалачак туебызны ахирәткә кичектерәбез... Мәҗбүр булабыз...» Автор Гәүһәр фаҗигасендә язмыш, тәкъдирдән узмыш юк фәлсәфәсен төп сәбәп итеп күрсәтсә дә, татар җәмгыятендә хөкем сөргән иске гореф-гадәтләрне, тәртипләрне дә

тәнкыйтьли. Аның үзен корбан итүе аларга каршы нәфрәт, протест булып та яңгырый. Бу каршылык, яшьләрнең үз бәхетләрен халык өчен корбан итеп, иҗтимагый-милли мәнфәгатьләр файдасына чишелә. Әсәрдә өч ярдәмче – беренче, икенче һәм дүртенче каршылыкны иҗтимагый-милли эчтәлеккә ия булулары ягыннан төркемләргә дә мөмкин.

Заһид белән Сөләйман арасындагы үзәк конфликт Заһид һәм аның сөйгәне Гәүһәрнең үлеме белән чишелә. Яшьләр үз мәхәббәтләренә тугры калып, Заһидка бирелгән байлыкны милләт файдасына тоту хакында васыять әйтеп, үзләрен корбан итәләр. Мелодрама төп каһарманнарның үлеме белән тәмамланса да, ул үлем мәхәббәтнең, яшьләрнең мораль җиңүе булып аңлашыла. Мәхәббәт кеше, аның акыл үлчәүләренә, акча, байлык һәм гомумән бернинди киртәләргә дә буйсынмый торган серле көч, рух эше буларак тәкъдим ителә. Аннан соң бу чишелеш аркылы татар зыялы яшьләре арасында үз тормышларын милли алгарыш, татар халкы бәхете хакына корбан итәрдәй катлам  барлыгы турындагы фикер дә үткәрелә. Шул ук вакытта Гәүһәрнең үз-үзенә кул салыр алдыннан әйткән «Татар тормышының җитешсезлекләренә корбан булып, хәят баткаклыгыннан чыга алмый үләм» дигән сүзләрендә милли чынбарлыкның тискәре якларына нәфрәт яңгырый, аның үзгәрергә, яңарырга тиешлеге раслана.  Мелодрамадагы төп конфликт мәңгелек «аталар» һәм «балалар» тартышының чагылышы да булып тора.

Әсәр романтик эстетика кануннарына корылган, әмма ул сентиментализм билгеләре – хис культы, хат язышу детальләре, куертылган кичерешләр, түгелгән күз яшьләре, мул бирелгән аһ-зарлар, геройларның күңел-калеб кешеләре итеп бирелү һ.б. белән баетылган.

Әсәрнең өченче пәрдәсендәге бишенче мәҗлесендә Гәүһәрнең, дүртенче пәрдәнең беренче мәҗлесендәге Заһидның хис-кичерешләре сызлану фәлсәфәсе ярдәмендә гәүдәләндерелә. Үз язмышларын үзгәртә алмаудан, кавышудан өметләре өзелгән, рухлары сүнгән геройлар газап китергән залим, усал дөньяны ләгънәтлиләр. Аннан котылу юлы дип үлемне санаган каһарманнар сыкрыйлар, сызланалар. Бу күренешләргә әдипнең экзистенциализм агымы тәэсирендә иҗат ителгән «Бәхет», «Рәхәт кайда?», «Соңгы теләк» шигырьләрендәге мотивлар килеп кереп, каһарманнарның хис кичерешләрендә гәүдәләнеш таба. Заһидның үз һәм Гәүһәренең үлемендә тормышны гаепләү, үкенеч хисе шулкадәр көчле,

күңел бәргәләнүләрен, чарасызлыгын тирәнрәк белдерү өчен ул, кулына револьверын тоткан килеш, «Соңгы теләк» шигыреннән өзек көйли. Бу үзенчәлек И.Нуруллин тарафыннан да ассызыклана: «М.Фәйзи 1913 елның январенда «Кызганыч» исемле драмасын язып тәмам итә. Әсәр язучының лирикасы, аеруча «Яшь күңел» җыентыгы белән аваздаш. Биредә дә реаль чынбарлык, конкретрак әйтсәк, буржуаз җәмгыять белән романтик шәхес арасындагы каршылык гәүдәләнә» [Нуруллин, 1982; 266].

М.Фәйзинең исеме үк экзистенциаль яңгырашлы булган «Тәкъдирнең шаяруы» (1913) дигән драмасы да шушы дулкында язылган. Фаҗигале мәхәббәт тарихын гәүдәләндергән пьеса алдагысыннан әсәр сюжетының мәхәббәт өчпочмагы мотивына корылуы, үзәк конфликтның кешеләр арасында түгел, ә төп каһарманның эчке дөньясындагы акыл һәм хис каршылыгында оешуы ягыннан аерыла.

Пьесаның үзәк конфликтын эчке каршылык – Гыйсмәтнең Гөлшатны ярату хисе белән үз хатыны Мөршидәне җәлләү, кызгануга килеп кушылган ихтирам, зурлау хисләренең тартышы барлыкка китерә. Аның сәбәбе итеп яшьлектә, матурлыкка алданып, мәхәббәткә, гаилә кору мәсьәләсенә аек акыл белән карамыйча өйләнү күрсәтелә. Дөрес, беренче пәрдәнең дүртенче күренешендә Гыйсмәт аны иске татар тормышы, татар гадәте белән дә бәйләргә омтыла. «Кызганыч» мелодрамасындагы Сөләйман байның Заһидны Гәүһәрдән аеру өчен дәлил төсендә китергән акыл белән ярату, өйләнү фәлсәфәсе «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасында икенче мәгънәви яңгыраш ала. Әсәрдәге ярдәмче каршылыклар шушы проблема белән бәйләнгән.

Пьесаның үзәк конфликты берничә ярдәмче каршылык белән тирәнәйтелә. Гыйсмәт – Мөршидә каршылыгы гаилә башлыгының, үз хатынына вакытлы мавыгу буларак аңлатылган мәхәббәт хисенең сүрелеп, Гөлшатка гашыйк булуы нәтиҗәсендә туа. Газапланган, күңелләре сыкранган геройларның бу хәлгә бәяләре төрлечә: Мөршидә аны тәкъдир кушуы, Аллаһы тарафыннан җибәрелгән язмыш төсендә кабул итә. Ә Гыйсмәт үз хыянәтен мәхәббәтнең, рух эше булып, акылга, кеше ирегенә буйсынмый торган серле хис булуы белән бәйләп аңлата. Шушы каршылыкта калебнең акылга буйсынмавы, хатын-кызның көче, мәхәббәт хакына үзен корбан итә алуы, аның түземле, сабыр, олы йөрәкле була алуы, хатын-кызны тәрбияләү кебек мәсьәләләр күтәрелә. Гыйсмәтнең

«кызларны ир ризасы – Тәңре ризасы дип колакларына тукып үстерәләр бит», Мөршидәнең әнисе белән көрәшергә теләгән Гыйсмәткә: «Анда синнән кача торган кеше бар» дигән сүзләрендә хатын-кызны курчак итеп тәрбияләгән милли чынбарлыкның иске гореф-гадәтләренә, тәртипләренә тискәре бәя дә бирелеп уза. Автор тарафыннан тигез мәхәббәт булмаган гаиләдә бәхеткә дә, ямьгә дә, күңел тынычлыгына да урын юк дигән фәлсәфи фикер үткәрелә.

Гыйсмәт белән Мөршидә арасындагы каршылык икесен дә тирән күңел газапларына сала. Бу хәлдән чыгу юлын тапмаган, каршылыкның уңай чишелешен күрмәгән Мөршидәнең хис-тойгылары экзистенциализм сызыгында гәүдәләнә. Аның тарафыннан үлем шушы газап дөньясыннан котылуның бер юлы, чарасы буларак тәкъдим ителә. Мөршидәнең сызланулары Раббыга мөрәҗәгате белән көчәйтелә: ул үзен дөньяга яраткан Аллаһыга ризасызлык белдерә.

Киявенең башка хатын белән йөреп, халык арасында гайбәт чыгуга урын калдырган, хурлыкларга төшергән һәм иң мөһиме – кызын бәхетсез итүгә әрнегән, өзгәләнгән Әсма белән Гыйсмәт арасында икенче каршылык ачыклана. Моңа кадәр кызының сүзенә колак салып түзеп килгән Әсма кияве Гыйсмәткә үз уйлаганнарын әйтеп бирә. Биредә ана күңеле балада, бала күңеле далада дигән фәлсәфә дә яңгырап китә. Баланың кадере, бала хакы, ана хакы проблемалары күтәрелә. Аналарның дөньядагы бөтен шәфкатьләрне үзләренә җыюлары турында фикер раслана. Хатын-кызның бәхете ир-аттан тора дигән караш та ассызыклана.

Гыйсмәт белән Хәмит арасындагы каршылык нигезендә мәхәббәткә, гаилә кору мәсьәләсенә карашларның төрлелеге ята. Мәхәббәт, гыйшыкка ышанмаган Хәмит Мөршидәгә зур ихтирам белән карый, хәтта аны илаһилаштыра. Гыйсмәткә Гөлшат белән араны өзеп гаиләне саклап калырга киңәш итә. Ир белән хатын арасында мәхәббәтнең булмавына күңеле белән инанган Хәмит үз гаиләсен үрнәк итеп китерә: «Миңа мәхәббәт дигән нәрсә таныш түгел. Бер хатыным бар. Мин аңа гашыйк та түгел. Шулай да бик матур торабыз. Аннан башка бер кызга кызыгу ихтималым да юк». Шушы фикер өйләнергә йөргән яшь романтик Ваһап тарафыннан тагын бер кат дәлилләнә. Сөйгәне өчен барысын дә эшләргә әзер бу каһарман күңелне бер кешегә утырту, матурларны күргәч, күңелне җилкендермәү, тыеп калуның мөһимлеге турында сөйли. Автор яхшы

холыклы кешене сайлап, акыл белән корылган гаиләнең нигезе нык, ышанычлы була дигән фикерне раслый. Гыйсмәтнең күңел кичерешләренә, гаилә хәленә нисбәтле Хәмитнең «...син дөньяның төзелешен үзең уйлаганча дип белмә» дигән сүзләрендә авторның тормыш кануннары, аңлап-танып бетерү мөмкин булмаган яшәеш хакындагы фәлсәфи уйланулары, карашлары гәүдәләнә.

Үлем генә бу газаптан коткара ала дигән карашыннан кире кайтып, үз язмышы белән килешкән, ялгызлыкка дучар ителгән Мөршидәнең күңел дөньясында тагын бер ярдәмче каршылык туа. Озак икеләнүләрдән, күңел тартышуларыннан соң, мөнәсәбәте салкын булуга карамастан, аның янында яшәп, барлыгын тоеп кына булса да, үзен бәхетле хис иткән Мөршидә, Гыйсмәтне сөйгәне Гөлшат белән кавыштыру өчен, иреннән аерыла. Шәхси бәхетен иренең сәгадәтле тормышы хакына корбан итә. Бу каршылыкның хәл ителешендә Г.Исхакыйларның Сәгыйдәләренә тиңләшерлек Мөршидәнең олы, изге йөрәкле, саф күңелле, көчле хатын-кыз булуы турында фикер раслана.

Икенче пәрдәдә мулла тарафыннан аерылып, килен булып ике ел яшәгән йортыннан газапланып, хәсрәтле күз яшьләре белән саубуллашкан Мөршидәне кызганып, Гыйсмәт аның калуын үтенә, икенче кат никах белән хатынлыкка ала. Каршылык, беренче карашка, олы йөрәкле Мөршидә мәнфәгатьләрендә хәл ителгән кебек. Әмма Гөлшатны онытам дип үз күңелен алдаган, аңа йозак салырга омтылган Гыйсмәт үз хисләренең корбаны була. Гөлшатка гыйшык газабы, күңел тартышуы аны авыруга сабыштыра. Драманың финалында вакыйгалар куертылып, Гыйсмәт вафат була. Төп каршылык автор фикеренә укучыны алып килү белән хәл ителә.

Драманың кыйммәте, һичшиксез, мәхәббәт хисләрен зурлауда билгеләнә. Шул ук вакытта мәхәббәтнең куркыныч, җимергеч көчкә ия булуы турындагы фикер дә калкуландырыла кебек. Гыйшык һәм гаилә мәсьәләсен күтәреп, тигез мәхәббәткә корылмаган гаиләдә бәхетсезлек хөкем сөрә, тигезсез гыйшык гаилә бәхетен җимереп, кешеләрне газапка, кайгы-хәсрәткә сала, моң-зар белән тутыра, ялгызлыкка дучар итә дигән караш та үткәрелә. Автор өмет өзелү, яшәешне матурлаган мәхәббәтнең югалуы кешене сызлануларга китерә һәм кешеләрне чарасызлык

баскычына атлатып, аннан котылу чарасы буларак саналган үлемгә этәрә дигән экзистенциаль, фәлсәфи нәтиҗәләр дә ясый.

М.Фәйзинең 1913-1916 еллар иҗатында идея-эстетик үзгәрешләр барлыкка килә. Язучы драматургиясенең идея эчтәлеге яңара, сәнгати эшләнеше ягыннан яңа сыйфатларга байый. Әдип иҗатында борылышны күрсәткән «Авыл бәйрәме» пьесасы 1915 елда языла. Драматург алдагы әсәрләреннән аермалы буларак, бу пьесасында халык тормышын, гади авыл яшьләрен, аларның теләк-омтылышларын сурәтләүгә алына. Әсәрнең конфликты заман әдәбиятында киң чагылган «аталар» һәм «балалар» каршылыгы яссылыгында барлыкка килә. Мәгълүм булганча, мондый типтагы каршылык М.Фәйзинең мәзәк ситуациягә корылган «Яшьләр алдатмыйлар» (1911) комедиясендә дә күзәтелгән иде. «Авыл бәйрәме» пьесасында автор конфликтның барлыкка килү сәбәпләрен киңрәк ала, авыл тормышында хөкем сөргән иске тәртипләрне, аның алгарышына комачаулаган көчләрне тулырак күрсәтүгә ирешә. Дөрес, искелеккә, «аталар»га каршы көрәш мәгърифәтчеләрчә шәрехләнә: уку, белем алу, яңа һөнәрләр үзләштерү белән бәйләп аңлатыла.

Каладан авылга кайткан укымышлы, әхлаклы һәм тәрбияле Заһит тирәсенә тупланган авыл яшьләренең көрәше дә иске татар тормышын асылыннан үзгәртеп кору идеясе белән бәйле булмыйча, аларның кичке җырлы-биюле уеннарына, уен коралларында уйнауларына каршы килүче дин әһелләренең, олы буын кешеләренең эш-гамәләреннән ризасызлыкны, шәхес бунтын хәтерләтә. Шуңа күрә бу әсәрдә «аталар» белән «балалар» каршылыгы «картлык» белән «яшьлек»нең тартышы рәвешендә үзенчәлекле гәүдәләнеш ала.

«Авыл бәйрәме» пьесасының сәнгатьчә эшләнешендә яңа тенденция буларак фольклор эстетикасы күзәтелә. Билгеле булганча, бу елларда М.Фәйзи халык тормышын, көнитешен, яшәү шартларын, этнографиясен, гореф-гадәтләрен тирәнтен өйрәнә, халыкның җанлы сөйләменә колак сала. Халык иҗаты материалларын, аеруча халык җырларын туплап, аларны фәнни анализлау омтылышы ясый. Җырларны үз әдәби әсәрләрендә иркен файдалана, сурәтләнгән вакыйгаларны җырлар белән тыгыз үреп сурәтли башлый. Шул рәвешле, аның идея-эстетик вазифасын киңәйтә. Бу сыйфат үз нәүбәтендә драма әсәренең жанр табигатенә тәэсир ясый. «Авыл бәйрәме» жанр ягыннан музыкаль комедия булып тора.

Автор әсәрдә яңа алымнар, поэтик бизәкләргә мөрәҗәгать итә. Аның бу еллар иҗатында әдәби әсәрнең мәгънәви кисәкләрен бер үзәккә туплаган бер детальне әдәби алым буларак файдалану күзәтелә башлый. Ул вазифаны драматургның романтик фикерләвеннән килә торган шартлы-символик образлар, пьесаларның идея эчтәлеге белән тыгыз бәйләнгән җырлар үти. «Авыл бәйрәме» драмасында исә «бәйрәм» традицион символик образы рухи-мәдәни яңарышка юл тоткан авыл тормышына, «табигый кеше» концепциясе яктылыгында сәнгатьчә гәүдәләндерелгән авыл яшьләренең яшәешенә, әхлакый сафлыгына һәм үзара мөнәсәбәтләрнең матурлыгына ишарә ясый.

Драматургның «Галиябану» драмасы 1916 елда язылa. Гәрчә әсәр мәңгелек темаларның берсе – мәхәббәт темасын гәүдәләндереп, сюжеты традицион мәхәббәт өчпочмагы мотивына корылса да, әдип иҗатының гына түгел, ә татар әдәбиятының җитди казанышы – таҗы, бизәге булып тора.

Сюжетның экспозициясе булып килгән әсәрнең беренче пәрдәсендә драматург Галиябану, аның әтисе, әнисе һәм каршылыкка керәчәк каһарманнар – Хәлил һәм Исмәгыйль белән таныштыра. Аларның эш-гамәлләре, теләк-омтылышлары, үз-үзләрен тотышлары, характер сыйфатлары хакында белешмә бирә. Бәдри – авылда үз көче белән көн күрүче тырыш, укый-яза белә торган крестьян. Аның хуҗалыгы нык: аты бар, кирәк вакытта базарга чыгарып сата алырлык икмәге дә юк түгел, хезмәтче тота. Сөйләшүләренә, үзара мөнәсәбәтләренә караганда, хатынын ихтирам итеп яши. Күңеленең бер почмагына матди хәлен ныгытып, кешеләр арасында үз абруен күтәрү теләге дә яшеренгән. Җае да чыгып тора: авылда матурлыгы, «акылы, фигыле, белеме, җитезлеге, үткерлеге» белән дан тоткан кызы Галиябануга байлыгы белән тирә-якны дер селкетеп торган Исмәгыйль күз атып, өйләнү теләге белән йөри. Менә шушы хәл драмада аңлашылмаучылыкка юл ача, хыял белән чынбарлык каршылыгын тудыра. Хәлил турында алдагы күренешләрдән алынган мәгълүмат яучы Бәдига тарафыннан арттыру алымы ярдәмендә тагын да киңәйтелә: «егет хан кызын димләсәң дә оят китерерлек түгел, ышанычлы, бик әйбәт», «авылда бер дип әйтерлек». Икенче пәрдәдә төп каршылыкның беренче адымы – төенләнеш ясала: әсәрне композицион яктан оештыруда, геройларның холык-фигылен, күңел кичерешләрен

ачуда зур роль уйнаган аңлашылмаучылык аркасында Бәдри белән Галимә, яучы Бәдиганы Исмәгыйльдән дип белеп, шатланып Галиябануны кияүгә бирергә ризалык белдерәләр.

Беренче-икенче пәрдәләрдә драманың үзәк каршылыгы ачыкланып бетә: ул Хәлил белән Исмәгыйль арасында барлыкка килә. Хәлил белән Исмәгыйль каршылыгын шәхси сәбәп – Галиябануга өйләнү теләге тудыра. Аның нигезендә Хәлилнең мәхәббәт хисе белән Исмәгыйльдәге «кыз минеке булырга тиеш» дигән теләк – ышанычның бәрелеше ята.

Төенләнештән соң сюжет тиз үсеп, вакыйгалар куерып, катнашучы геройлар арасында мөнәсәбәтләр киеренкеләнеп китә, каһарманнарның драматик кичерешләренә фаҗигалелек өстәлә. Галиябануның Хәлилгә ярәшелүен ишеткәннән соң, күңелендә тискәре хисләр өермәсе уйнаган Исмәгыйль су буенда Галиябануның юлына каршы төшә. Үз сүзләре белән әйткәндә, «синең кулыңа су салырга ярамаслык малай» белән Галиябануның вәгъдәләшүе Исмәгыйльнең минминлегенә тия, хисләре акылын томалый. Ул – мәрхәмәтсез, усал; байлык аны рухи яктан имгәтеп, башкаларны үзенә буйсындырып, кешеләрнең мәнфәгатьләре белән санлашмыйча яшәргә өйрәткән. «Ачу килгән вакытта Ходай истән чыга» дигән сүзләре Исмәгыйльнең үз максатына ирешү юлында гореф-гадәт, әхлак нормалары белән генә түгел, хәтта дини кануннар белән исәпләшмәвен раслый. Исмәгыйльнең тупас, дорфа мөнәсәбәтенә Галиябану үзенең күңел яхшылыгын каршы куеп карый, әмма ул уңай нәтиҗәгә китерми. Героиняның ялварулы үтенече, кансыз, ерткыч Исмәгыйльнең каты күңеленә юл таба алмыйча, янәдән янауга, куркытуга очрый. Алар арасындагы каршылык кешене кимсетү һәм мыскыллауга бәйле туа. Әлеге бәрелештә мәхәббәт хисе Исмәгыйльнең «кызыксыз байлыгы»ннан өстен куела, теләсә нинди рәнҗетүләрне, түбәнлекләрне җиңәрлек мәхәббәт хисенә дан җырлана.

Галиябануны үзенеке итә алмавына шикләнгән Исмәгыйль Бәдри йортына килә. Дүртенче пәрдәнең икенче күренешендә ачыкланган ярдәмче каршылыкта үз кызларын Исмәгыйльгә ярәштек дип инанган Бәдри белән Галимәнең күзләре ачыла, алар үзләренең ялгышу-алдануларын аңлыйлар. Бу каршылык эчендә Исмәгыйль белән Бәдринең холыклары яңа штрих-сызыклар белән тулыландырыла. Исмәгыйльнең рәхимсезлеге, мәкерлеге бу күренештә тагын да көчәйтелә, соңгы чиккә

җиткерелә. Галиябануның Хәлилгә ярәшелүен: «Моңарчы алам дип йөреп, инде читкә җибәрү... үлем белән бер», - дип кабул иткән Исмәгыйль байлыгын эшкә җигә. Туйлыкка, мәһәрләрдән тыш мең сум акча вәгъдә итеп, Бәдрине бик тиз үз ягына аудара. Бу каршылык эчендә Бәдринең аумалы табигате, байлыкны үз кызы бәхетеннән дә өстен куюы ачыклана.

Икенче бәрелештә үк өченче каршылыкның тууына җирлек әзерләнә. Бәдри белән Галиябану арасында оешкан каршылык моңа кадәр тыныч, бер-берсенә ихтирам хисе белән, матур гына яшәп яткан гаилә тормышына ямьсез күренешләр алып керә, ир-хатын, ата-бала мөнәсәбәтләре бозыла. Сәбәбе – ата-ана һәм Галиябану арасындагы аңлашылмаучылыкның ачыклануы, аннан соң туйдан киләчәк акчадан Бәдринең мәхрүм калу куркынычы. Меңнәр белән аңы томаланган Бәдри, мәҗбүриләп, куркытып, алай да барып чыкмагач, кыйнап, Галиябануның ризалыгын алуга ирешә. Автор бу каршылык аша кеше характерындагы комсызлык, акча-байлыкка омтылыш гаилә тормышын гарипләндерә, кеше бәхетен, гомумкешелек кыйммәтләрне җимерә дигән фикерне раслый.

Бәдринең ризалыгын алудан өметләре өзелгән Хәлил белән Галиябану үз бәхетләре өчен көрәшүнең соңгы юлын – яшерен рәвештә никах укытуны сайлыйлар. Мәхәббәт көченнән куркып, төнлә белән икенче тапкыр Бәдриләр йортына килгән Исмәгыйль яшьләрнең бу адымына каршы төшә. Хәлил белән Исмәгыйль очрашкан күренеш сюжетның кульминацион ноктасы булып тора. Бар нәрсәне үз файдасына хәл итәргә гадәтләнгән Исмәгыйль, Галиябануның башка кешегә кияүгә чыгуы белән һич кенә килешергә теләмичә, Хәлилне револьвердан атып үтерә. Бу каршылыкта ике каһарман да яңа яктан ачылып китәләр. Күңеле, эш-гамәлләре гел яхшыда, изгелектә булган Хәлил, миһербансыз Исмәгыйльгә ышаныч белдереп, кулына төшкән револьверны җиргә ташлый. Бу Хәлилнең беркатлылыгы, тәҗрибәсезлеге турында сөйли. Тәүфыйксыз, «бозык» дигән ат алган Исмәгыйльнең дә характерына яңа детальләр өстәлә. Ул, Хәлил белән Галиябануның мәхәббәт хисләре һәм намус, вөҗдан кебек гомумкешелек кыйммәтләр алдында җиңелеп, үзенең Хәлилне атып үтерүен танырга мәҗбүр була. Димәк, Исмәгыйльдә әле кешелек сыйфатлары үлеп бетмәгән. Үзәк каршылыкның фаҗигале

чишелеше тамашачы күңелендә Исмәгыйльне гаепләү, аңа нәфрәт, ә Хәлилгә теләктәшлек, кызгану хисләре уята.

Автор кеше бәхете мәсьәләсен, аның нинди генә шартларда яшәвенә карамастан, зур, җитди проблема итеп күтәрә. Җир йөзендә яшәгән барлык кешеләр дә омтылган бу кыйммәт, мәхәббәт, кешеләр, туганнар, кан-кардәшләр арасындагы матур мөнәсәбәтләр яклауга һәм саклауга мохтаҗ дигән фикер үткәрелә; саф, керсез мәхәббәт хисләренә дан җырлана. Акча, мал-мөлкәтнең, байлыкның, акыл һәм зыялылык белән эш иткәндә генә, кешегә, халыкка һәм милләткә файда китерүе раслана.

«Галиябану» музыкаль драмасының сәнгатьчә эшләнеше дә бик югары. Реализм һәм романтизм синтезы рәвешендә язылган пьесада музыканың роле, идея-эстетик вазифасы үзгәрә, ул очраклы бизәк төсендә генә түгел, ә пьеса эчтәлегенең тукымасын хасил итә. Әсәрнең мәгънәви кисәкләрен бер үзәккә туплаган әдәби деталь буларак кулланыла. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Г.Ибраһимов әдәби әсәрнең яңа сыйфаты хакында болай дип яза: «Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны, бер иттифакый зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә (эчтәлек – Г.Т.) кыйлып, кертүедер. Буны «Галиябану» башлап җибәрде. ... Менә шундый хасиятләре белән «Галиябану» бездә ялгыз урында тора, яңа бер баб яки, зуррак тәгъбир булса да, әйтик, драмалар галәмендә яңа мәктәп ача һәм, шулар аркасында бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала» [Ибраһимов, 1978: 303]. М.Ибраһимов тарафыннан бу караш конкретлаштырылып, иҗади үстерелә. Галим пьесада җырның идея-эстетик вазифасын әдәби әсәрне композицион яктан оештыруда, вакыйгаларны хәрәкәт иттерүдә билгели. Аның карашынча, җыр драмада «тышкы коллизияләр» белән янәшә үскән эчке хәрәкәтне барлыкка китерә: «М.Фәйзи драмасында тышкы каршылыклар белән янәшә эчке каршылыклар да бар. Алар тышкы каршылыкларга янәшә үсә. Автор коллизияләрне «Галиябану» җырындагы үтәли мотив (лейтмотив) ярдәмендә ача» [Ибраһимов, 2005; 45]. М.Ибраһимов билгеләгәнчә, Галиябануның эмоциональ халәте һәм хисләр үзгәреше барлыкка китергән эчке хәрәкәт җырлар аша тәэмин ителә, «җыр хисләр белдерү чарасына әверелә». Аннан соң әсәрнең финалында яңгыраган «Галиябану» көе, героиняның эчке халәте белән

генә бәйле булмыйча, тормыштагы мәңгелек сагышка, моңга ишарә ясый. Бу очракта ул хәрәкәттәге хис, кичерешне түгел, ә «тотрыклы, стабиль, субстанциаль» халәтне белдерүгә хезмәт итә. «Музыкаль образ, безнең фикеребезчә, монда символик табигатьле, – дип яза мәкалә авторы. – Аның мәгънәсе ахырга кадәр ачыкланмаган, ул күпмәгънәле» [Ибраһимов, 2005; 46]. Күренә ки, М.Фәйзи музыканы саф, керсез мәхәббәткә, сөю-сөелү хисләренең бөеклегенә, вәгъдәләшүгә ишарә итүче символ дәрәҗәсенә күтәрә.

Әсәрнең төп каһаманнары – Галиябану һәм Хәлилнең характер сыйфатлары арттырылып, күпертелеп сурәтләнгән, алар романтик буяулар белән бизәкләнгән. Исмәгыйльнең дә минминлеге, миһербансызлыгы автор тарафыннан үстерелеп бирелгән. Драматург аңлашылмаучылыкларга, төрле сәнгати детальләргә, символик образларга мөрәҗәгать иткән. Портретлар, психологик контрастлар, драматик антитезалар ятратып файдаланылган. Әдәби әсәрнең теле гаҗәеп матур, халыкның җанлы сөйләм элементлары – мәкаль, әйтем, афоризмнар белән баетылган. Алар, бердән, әсәрнең реалистик яңгырашын, халык тормышына якынлыгын күрсәтсәләр, икенчедән, каһарманның характер сыйфатларын (мәсәлән, Исмәгыйль) тулыландыралар, өченчедән, вакыйга-күренешкә авторның, геройның бәясен, мөнәсәбәтен белдерүгә дә хезмәт итәләр.

**Сораулар һәм биремнәр**

1. «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясендә көлү объектын һәм көлке тудыру алымнарын билгеләгез.
2. «Кызганыч» мелодрамасында үзәк конфликтның эчтәлеген ачыклагыз.
3. «Кызганыч» пьесасында кемнәр кызганыч?
4. «Авыл бәйрәме» драматург иҗатына нинди үзгәрешләр алып килә?
5. «Тәкъдирнең шаяруы» драмасы белән М.Фәйзи шигъриятендәге уртак билгеләрне күрсәтегез.
6. М.Фәйзи һәм К.Тинчуриннарның 1910 еллар драматургиясендә уртак сыйфатларны билгеләгез.

7. «Галиябану» пьесасының татар драматургиясенә алып килгән яңалыгы нәрсә белән аңлатыла?
8. «Галиябану» музыкаль драмасының матурлыгы һәм сихри көче нидән гыйбарәт?
9. «Мәхәббәт, вөждан һәм намус» дигән темага реферат языгыз.
10. Хәлил һәм Исмәгыйль образларына чагыштырмача характеристика бирегез.
11. Нинди тышкы сәбәпләр Галиябануның күңелендә тирән драматик кичерешләр барлыкка китерә?

**Контроль эш темалары**

1. «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясендә күтәрелгән мәсьәләләр.
2. «Кызганыч» мелодрамасында төп һәм ярдәмче конфликтлар.
3. «Кызганыч» мелодрамасында күтәрелгән проблемалар.
4. М.Фәйзи иҗатында татар-төрек әдәби багланышлары.
5. «Тәкъдирнең шаяруы» драмасында драматик шәхесләр – Мөршидә, Гыйсмәт, Гөлшат.
6. «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасында композицион катламнар.
7. «Авыл бәйрәме» музыкаль комедиясендә авыл кешеләре психологиясенең чагылышы.
8. М.Фәйзинең «Галиябану» драмасында конфликт үзенчәлеге.
9. «Галиябану» пьесасының жанр үзенчәлеге.
10. «Галиябану» музыкаль драмасында Бәдри һәм Галимә образлары.

**Гамәли дәрес. Тема: М.Фәйзинең 1910 еллар драматургиясендә конфликт һәм характерлар.**

1. М.Фәйзи – милли драматургиядә үз сукмагын булдырган классик әсәрләр авторы. «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясенең идея-эстетик үзенчәлекләре.
2. «Кызганыч» мелодрамасының сюжет сызыгы, образлар системасы: Заһид, Гәүһәр, Сөләйман һ.б. Геройларны хәрәкәткә китергән төп конфликт, каһарманнарның эчке каршылыгына корылган ярдәмче каршылыклар. Әсәрдә хис, күңел культы. Романтик сурәтлелекнең сентиментализм билгеләре белән баетылуы.
3. Традицион мәхәббәт өчпочмагы мотивына корылган «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасы. Аның конфликт үзенчәлеге. Чарасызлык баскычындагы романтик каһарманнарның сызлану, өзгәләнү

сәбәпләре, фаҗигалелек. Әсәрне «Кызганыч», К.Тинчуринның «Соңгы сәлам» драмасы белән бәйли торган җепләр.

4. Драматургның «Галиябану» музыкаль драмасы. Аның жанр үзенчәлеге һәм иҗат ысулы мәсьәләсе. Пьесада төп һәм ярдәмче конфликтлар. Әсәр каһарманнарының каршылыкларда ачылган характер сыйфатлары. Автор тарафыннан якланган кыйммәтләр.
5. «Галиябану» драмасының сәнгати яктан камиллеге, бөтенлеге. Характерлар тудыруда драматург осталыгы, ул мөрәҗәгать иткән алымнар. Әсәр тукымасындагы халык җырлары, этнографик детальләрнең роле. М.Фәйзи иҗатына замандашларының, төрек әдәбиятының йогынтысы.

**Текстлар**

1. Фәйзи М. Сайланма әсәрләр / Кереш сүз авторы Х.Хәйри. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 369 б.
2. Фәйзи М. Сәхнә әсәрләре. - Казан: Татгосиздат, 1941. - 362 б.
3. Фәйзи М. Пьесалар. - Казан: Татгосиздат, 1951. - 239 б.
4. Фәйзи М. Сайланма әсәрләр / Урта һәм олы яшьтәге балалар өчен. - Казан: Татгосиздат, 1953. - 118 б.
5. Фәйзи М. Сайланма әсәрләр. 2 томда. 1 – том / Пьесалар, шигырьләр, халык җырлары. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1957. – 360 б.
6. Фәйзи М. Галиябану / Ахыргы сүз авторы Р.Даутов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1981. – 158 б.
7. Фәйзи М. Әсәрләр / Төзүче һәм кереш мәкалә авторы Т.Гыйлаҗев. – Казан: Мәгариф, 2007. – 295 б.

**Әдәбият**

1. Әхмәдуллин А. Аның сәнгатьчә ачышлары // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. – 141-146 б.
2. Гыйлаҗев Т. Кешенең рухи дөньясында ямь, матурлык эзләп // Мирхәйдәр Фәйзи. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – 7-31б.
3. Закирҗанов Ә. «Кызганыч»та нәрсә кызганыч?» (Мирхәйдәр Фәйзи иҗатына күзәтү) // Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре: Әдәбият укытучылары өчен методик кулланма. – Казан: «Мастер Лайн», 1997. – 69-77 б.

4. Заһидуллина Д., Ибраһимов М., Әминева В.Р. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111б.
5. Ибраһимов Г. «Галиябану» хакында бер-ике сүз // Әсәрләр. Сигез томда. 5-том. / Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). - Казан: Тат.кит.нәшр., 1978. - 301-303 б.
6. Ибраһимов М. Композицияне ачыклау // Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005. – 35-49 б.
7. Кутуй Г. Академия театрында «Галиябану» // Публицистика. / Төз. З.Усманова. – Казан:Таткнигоиздат, 1957. - 135-138 б.
8. Мирхәйдәр Фәйзи (1891-1928) // Татар әдәбияты. II кисәк (1917 нче елга кадәр). Югары уку йортлары өчен. Төзәтелгән икенче басмасы. - Казан: Таткнигоиздат, 1954. - 339-453 б.
9. Нуриев Г. Сәхнә ачылганда уйланулар // Идел. – 1998. - № 1. – 64-65 б.
10. Нуруллин И. Мирхәйдәр Фәйзи // XX йөз башы татар әдәбияты: Урта мәктәп укытучылары һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1982. – 261-282 б.
11. Толымбайский Г. Әсәр нәрсә бирә? // Кызыл Татарстан. – 1924. – 23 май.
12. Ханзафаров М. Мирхәйдәр Фәйзи // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3 – том / XX гасыр башы. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. – 421-435 б.

## М.Фәйзинең 1920 еллар драматургиясендә традицияләр һәм яңачалык

1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр үк сәхнә әсәрләре язуда тәҗрибә туплап, милли драматургияне үстерүдә үз сукмагын булдырган М.Фәйзинең 1920 елларда икенче дәвер иҗаты башлана. Илдәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять, гражданнар сугышы белән бәйле канлы вакыйгалар, илне социалистик нигездә үзгәртеп кору хәрәкәте әдипкә йогынты ясамый калмый. Матур әдәбиятны өйрәнгән әдәбият белеме фәне гыйльми-нәзари эзләнүләр юлында булса да, М.Фәйзи үзенең иҗат кыйбласын билгеләп, авыл темасын, аның кешеләре тормышына заман вакыйгалары алып килгән үзгәрешләрне сурәтләүгә алына. Замандаш әдипләренең каләме, әдәби эшчәнлеге сүлпәнәеп калган вакытта, М.Фәйзи, киресенчә, бик актив иҗат итә, аның 1920 елларда бер-бер артлы әсәрләре дөнья күрә. Язучы пьесаларында, гәрчә ул каләмен иҗтимагый-социаль мәсьәләләргә борырга тырышса да, кешене олылау һәм зурлау, аңа гуманистик караш өстенлек ала. Н.Ханзафаров драматургның бу еллар иҗатындагы стиль үзенчәлеген болай билгели: «пьесаларында драматург сыйнфый каршылыкларны кискен итеп сурәтләү белән бергә, дөньяга гуманистларча карады, кешегә тирән мәхәббәт саклый» [Ханзафаров, 1989; 268]. М.Фәйзи әсәрләрендә яңа тормышның беренче яралгыларын һәм кешеләрнең күңел дөньясындагы үзгәрешләрне тасвирлауда охшашлык күзәтелсә дә, әдипнең бу чор иҗатында ике тематик юнәлеш, тармак аерымлана. Беренче юнәлешкә караган «Урал суы буенда» (1917), «Асылъяр» (1918-1920), «Ак калфак» (1922-1923) әсәрләренә романтик-шартлы фикерләү, дастани башлангыч, шәркый традицияләр хас. Аларда М.Фәйзи беренче чор иҗатындагы традицияләргә киңрәк таяна.

Шигъриятендәге авыл кешеләренең табигыйлегенә, инсани мөнәсәбәтләренә, табигать матурлыгына һәм хезмәт романтикасына дан җырлау мотивы язучының романтик эчтәлекле «Урал суы буенда» (1917) драмасында яңа сыйфатта сурәтләнә. Пьесада, революциягә кадәрге бер төркем әсәрләрендә язмышка, тәкъдиргә буйсынып, сызланып яшәүгә дучар ителгән каһарманнарыннан аермалы буларак, шәхес азатлыгына, кеше бәхетенә каршы торган киртәләрне җимерергә сәләтле, романтик

рухлы, актив геройлар тудырыла. Бай гаиләдә туып үсеп, шәһәр тәрбиясе алган Зифа, ата-анасының теләкләренә каршы килеп, крестьян егете Әдһәмгә кияүгә чыга. Аларның фән-техника казанышлары нигезендә авыл тормышын яңарту, мәдәниләштерү теләге авылдашлары тарафыннан яклау таба һәм тиз арада беренче нәтиҗәләрен дә бирә. «Авыл бәйрәме»ндәге (1915) кебек бу пьесасында да М.Фәйзинең симпатиясе үз кул көче белән көн күрүче авылның гади кешесендә, егетләрендә һәм кызларында. «Урал суы буенда» пьесасы драматургның катлаулы, тарихи һәм социаль катаклизмнар чорында социаль гаделлек, шәхси азатлык эзләү юлында беренче тәҗрибәсе булып тора.

М.Фәйзинең «Асылъяр» (1918-1920) драмасында кече яшьтән бер-берсен сөешеп үскән ятим егет Шәрәф белән Искәндәр бай кызы Ләләнең мәхәббәт хисләре шәркый мотивлар белән тыгыз бәйләнештә тасвирлана. Бу мелодрамадагы мәхәббәт тарихы бер яктан «Таһир-Зөһрә» мотивларына барып тоташса, икенче яктан, аерым сыйфатлары белән замандашлары Ф.Бурнаш, К.Тинчурин һ.б.ларның пьесаларына аваздаш. Мәсәлән, борынгы йола-гадәтләр буенча Ләләнең колагы тешләтелгән Гаптерәшит – үзенең булдыксызлыгы, фикерсезлеге, идеалсызлыгы белән К.Тинчуринның «Назлы кияү» (1916) трагикомедиясендәге Рамазанның сыңары.

Драманың төп каһарманнары Шәрәф белән Ләлә романтик эстетика кануннарына буйсындырылып, холык сыйфатлары үстерелеп тасвирланганнар. Автор бай кызы Ләләнең тышкы кыяфәтен дә, күңел матурлыгын да идеаллаштырып сурәтли. Хезмәтчеләргә, түбән катлауга кимсетеп караган Искәндәр бай, төрле чаралар кулланып та, кызы Ләлә белән Шәрәфнең бер берсенә сөю хисләрен сүндерә алмагач, аларны аеру өчен, мәкерле план кора. Изге ниятләр пәрдәсенә яшеренеп, Шәрәфне шәһәргә укырга җибәрә һәм шул арада Ләләне Гаптерәшиткә кияүгә биреп, үз «фамилиясенең абруен» саклап калырга тели. Әмма әсәрнең финалында ике арадагы каршылык романтикларча хәл ителеп, гаделлек, дөреслек җиңеп чыга, яшьләрнең саф мәхәббәт хисләре тантана итә. Драматург тарафыннан кешенең табигый хисләре, мәхәббәтнең зурлыгы яклана. Ә инде үз бәхете, мәхәббәте өчен атасына каршы көрәшкә чыккан Ләлә туган йортыннан куыла. Ләлә Шәрәфнең «авылдагы үз кул көче белән көн иткән тормышын» атасының бай һәм мул тормышыннан өстен

куя. Героиняның бу адымы белән М.Фәйзи хезмәт кешесен алгы планга чыгара һәм кеше бәхете мәсьәләсен шушы яссылыкта хәл итә.

Драматург беренче чор иҗатында язылган «Авыл бәйрәме» (1915), «Галиябану» (1916) драмаларында халык иҗаты җәүһәрләрен куллануда бай тәҗрибә туплый. Язучылык сәләте белән фольклор эстетикасы органик кушылган әдип иҗатында, аерым алганда «Асылъяр» мелодрамасында җыр әсәрнең композицион бөтенлегенә, төзеклегенә ирешү, геройларның психологик кичерешләрен, күңел тибрәнешләрен тирәнәйтү, аларның үзара аралашу, мәхәббәттә аңлашу чарасы буларак та кулланыла. Шәрәфнең Ләләгә эчкерсез, саф мәхәббәт хисләрен гәүдәләндереп символ югарылыгына күтәрелгән «Асылъяр» җыры белән пьесаның идея эчтәлеге сугарыла.

Драматургның социаль-иҗтимагый хәлләре төрле булган яшьләр – морза кызы Хәмдия белән көтүче Бакыйның мәхәббәтен сурәтләгән «Ак калфак» мелодрамасы 1922-1923 елларда языла. Бу пьесада алдагы әсәр белән жанр, сюжет, конфликт һәм коллизияләр охшашлыгы күзәтелсә дә, автор башка тормыш материалына мөрәҗәгать итә. Вакыйгаларның үстерелеше һәм төп каршылыкның чишелеше, якланган кыйммәтләр дә шактый үзенчәлекле. «Ак калфак» пьесасында милли әдәбиятта сурәтләнү традицияләре бай булган татар халкының аксөякләре, морзалар тормышы тасвирлана. Мәгълүм булганча, совет власте елларында бу социаль катлауның тарихын яктыртуга берьяклы караш, тискәре мөнәсәбәт урнаша. Морзаларның иҗтимагый хәле, яшәү рәвеше, сыйнфый–идеологик күзлектән чыгып, бозып аңлатыла. М.Фәйзинең «Ак калфак» пьесасында да морзалар яшәешен тасвирлауда чор идеологиясенең йогынтысы сизелә. Мондый караш авторның характер тудыру алымнарына да тәэсир ясый. Драматург XX гасыр башы иҗатында өстен катлау кешеләренең, байларның холкын драматик вакыйгаларда ачса, ә совет чорындагы пьесаларында аларның характер сыйфатларын көлкеле хәлләрдә, комедиячел ситуацияләрдә күрсәтә.

Сәлим морза белән аның хезмәтчеләре, авыл ярлылары арасында социаль каршылык мелодрамадагы вакыйгаларны хәрәкәт иттерә, әсәрдә өстенлек алган мәхәббәт сюжет сызыгына драматизм, фаҗигалелек өсти. Дуамал, рәхимсез, кешелексез Сәлим морза хезмәтчеләренә «бер куйның бер аягы сынганчы, йөз хезмәтченең мең аягы сынсын» дигән караштa

тора һәм сатирик планда сурәтләнә Ә аның кызы Хәмдия – атасыннан аермалы буларак, миһербанлы, психологик кичерешләргә бай, кимсетелгәннәрне яклаучы саф күңелле кыз. Дөрес, ул да, үзенең сыйнфый өстенлегеннән чыгып, аерым ситуацияләрдә көтүче-фәкыйрьләргә кимсетеп карый, ә Бакый исә - җырлы-моңлы, хезмәт кешесенең иң күркәм сыйфатларын үзендә туплаган батыр йөрәкле, характер сыйфатлары арттырылып тасвирланган образ.

Вакыйгалар үстерелешендә әсәргә килеп кергән Хантимер мирзаның улы Шаһтимернең тышкы кыяфәтен, холкын, эш-гамәлләрен автор уңай яктан тасвирлый, аның Хәмдиягә булган саф мәхәббәт хисләрен күрсәтә. Хәмдия, Шаһтимерне яратса да, үз исемен, дәрәҗәсен ил, халык теленә кертеп, аның исемен мәңгеләштереп, мәхәббәт җыры иҗат иткән кешегә үзенең күңелен баглавын белдерә. Җыр аны бер күрүдә гашыйк булган бай күңелле көтүче Бакый тарафыннан иҗат ителә һәм Хәмдиянең күңелен биләп ала. Шушы яссылыкта Шаһтимер белән Бакый арасында ярдәмче каршылык та туа һәм, аңлашылмаучылык аркасында, ул Бакыйның үлеменә китерә.

«Ак калфак» мелодрамасының фаҗигале чишелешендә «Хәмдия» җыры сыйнфый киртәләрне белмәгән саф мәхәббәт хисләренә дан җырлаган шартлы-романтик образ югарылыгына күтәрелә: «Ак калфак» исә – романтик рухтагы әсәр. Шигъри нәфислеге, композициясенең төгәллеге, образларының камиллеге, җыр-музыкага байлыгы, «Хәмдия» җырын шигъри деталь итеп алуы һәм үстерүе, мәхәббәтне күтәренке төстә, гүзәл итеп сурәтләве белән ул безнең романтик драматургиядә үзгә бер урын били» [Әхмәдуллин, 1980; 294].

М.Фәйзинең икенче шәлкем әсәрләрендә иҗтимагый-социаль, сыйнфый көрәш мәсьәләләре шактый калку гәүдәләнеш ала. «Кызыл йолдыз» (1923), «Адашкан күңел» (1923), «Кәкре каен» (1923), «Коммунага» (1924) һ.б. Мондый эчтәлектәге әсәрләр реалистик детальләргә мөрәҗәгать итү, тормышчанлыгы белән аерылып торалар һәм аларда рус әдәбияты белән аваздаш җепләр, сыйфатлар да күзәтелә. Исеменә үк көчле мәгънәви йөк салынып, заман рухын чагылдырган «Кызыл йолдыз» (1923) пьесасы авылда беренче комсомол оешмасы төзелү вакыйгасын сурәтли. «Язучының идея-политик үсеше аның әсәрләрендә дә чагылмый калмый. Шуның ачык мисалы – 1923 елны

язылган «Кызыл йолдыз» пьесасы, - дип яза А.Әхмәдуллин. – Заман темасын үзләштерү ноктасыннан караганда, ул М.Фәйзи иҗатында гына түгел, гомумән шул еллар татар драматургиясендә әһәмиятле урын тота» [Әхмәдуллин, 1980; 145]. Бу автобиографик җирлекле әсәр, М.Фәйзинең искәрмәсендә әйтелгәнчә, «Башкортстанның 1921 елга кадәр бандитлар бәласеннән котылып бетә алмаган почмагындагы бер татар авылында яшьләр оешмасы төзелү вакыйгасыннан алынып язылган» [Фәйзи, 1951; 160].

Драманың беренче пәрдәсендә кулак балалары Таҗи белән Әпрәү арасындагы сөйләшүдә төп каршылык, аның характеры, геройларның холык -фигыльләре ачыклана башлый. Авылның матур, уңган, акыллы кызы Маһруйны Әпрәү, байлыгы белән масаеп, үзенеке итәргә тели. Аның сөйгән егете Сөнгать белән Әпрәү арасындагы тартышта төенләнеш барлыкка килә. Гади тормыш-көнкүреш вакыйгаларында, яшьләр хәрәкәтендә һәм персонажларның эш-гамәлләрендә каршылык тирәнәеп, өченче пәрдәдә үзәк конфликт ачыкланып бетә. Ул китапханәче Хәй, аның тирәсендә тупланган Сөнгать, Гатау, Ибрай кебек авыл яшьләре белән совет органнарына кереп оялаган кулаклар һәм аларның малайлары арасында туа. Пьесада характерлар бәрелеше яңа иҗтимагый күренешләргә мөнәсәбәтнең, идеологик-сәяси карашларның төрлелегенә нигезләнгән.

Драманың яңа идея эчтәлеге язучының сәнгатьчә фикерләвенә йогынты ясаган. Ул кеше яшәешен, җәмгыять тормышын матур әдәбиятта гәүдәләндерүнең яңа реалистик принципларына, алымнарына мөрәҗәгать итә. Яңа тормыш төзелешен һәм авыл кешеләренең иҗтимагый-сәяси карашлары үзгәрешен драматург җанлы, реаль вакыйгалар һәм образлар системасы аша күрсәтә. Пьесаның төп каһарманы Хәй – шәһәрдән авылга килгән сәяси аңлы, акыллы, белемле, җырга-биюгә, сүзгә оста егет. Ул алгы планга куеп сурәтләнә. Үзенең салмак характеры, һәр буын вәкиле белән уртак тел таба алуы аркасында, авыл халкында тиз арада абруй һәм ышаныч казана, үз тирәсенә фикердәш, таяныч булырдай егетләрне, кызларны туплый. Коммун егет авыл халкы тормышын үзгәртүдә, хезмәткә яңа мөнәсәбәт тәрбияләүдә әдәби-мәдәни чараларны файдалана.

М.Фәйзи «Кызыл йолдыз» драмасында шушы еллар тарихи вакыйгаларын, үз чорының мохитен, туып килгән яңа күренешләрне,

хәрәкәтләрне тасвирларга омтылган. Аерым мәсьәләләргә карашының артык беркатлы булуына карамастан, бу юнәлештә уңышларга да ирешкән. Язучы кешенең рухын, дөньяга карашларын үзгәртүдә, кискен адымнар ясауны, көч куллануны кире кагып, табигыйлеккә, агарту-тәрбия эшләренә басым ясый. Сукыр Шәфи картның «кесәсендәге актык тиеннәрен елатып алган» Ногман байның эш-гамәле коммун яшьләрнең ижтимагый активлыгын кузгатып җибәрә. Алар, сыйнфый-сәяси аңы үсеп, совет власте дошманнарына каршы көрәшләрдә чыныгып кайткан кызылармеец Абдулла җитәкчелегендә авыл советыннан байларны, кулакларны куып чыгаралар һәм гади халыкны җәбер-золымнан коткаралар. Шушы вакыйгалар тәэсирендә авылда комсомол оешмасы төзелә. Авыл тирәсендәге урманнарга кереп яшеренгән бандитлар килеп чыкса, «исән калу юклыгын» аңлаган коммунарлар, кулларына корал алып, кызыл гаскәрләргә барып кушылалар. Корбаннар бирү хакына, совет власте дошманнары тар-мар ителә. Сыйнфый көрәш вакыйгаларында авыл егетләре, кызлары рухи яктан чыныгу, сыналу үтәләр. Драматург кешеләрнең үзара аралашуында, ир-хатын мөнәсәбәтләрендә, көнкүрештә барган үзгәрешләрне ышандыру көченә ия булган тасвирларда ача алган. Әсәр бүгенге көн күзлегеннән караганда, социаль изелүгә, кимсетелүгә, җәбер-золымга дучар ителгән гади халыкның якты өмет-хыялларын, ижтимагый гаделлеккә, тигезлеккә омтылышын тасвирлавы белән әһәмияткә ия. Пьеса идея эчтәлегенең гуманистик яңгырашы шунда билгеләнә.

Шулай да, социалистик төзелешнең беренче үрентеләрен, яңа идеологиянең һәм мәдәни чараларның кеше психологиясенә тәэсирен күрсәтүдә драматург мәгълүм уңышларга ирешсә дә, сыйнфый каршылыкларны, кулак фетнәләрен, акгвардиячеләрнең террорын тасвирлаган сюжет сызыгы вакыйгалар һәм типлар байлыгы белән аерылып тормый, аларның ышандыру көче түбән. Бу, беренчедән, драматургның, ижтимагый-сәяси хәяттән читтә торуы аркасында, тормыш тәҗрибәсе җитмәү белән аңлатылса, икенчедән, авторның рәхимсезлекне, канлы вакыйгаларны, кеше характерындагы кансызлыкны кабул итмәве белән шәрехләнә.

Драматург сыйнфый көрәш сызыгына параллель рәвештә үз идея-эстетик казанышларына, сәнгатьчә фикерләү рәвешенә, стиленә тугры

калып, гади авыл тормышын, гореф-гадәтләрен, туй йолаларын, этнографиясен чагылдыруга зур урын бирә һәм вакыйгаларны җыр-музыка, моң белән үреп сурәтли. Шушы вакыйгалар тезмәсендә характерлар да тулырак ачыла һәм алар тамашачыларга тәэсир итү көче белән дә аерылып тора.

Бу тематикада үзәк конфликты, вакыйгаларның драматик, урыны белән фаҗигале төстә үстерелеше, яңа тема –мотивларның килеп керүе һәм якланган кыйммәтләрнең үзгәлеге белән «Адашкан күңел» (1922-1923) мелодрамасы үзенчәлекле урын алып тора. Шәһәрдә бай гаиләдә тәрбияләнеп, үзенең күңеле ятмаган кешегә кияүгә чыгудан баш тартып, авылга мөгаллимә булып килгән Мавия крестьян егете Саматка гашыйк була. Күңелендәге мәхәббәт хисләрен аңлатуда Самат белән аралашуда үзе башлап йөрүче Мавия Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем» (1907) көнкүреш драмасындагы Галияне хәтерләтә. Крестьян хезмәтен башкара алу, алмавына нисбәтле Мавия күңелендә туган шөбһәләнүләр, каршылыклы уйлар пьесаның үзәк конфликтын барлыкка китерә. Төп героиня үз мәхәббәтен ташлап китәргә карар кыла һәм шушы адымы белән ул зур тормыш сынавына дучар ителә.

Драманың менә шушы сюжет сызыгында тасвирланган вакыйгалар, хәлләр М.Фәйзинең дөньяга карашларында үзгәрешләр барлыкка килүен дәлилли. Автор тарихи барышка реаль караш ташлый. Моңа кадәр романтик яссылыкта сурәтләнеп килгән вакыйгалар реалистик юнәлештә үстерелә башлый. Озак вакытлардан соң Мавия Самат белән очраша, ургып чыккан мәхәббәт хисләренә хуҗа була алмыйча, авырга уза. Мавия бала таба һәм шуннан соң артык ихлас, артык саф Мавия буржуаз җәмгыятьнең кешелексез, кыргый тәртипләре белән күзгә-күз очраша.

Автор үз героинясының рухи ныклыгын төрле хәл-ситуацияләрдә сыный. Баласы белән сыеныр урын тапмаган Мавия – хуҗасы акча, мал-мөлкәт өчен теләсә нинди түбәнлекләргә барырга әзер торган шыксыз постоялый дворда яшәргә мәҗбүр була. Үз тәне белән сату итүдән баш тарткан Мавия бүлмәсенә иҗтимагый гаделсезлек аркасында яшәү мәгънәсен югалткан тормыш төбендәге зимагорлар кертелгәч, аның хәле тагын да авырая. Шушы күренешләр аркылы автор җәмгыятьнең рәхимсез якларын ача. Пьесаның бу эпизоды рус әдибе А.М.Горькийның «Тормыш төбендә» әсәре йогынтысында тудырылган. Дөрес, автор романтик

эстетиканың атрибуты булган очраклылык алымына мөрәҗәгать итеп, әсәр финалында Мавия белән Саматны кавыштыра.

М.Фәйзи «Адашкан күңел» драмасында үз күңел дөньясында, мәхәббәт хисләрендә адашкан каһарманнарның драматик һәм фаҗигале хәлләрен күрсәтеп, аерым эш-хәлләрне аек акыл белән үлчәргә, үз мәхәббәтеңне сакларга кирәк дигән фикерне яклый. Шулай ук автор буржуаз җәмгыятьнең кешене рухи яктан имгәткән, зәгыйфьләндергән тәртипләрен реалистларча сурәтләүгә ирешә.

М.Фәйзи 1920 еллар драматургиясендә кеше яшәешен, чынбарлыкны сурәтләүнең романтик принципларына һәм алымнарына тугры кала. Шул ук вакытта бу чор әсәрләренең сюжеты нигезендә яткан конфликтларның эчтәлеге үзгәрә, характерлар тудыру алымнары төрләнә, геройларның психологиясендә, эш-гамәлләрендә үзгәрешләр күзәтелә, яңа тасвирый чаралар барлыкка килә. Әмма М.Фәйзи иҗатында кешеләрнең күңел матурлыгын, табигый хисләр, гомумкешелек кыйммәтләрне чагылдыру өстенлек итә. Үз сүзләре белән әйткәндә, «каләмен пролетариат сәхнәсенә борырга» тырышса да, рәсми идеологиядән, тар пролетар сыйнфыйлыктан азат пьесалары белән татар совет драматургиясенең башлангыч чорында үзенчәлекле үсеш юнәлеше булдыра.

Шигырьләрендә һәм драма әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар әдипнең «Табигать серләре», «Сәрвиназ», «Инде мин еламыйм» кебек хикәя-нәсерләрендә дә яктыртыла.

М.Фәйзинең гомер юлы кыска була. Рәхимсез авыру аның иҗат планнарына чик куя. М.Фәйзи әдәби иҗатка матур әдәбиятның лирика төрендә тәҗрибә туплап килеп, милли драматургиянең идея-эчтәлеген киңәйтүгә, яңа сәнгати алымнар-чаралар белән баетуга, жанр системасын төрләндерүгә үзеннән мәгълүм өлеш кертеп, аны романтик юнәлештә үстерде, яңа биекләргә күтәрде. Чын мәгънәсендә халыкчан, сәнгатьчә эшләнеше камил булган драмалары белән татар әдәбиятының хәзинәсен баетты.

**Сораулар һәм биремнәр**

1. 1920 еллардагы яңа иҗтимагый, икътисади шартлар М.Фәйзинең каләменә ничек тәэсир ясый?
2. «Ак калфак» мелодрамасында төп каһарманнар Бакый һәм Хәмдияләрнең характер сыйфатларын ачыклагыз.

3. «Асылъяр» драмасындагы Габдерәшиткә һәм К.Тинчуриннның «Назлы кияү» трагикомедиясендәге Рамазанга чагыштырма характеристика бирегез.
4. Гади халык вәкилләренең күңел матурлыгын ачуда М.Фәйзинең осталыгын күрсәтегез.
5. Драматургның «Ак калфак» пьесасында традицияләр дәвамчанлыгы кайсы сыйфатларда күзәтелә?
6. «Урал суы буенда» драмасында Зифа һәм Әхмәт образларында автор эстетик идеалының чагылышы.
7. «Кызыл йолдыз» пьесасында образлар системасын бәяләгез.
8. «Адашкан күңел» драмасында реалистик вакыйгалар сызыгын аерып күрсәтегез һәм аның иҗат ысулын анализлагыз.
9. М.Фәйзи драмаларына нигезләнеп, «Җыр-мәхәббәт символы» дигән темага инша языгыз.

**Контроль эш темалары**

1. «Урал суы буенда» пьесасында авыл һәм шәһәр мөнәсәбәте.
2. «Кызыл йолдыз» пьесасында чор идеологиясенең чагылышы.
3. «Асылъяр» драмасының сәнгати үзенчәлекләре.
4. «Ак калфак» мелодрамасында “Хәмдия” җырының идея-эстетик вазифасы.
5. Өстен катлау вәкилләре образларын тудыруда драматург мөрәҗәгать иткән алымнар.
6. «Адашкан күңел» пьесасында рус-татар әдәби багланышлары.
7. «Асылъяр» драмасында традицияләр һәм яңачалык.

**Гамәли дәрес. Тема: М.Фәйзинең 1920 еллар драматургиясендә традицияләр һәм яңачалык.**

1. 1917 елгы Октябрь борылышы нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа иҗтимагый-сәяси, әдәби-мәдәни шартлар һәм Мирхәйдәр Фәйзи.
2. Әдипнең «Асылъяр» һәм «Ак калфак» драмаларында мәхәббәт темасының сурәтләнешендә традицияләр чагылышы һәм яңачалык. Шәрәф, Бакый образларының характер сыйфатлары һәм аларга йөкләнгән идея-эстетик мәгънә.
3. Драматургның «Адашкан күңел», «Кызыл йолдыз» пьесаларында чор идеологиясенең чагылышы. Әсәрләрдә сурәтләнгән сюжет сызыклары һәм күтәрелгән иҗтимагый-социаль мәсьәләләр.

4. М.Фәйзи драмаларында якланган кыйммәтләрнең гуманистик яңгырашы һәм драматургның татар халкының рухи-мәдәни яңарышында тоткан урыны.

**Текстлар**


1. Фәйзи М. Сайланма әсәрләр / Кереш сүз авторы Х.Хәйри. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 369 б.
2. Фәйзи М. Сәхнә әсәрләре. - Казан: Татгосиздат, 1941. - 362 б.
3. Фәйзи М. Пьесалар. - Казан: Татгосиздат, 1951. - 239 б.
4. Фәйзи М. Сайланма әсәрләр / Урта һәм олы яшьтәге балалар өчен. - Казан: Татгосиздат, 1953. - 118 б.
5. Фәйзи М. Сайланма әсәрләр. 2 томда. 2 – том / Пьесалар, шигырьләр, хикәяләр, көндәлек дәфтәреннән өзекләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1957. – 464 б.
6. Фәйзи М. Әсәрләр / Төзүче һәм кереш мәкалә авторы Т.Гыйлаҗев. – Казан: Мәгариф, 2007. – 295 б.


**Әдәбият**


1. Әхмәдуллин А.Г. «Ак калфак» // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. – 293-296 б.
2. Ахмадуллин А. Лейтмотив - гуманизм // Горизонты татарской драматургии: Литературно-критические статьи. - Казань: Татар.кн. изд-во, 1985. - С. 189-192.
3. Бурнаш Ф. Революция һәм татар әдәбияты // Әдәбият һәм сәнгать турында. - Казан: Тат.кит.нәшр, 1978. – 170-195 б.
4. Кутуй Г. Хәйдәр Фәйзи // Публицистика / Төз.: З.Усманова. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. - 213-215 б.
5. Мусин Ф. Мирхәйдәр Фәйзи һәм XX йөз татар әдәбияты // Шәһри Казан. – 2001. – 4 гыйнвар.
6. Ханзафаров Н. Мирхәйдәр Фәйзи // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 4 – том / Татар совет әдәбияты (1917-1941). – Казан: Тат.кит.нәшр., 1989. – 259-270 б.
7. Ханзафаров Н. Мирхәйдәр Фәйзи һәм инкыйлаб // Мәдәни җомга. – 2001. – 7 декабрь.
8. Шәрәфиев Р. Гашыйклар җырчысы // Мәйдан. – 2003. - № 1. – 116-121 б.

## Тестлар

## М.Фәйзинең 1917 елгы Октябрь борылышына кадәрге тормыш юлы һәм иҗаты

*I вариант*

1. М.Фәйзи кайсы авылда туган?

а) Юлык в) Җүнәй
б) Күкшел г) Җиргән

2. Әдип кайчан вафат булган?

а) 1921 в) 1924
б) 1926 г) 1928

3. М.Фәйзинең әдәби әсәрләре нинди әдәби юнәлештә иҗат ителгәннәр?

а) реалистик
б) романтик
в) модернистик

4. Аның беренче шигырьләре ничәнче елда матбугат битләрендә күренә башлый?

а) 1907 в) 1912
б) 1910 г) 1914

5. М.Фәйзигә Г.Тукай белән очрашу насыйп булганмы?

а) әйе
б) юк

6. Шагыйрьнең «Мөнбәр вә мендәр» шигыре нинди композицион алымга корылган?

а) кабатлау в) монтаж
б) каршы кую г) көчәйтү

7. «Үз иркемә куй» шигыренең жанрын билгеләгез:

а) фәлсәфи лирика в) пейзаж лирикасы
б) гражданлык лирикасы г) күңел лирикасы

8. «Үткән вакыт» шигырендә лирик геройның зарлы, хәсрәтле халәтенә нәрсә каршы куела?

а) үткәндәге мәхәббәт в) сабыйлык
б) яшьлек г) табигать матурлыгы
д) ак канатлы хыяллар

9. «Зарлану» шигыренең мотивы кайсы шагыйрь иҗаты йогынтысында М.Фәйзи рухи мирасына килеп кергән?

а) С.Рәмиев
б) Дәрдемәнд
в) С.Сүнчәләй
г) Ш.Бабич
д) З.Бурнашева

10. «Рәхәт кайда?» шигырендәге төп мотивны аерып чыгарыгыз:

а) сызлану
б) халык
в) табигать
г) каләм
д) шагыйрь
е) өмет

11. «Бер кыз җырлый» шигырендә тропларның кайсы төре файдаланылган?

Яхуд ул яңа
Ачылган **гөлдәй**
Елмаеп кына
Сөйли **былбылдай**

а) метафора
б) эпитет
в) чагыштыру
г) аллегория

12. «Яшәгез, яшьләр» шигырендә лирик герой күңелендәге хисне аерып күрсәтегез:

а) үкенеч
б) борчылу
в) көенү
г) сагыш
д) шатлык
е) өметсезлек

13. «Соңгы теләк» шигырендә гәүдәләнгән мотивны билгеләгез:

а) яшәү
б) үлем
в) мәхәббәт
г) үкенеч
д) өметсезлек
е) фани дөньяның чикләнгәнлеге

14. «Галиябану» пьесасы нинди жанрда иҗат ителгән?

а) тарихи драма
б) музыкаль драма
в) сатирик драма
г) трагедия
д) сентименталь драма

15. «Дустым өчен. Фәләк» шигырендә нинди мотив күзәтелә?

Китә картлар белән яшьләр дә бергә,
Синең җәбереңбелән яшьләй кабергә.
Кайчан комсызлыгыңнан бер туярсың?
Кайчан инсан белән уеның куярсың?

а) үлем
б) яшәү
в) гыйсъянчылык
г) төшенкелек

16. «Илем» әсәрендә шигырь юлларының рифмалашу төрен билгеләгез:

Тырышамын авылым өчен, «аккош» булыйм дип бәхетенә,
Нурлы бер «аккош» булыйм дип авылым – алтын тәхетемә.

а) төгәл рифма　　　　　в) омонимик рифма
б) аралаш рифма　　　　　г) әйләнмә рифма

17. «Чәчәкләр җыры» шигырендә бакча тасвиры нинди сәнгати алым ярдәмендә тудырылган?

а) кабатлау　　　　　в) санау
б) детальләштерү　　　　　г) чамадан тыш арттыру

18. Туган як лирикасына караган «Илем» шигырендә авторның авылына мәхәббәте нинди уйланулар белән үрелеп китә?

а) милләтнең тарихы хакында
б) күк тормышы турында
в) халыкчылык идеяләре
г) кеше, аның асылы хакында

19. «Рәхәт кайда?» шигырендә кулланылган каршы кую композицион алымының эчтәлеген билгеләгез:

а) җир тормышы – бакый дөнья
б) җир – су
в) төш - өн
г) тән – җан
д) ямьсезлек – матурлык

20. «Галиябану»да Исмәгыйль образын тудырганда автор кайсы алымга өстенлек биргән?

а) тышкы кыяфәт　　　　　в) табигать, пейзаж тасвирлау
б) персонаж характерын ачу　　　　　г) психологик анализ

21. «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясендә Гали хәзрәт холкының кайсы сыйфаты аның җиңелүенә сәбәп була?

а) комсызлык　　　　　г) азгынлык
б) кирелек　　　　　д) дуамаллык
в) наданлык　　　　　е) тупаслык

22. «Галиябану» музыкаль драмасының үзәк каршылыгын аерып чыгарыгыз:

а) Галиябану – Исмәгыйль
б) Исмәгыйль – Бәдри

в) Исмәгыйль – тирәлек
г) Исмәгыйль – Хәлил
д) Галиябану – Бәдри

23. «Галиябану» әсәрендә автор нинди алымны отышлы файдаланган?
а) чамадан тыш арттыру
б) аңлашылмаучылык
в) читкә карап сөйләү
г) сүз уйнату

24. «Кызганыч» мелодрамасында Гәүһәрнең эчке каршылыгы ничек туа?
а) шәхси теләк белән милләт мәнфәгате
б) хыял белән чынбарлык
в) хакыйкать белән күзаллау
г) намус белән хис

25. «Авыл бәйрәме» музыкаль комедиясендә конфликт төрен билгеләгез:
а) локаль (чишелә торган)
б) субстанциаль (чишелми торган)

26. «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасында сюжет вакытын билгеләгез:
а) ярты гасыр
б) бер дистә ел
в) биш ел

*II вариант*

1. М.Фәйзи кайчан туган?
а) 1891    в) 1886
б) 1880    г) 1887

2. Аның беренче иҗат тәҗрибәсен атагыз:
а) «Яшьләр алдатмыйлар»
б) «Татар туе»
в) «Ике Хәсән»
г) «Кызганыч»

3. М.Фәйзи нинди мәдрәсәдә белем алу омтылышы ясап карый?
а) «Галия»    в) «Хөсәения»
б) «Госмания»    г) «Мотыйгыя»

4. Әдипнең «Яшь күңел» шигырьләр җыентыгы кайчан дөнья күрә?
а) 1912    в) 1913
б) 1905    г) 1910

5. Аның лирикасындагы үзәк мотивны күрсәтегез:

а) социаль
б) дини
в) каләм
г) шагыйрь
д) мәхбүс
е) халык
ж) авыл

6. М.Фәйзинең «Габдулла әфәнде Тукаев наменә» шигыренең үзәгендә торган хисне аерып күрсәтегез:

а) кайгыру
б) хәсрәтләнү
в) сагыш
г) горурлану, шатлану
д) үкенеч
е) сызлану

7. Авторның «Үз иркемә куй» шигырендә файдаланылган рифма төрен билгеләгез:

Ихтыяр юк үз теләгем берлә эш күрмәк өчен,
Иркемә каршы төшәсең, сарыф итеп син бар көчең
Ул синең золмың чиген чыкмак санап мөмкин түгел,
Кыска халкың берлә тар рамкаң өчен рәнҗи күңел

а) аралаш
б) әйләнмә
в) янәшә рифма
г) төгәл рифма

8. «Хәйран булам» шигырендә кабатлау алымының кайсы төре файдаланылган?

Ике якта матур гөлләр,
Арада комлы тар юллар,
Агачта сайрый былбыллар...
**Бу күренешкә булам хәйран**.
Исә йомшак саба җилләр
Агач яфраклар җилләр
Килә кошлар үтеп илләр
**Бу күренешкә булам хәйран.**

а) эпифора
б) рәдиф
в) анафора
г) ялгау
д) рефрен

9. «Кызганыч» мелодрамасының иҗат ысулы кайсы агым билгеләре белән баетылган?

а) экзистенциализм
б) натурализм

в) импрессионизм

10. «Авыл бәйрәме» пьесасы нинди жанрда язылган?

а) сатирик комедия
б) моңсу комедия
в) музыкаль комедия
г) музыкаль драма
д) сатирик драма
е) тарихи драма

11. «Беттеңмени» шигырендә лирик геройның сызлану сәбәбен аңлатыгыз:

а) тәкъдир
б) гомернең чикләнгәнлеге
в) үткән мәхәббәт
г) тормышка ашмаган хыял
д) вакыт рәхимсезлеге, хәрабә хәленә килгән морза утары

12. «Үткән вакыт» шигырендә нинди алымга мөрәҗәгать ителгән?

а) кабатлау
б) каршы кую
в) көчәйтү
г) монтаж

13. «Кызганыч» мелодрамасында нинди пафос өстенлек итә?

а) героик
б) романтик
в) трагик
г) сентименталь
д) сатирик

14. «Фәрештә» шигырендә нинди стилистик фигура файдаланылган?

Сәбәп нидер, белмим һич, рухым төшкән, күңел сүнгән
Тагын куйган кебек бер чир, авырланган башым түнгән.
Күзем тонган, үзем аңсыз, тәнем **каткан кебек җансыз**,
**Арыкланган, зәгыйфләнгән, тәмам хәлсез, кебек кансыз**.

а) градация
б) янәшәлек
в) инверсия
г) риторик эндәш

15. «Зарлану» шигырендәге лирик геройның сызлану сәбәбен күрсәтегез:

а) дөньяның ялганга корылуы
б) гомернең чикләнгәнлеге
в) тормыштагы гаделсезлек
г) җирдә кан коелу

16. «Рәхәт кайда?» шигыренең жанрын билгеләгез:

а) пейзаж лирикасы
б) гражданлык лирикасы
в) фәлсәфи лирика
г) күңел лирикасы

17. «Галиябану» драмасында нинди пафос өстенлек итә?

а) сатирик в) трагик

б) драматик г) героик

18. «Галиябану» драмасында Галиябану образын тудырганда нинди алымга өстенлек бирелгән?

а) портрет

б) табигатьне тасвирлау

в) психологик анализ

г) герой яшәгән иҗтимагый тирәлеккә, җәмгыятькә бәя бирү

19. «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясендә төп конфликтны аерып чыгарыгыз:

а) Мәгърүфә - Гали хәзрәт

б) Мәгърүфә - Сәлимә

в) Шакир белән Гали хәзрәт каршылыгы рәвешендә гәүдәләнгән яңалык һәм искелек тартышы

20. «Галиябану» музыкаль драмасының иҗат ысулын билгеләгез:

а) тәнкыйди реализм

б) романтизм

в) романтизм һәм реализм синтезы

г) сентиментализм

д) импрессионизм

21. «Галиябану» әсәренең милли әдәбиятка алып килгән яңалыгы:

а) композиция

б) жанр

в) тема

г) образлар системасы

22. «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасының каһарманнары Гыйсмәт белән Хәмитнең нинди мәсьәләгә бәя-карашлары аерыла?

а) никах иреге

б) хатын-кызның гаиләдәге урыны

в) мәхәббәт

г) милләт яшәешен үзгәртү

д) искелеккә каршы көрәш

23. «Галиябану» драмасында образ төрләрен билгеләгез:

а) Галиябану а) җыелма

б) Бәдри
в) егетләр
г) Сибгать
д) кулъяулык
е) Садри

б) ясалма
в) эпизодик
г) аталучы
д) ярдәмче
е) төп

24. «Кызганыч» һәм «Тәкъдирнең шаяруы» песаларында нинди фәлсәфи катлам дәвам иттерелә?

а) тәкъдир, язмыш фәлсәфәсе
б) тормыш фәлсәфәсе
в) кеше фәлсәфәсе
г) яшәеш фәлсәфәсе

25. «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасында нинди деталь отышлы файдаланылган?

а) портрет
б) психологизм
в) пейзаж
г) әйберләр дөньясы

26. «Тәкъдирнең шаяруы» әсәрендә нинди тема гәүдәләнгән?

а) персональ
б) милли
в) мәңгелек
г) тарихи

## М.Фәйзинең 1920 еллар тормыш юлы һәм иҗаты

*I вариант*

1. Мирхәйдәр Фәйзи 1919-1921 еллар аралыгында кайда яши?

а) Җүнәй
б) Темәс
в) Юлык
г) Орск шәһәрендә

2. Г.Ибраһимовның «Галиябану» хакында бер-ике сүз» тәнкыйди язмасының жанры:

а) рецензия
б) мәкалә
в) аннотация
г) әдәби портрет

3. М.Фәйзинең шәхси архивы тасвирламасын төзүче:

а) Б.Камалов
б) М.Хәмидуллин
в) Н.Ханзафаров
г) Д.Абдуллина

4. М.Фәйзи тарафыннан иҗат ителгән нинди драманың тәүге исеме «Фәрештә» була?

а) «Ак калфак»
в) «Урал буенда»

б) «Асылъяр» г) «Адашкан күңел»

5. «Урал суы буенда» драмасының сюжеты нигезендә яткан үзәк конфликтның төрен билгеләгез:

а) локаль

б) субстанциаль

6. «Асылъяр» драмасында гәүдәләнгән үзәк тема:

а) тарихи в) мәңгелек

б) милли г) персональ

7. «Ак калфак» драмасында образ төрләрен билгеләгез:

| | |
|---|---|
| а) «Хәмдия» җыры | а) төп |
| б) Бакый | б) аталучы |
| в) хезмәтчеләр | в) җыелма |
| г) Сәлим мирза | г) ясалма |
| д) Хантимер мирза | д) эпизодик |
| е) Хөсәй | е) ярдәмче |

8. «Кызыл йолдыз» пьесасында образ төрләрен билгеләгез:

| | |
|---|---|
| а) Хәй | в) ярдәмче |
| б) Сөнгать | г) аталучы |
| в) авыл кызлары | в) ясалма |
| г) кызыл йолдыз | г) җыелма |
| а) Хөснекәй әби | в) төп |
| б) мулла | г) эпизодик |

9. «Кызыл йолдыз» драмасының үзәк конфликты:

а) Әпрәү белән Сөнгать каршылыгы;

б) Сөнгать белән Маһруй каршылыгы;

в) «Аталар» һәм «балалар» каршылыгы;

г) коммун яшьләре белән совет власте дошманнары арасындагы каршылык.

10. «Кызыл йолдыз» пьесасында Хәй образын тудыруда М.Фәйзи нинди алымга өстенлек биргән?

а) прототипның булуы яки булмавы;

б) герой яшәгән иҗтимагый тирәлеккә, җәмгыятькә бәя бирү;

в) табигатьне тасвирлау;

г) психологик анализ.

11. «Адашкан күңел» драмасының исеме кайсы герой язмышына ишарә ясый?

а) Самат
б) Мавия
в) Бибкәй
г) Бәкер
д) Вафа

12. «Кызыл йолдыз» драмасында өстенлек иткән пафосны билгеләгез:

а) романтик
б) сентименталь
в) драматик
г) сатирик
д) героик
е) трагик
ж) комик

13. Драматург әсәрләрендә максатчан һәм отышлы файдаланылган деталь:

а) пейзаж
б) портрет
в) җыр

14. «Адашкан күңел» драмасында Мавия образын тудыруда автор өстенлек биргән алым:

а) прототипның булу яки булмавы;
б) табигатьне тасвирлау;
в) яшәү шартларын, тирәлекне тасвирлау;
г) автор бәяләмәсе.

15. Драматургның әүвәл «Хәмдия» дип исемләнгән драмасы:

а) «Ак калфак»
б) «Асылъяр»
в) «Урал суы буенда»
г) «Адашкан күңел»

16. М.Фәйзинең икенче тематикага караган әсәрләрендә нинди проблематика калкуланып китә?

а) милли
б) фәлсәфи
в) иҗтимагый-социаль
г) тарихи

17. Драматургның автобиографик җирлекле әсәре:

а) «Урал суы буенда»
б) «Асылъяр»
в) «Адашкан күңел»
г) «Кызыл йолдыз»

18. «Урал суы буенда» драмасы кайсы хасияте белән башкалардан аерылып тора?

а) хатын-кыз культы
б) мәхәббәт культы
в) авылның табигыйлегенә дан җырлау
г) музыка, сәнгать культы

19. «Ак калфак» пьесасы, конфликты белдерелү рәвешенә карап, драманың кайсы төренә якын тора?

а) хәрәкәт пьесасы

б) халәт-кичереш пьесасы

в) пьеса-бәхәс

20. М.Фәйзинең 1920 еллар рухи мирасында нинди иҗат юнәлешенең принциплары һәм алымнары өстенлек итә?

а) реализм

б) романтизм

*II вариант*

1. М.Фәйзи 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Казанда ничәнче елларда яши?

а) 1923-1924 в) 1927

б) 1920 г) 1925

2. Язучы вафат булган төбәк:

а) Баймак в) Оренбург

б) Орск шәһәре г) Юлык

3. Язучының тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә багышланган «Мирхәйдәр Фәйзи» (1920) дигән монографик хезмәтнең авторы:

а) А.Әхмәдуллин в) Б.Камалов

б) Н.Ханзафаров г) И.Фәйзуллин

4. Язучының 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң иҗат ителгән тәүге әсәре:

а) «Ак калфак» в) «Адашкан күңел»

б) «Асылъяр» г) «Урал суы буенда»

д) «Кызыл йолдыз»

5. «Урал суы буенда» драмасында өстенлек иткән пафос:

а) драматик д) комик

б) героик е) сатирик

в) романтик ж) трагик

г) сентименталь

6. «Асылъяр» драмасында образ төрләрен билгеләгез:

а) Шәрәф а) ясалма

б) Искәндәр бай б) төп

в) «Асылъяр» җыры в) эпизодик

г) хатын-кызлар	г) аталучы
д) Таҗи	д) җыелма
е) Шәмси әби	е) ярдәмче

7. Драматургның авылдагы сыйнфый каршылыкларны, гражданнар сугышы вакыйгаларын сурәтләгән әсәре:

а) «Урал суы буенда»
б) «Адашкан күңел»
в) «Кызыл йолдыз»
г) «Асылъяр»
д) «Ак калфак»

8. М.Фәйзи иҗатына хас стиль үзенчәлеге:

а) кеше тормышын реаль детальләрдә, үз формасында сурәтләү;
б) иҗтимагый-социаль мәсьәләләрне калкытып кую;
в) милли проблематика кызыл җеп булып сузылу;
г) фольклор эстетикасы белән тыгыз бәйләнеш.

9. «Ак калфак» драмасында өстенлек иткән пафос:

а) романтик
б) трагик
в) драматик
г) сатирик
д) комик
е) героик
ж) сентименталь

10. Драматургның кайсы әсәре авылда коммун яшьләре оешмасы төзелү вакыйгасыннан алынып язылган?

а) «Кызыл йолдыз»
б) «Урал буенда»
в) «Адашкан күңел»
г) «Ак калфак»

12. «Кызыл йолдыз» пьесасының конфликт төрен билгеләгез:

а) локаль
б) субстанциаль

13. «Адашкан күңел» пьесасының үзәк конфликтын билгеләгез:

а) Мавия – Самат каршылыгы
б) шәһәр мәдәнияте белән авыл шартлары каршылыгы
в) Мавия белән Бибкәй каршылыгы
г) Мавия белән Бәкер каршылыгы
д) Мавиянең күңелендәге акыл һәм хис каршылыгы
е) «Аталар» һәм «балалар» каршылыгы

14. «Кызыл йолдыз» драмасының темасын билгеләгез:

а) иҗтимагый-тарихи
б) мәңгелек
г) мәхәббәт
д) персональ

15. «Кызыл йолдыз» пьесасында автор нинди проблематиканы калкуландырырга омтыла?

а) мифологик в) фәлсәфи

б) милли д) иҗтимагый-социаль, сыйнфый көрәш

16. «Ак калфак» драмасында кайсы социаль катлау тормышын сурәтләү чор идеологиясенә буйсындырылган?

а) зыялылыр в) морзалар

б) гади халык г) руханилар

17. «Адашкан күңел» драмасында постоялый двор һәм номер тормышы кайсы рус әдибе йогынтысында сурәтләнгән?

а) А.Куприн

б) А.М.Горький

в) А.П.Чехов

18. «Асылъяр» драмасында өстенлек иткән пафосны билгеләгез:

а) трагик д) сатирик

б) сентименталь е) героик

в) комик ж) драматик

19. М.Фәйзи иҗатында өстенлек иткән деталь:

а) этнографик

б) пейзаж

в) портрет

20. «Адашкан күңел» пьесасындагы үзәк конфликтның төре:

а) эчке (психологик)

б) тышкы (иҗтимагый)

## Фәнни-тикшеренү темалары

1. М.Фәйзинең «Галиябану» музыкаль драмасында образлар системасы.
2. Язучының «Галиябану» пьесасында хронотоп.
3. М.Фәйзинең «Галиябану» драмасында сюжет.
4. Драматургның «Галиябану» әсәрендә конфликт һәм характерлар.
5. «Галиябану» музыкаль драмасында фольклор эстетикасы.
6. М.Фәйзинең «Галиябану» пьесасында психологизм.
7. Язучының «Галиябану» драмасында идея-проблематика.
8. Классик «Галиябану» драмасында стиль һәм тел-сурәтләү чаралары.
9. «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясенең идея-эстетик үзенчәлекләре.
10. М.Фәйзинең «Кызганыч» мелодрамасының иҗат ысулы мәсьәләсе.
11. «Кызганыч» пьесасында конфликт һәм жанр үзенчәлеге.
12. «Кызганыч» мелодрамасында конфликт һәм характерлар.
13. Драматургның «Кызганыч» пьесасында сентиментализм билгеләре.
14. «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасында экзистенциаль мотивлар.
15. Язучының «Тәкъдирнең шаяруы» пьесасында конфликт.
16. М.Фәйзинең «Тәкъдирнең шаяруы» мелодрамасында сюжет, тема һәм идеяләр дөньясы.
17. «Авыл бәйрәме» пьесасында конфликт һәм жанр үзенчәлеге.
18. «Авыл бәйрәме» музыкаль комедиясендә этнографик детальләр һәм фольклор традицияләре.
19. М.Фәйзи шигъриятендә авыл мотивы.
20. Шагыйрь поэзиясендә әдәби бәйләнешләр.
21. М.Фәйзи шигъриятендә интертекстуальлек.
22. М.Фәйзи лирикасында фәлсәфи мотивлар.
23. Язучының «Асылъяр» драмасында традицияләр һәм яңачалык.
24. Драматургның «Асылъяр» пьесасында образлар системасы.
25. «Асылъяр» пьесасында конфликт һәм характерлар.
26. М.Фәйзинең «Асылъяр» пьесасында сюжет, тема һәм идеяләр дөньясы.
27. «Ак калфак» драмасында морзалар тормышының гәүдәләнеше.
28. М.Фәйзинең «Ак калфак» драмасында гуманизм.

29. Әдипнең «Ак калфак» драмасында сюжет һәм композиция үзенчәлекләре.
30. Язучының «Ак калфак» драмасында психологизм.
31. «Ак калфак» драмасында М.Фәйзи файдаланган әдәби детальләр.
32. М.Фәйзинең «Ак калфак» драмасында образлар системасы.
33. «Кызыл йолдыз» пьесасында М.Фәйзи сурәтләгән сюжет сызыклары.
34. «Кызыл йолдыз» пьесасында образлар системасы.
35. М.Фәйзинең көндәлек дәфтәрләрендә чор үзгәрешләренә мөнәсәбәтнең чагылышы.
36. Драматургның «Адашкан күңел» пьесасында әдәби бәйләнешләр.
37. Язучының «Адашкан күңел» пьесасында психологизм.
38. М.Фәйзинең «Адашкан күңел» пьесасында идея-проблематика.
39. Классик «Галиябану» музыкаль драмасы татар сәхнәсендә.
40. М.Фәйзинең «Асылъяр» драмасының сәхнә тарихы.
41. Әдипнең «Урал суы буенда» драмасында авыл һәм шәһәр мөнәсәбәтләре.
42. М.Фәйзинең «Урал суы буенда» пьесасында хезмәт романтикасы.
43. Драматургның «Урал суы буенда» пьесасында образлар системасы.

II

1. М.Фәйзинең шигъри дөньясы.
2. Милли драматургиядә һәм татар сәхнәсендә М.Фәйзинең «Галиябану» музыкаль пьесасы.
3. Язучының 1910 еллар драматургиясендә жанр төрлелеге.
4. М.Фәйзинең 1910 еллар драматургиясендә фольклор традицияләре.
5. Драматургның 1910 еллар пьесаларында мәхәббәт һәм хис культы («Кызганыч», «Тәкъдирнең шаяруы» мисалында).
6. Әдипнең 1920 еллар драматургиясендә традицияләр һәм яңачалык («Кызыл йолдыз», «Адашкан күңел» мисалында).
7. Драматургның 1920 еллар пьесаларында автор һәм чор идеологиясенең чагылышы.
8. М.Фәйзинең «Асылъяр» һәм «Ак калфак» драмаларында конфликт һәм характерлар.
9. Әдип драматургиясендә авыл темасы: «Авыл бәйрәме», «Урал суы буенда» пьесалары мисалында.
10. М.Фәйзи – гуманист драматург.

11. М.Фәйзинең көндәлек дәфтәрләрендә автор һәм чор.
12. Драматургның «Кызыл йолдыз» пьесасына хас идея-эстетик үзенчәлекләр.
13. Гыйльми-тәнкыйди фикердә М.Фәйзи иҗаты.
14. Татар сәхнәсендә М.Фәйзинең драмалары.

## Тестларга ачкычлар

### М.Фәйзинең 1917 елгы Октябрь борылышына кадәрге тормыш юлы һәм иҗаты

*I вариант*

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. б | 8. в | 15. в | 22. г |
| 2. г | 9. г | 16. а | 23. б |
| 3. б | 10. а | 17. б | 24. а |
| 4. б | 11. в | 18. в | 25. а |
| 5. б | 12. д | 19. а | 26. в |
| 6. б | 13. б | 20. б | |
| 7. а | 14. б | 21. г | |

*II вариант*

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. а | 8. д | 15. а | 22. в |
| 2. б | 9. в | 16. в | 23. а – е; б – д; |
| 3. в | 10. в | 17. б | в – а; г – в; д – б; |
| 4. в | 11. д | 18. а | е – г |
| 5. ж | 12. б | 19. в | 24. а |
| 6. г | 13. г | 20. в | 25. б |
| 7. в | 14. а | 21. б | 26. в |

### М.Фәйзинең 1920 еллар тормыш юлы һәм иҗаты

*I вариант*

| | |
|---|---|
| 1. в | 11. а |
| 2. а | 12. а |
| 3. г | 13. в |
| 4. б | 14. а |
| 5. а | 15. в |
| 6. а-г; б-а; в-в; г-е; д-б; е-д. | 16. г |
| 7. а-д; б-а; в-г; г-в; д-б; е-е. | 17. в |
| 8. г | 18. б |
| 9. а | 19. б |
| 10. б | 20. г |

*II вариант*

| | |
|---|---|
| 1. а | 11. а |
| 2. а | 12. а |

3. в
4. г
5. в
6. а-б;б-е; в-а; г-д; д-г; е-в.
7. в
8. г
9. в
10. в
13. д
14. а
15. д
16. в
17. б
18. г
19. а
20. а

## Резюме

В данном учебном пособии, посвященном монографическому исследованию духовного наследия одного из классиков татарской литературы Мирхайдара Файзи (1851-1928), рассмотрены жизненная и творческая биография писателя, эволюция его идейно-эстетических взглядов и вклад, который он внес в развитие татарской драматургии. Творчество М.Файзи многогранно: он поэт, прозаик, переводчик, публицист, фольклорист, общественный деятель.

В формировании М.Файзи как личности и как писателя решающую роль сыграли такие факторы, как традиционное семейное воспитание, географическо-природные условия родного края, его литературная и историко-культурная среда и постоянно меняющаяся общественно-политическая обстановка. Литературно-эстетические взгляды М.Файзи развивались под влиянием традиций национальной литературы дотукаевского периода, эстетики фольклора, идейно-эстетических достижений восточной, особенно турецкой, и русско-европейской литератур.

Первые пробы пера М.Файзи испытал в лирике. Литературная деятельность М.Файзи с самого начала развивалась под влиянием традиций таких выдающихся поэтов, как Г.Тукай, Ш.Бабич, Дардменд и других. Будучи поэтом-романтиком, он описывал тонкие душевные переживания лирического героя, вдохновленного крастотой родной природы, красотой женщины и наделенного неугасимой любовью к жизни. Для поэзии М.Файзи характерны разнообразие тем, мотивов, жанров и богатство поэтических средств, из которых складывается его художественный мир.

Особенно результативным было его творчество в области драматургии, которое сопровождалось научно-теоретическими исканиями в татарской литературе 1910-ых годов. Писатель в своих пьесах, активно и по-новаторски используя традиции фольклора, народные песни и музыку, воспевает любовь и духовное величие человека. А его музыкальная драма “Галиябану” (1916)

является одним из лучших произведений татарской классической литературы, которая представляет собой новое направление в истории национальной драматургии.

В пособии приведен перечень тем практических занятий, различные творческие задания, а также вопросы для контрольных работ. Кроме того, дается список рекомендуемой литературы, представлены тесты по творчеству М.Файзи в нескольких вариантах и темы для исследовательских работ студентов.

**Summary**

The presented textbook is a monograph study of Mirhaidar Faizi's spiritual heritage, who is one of the Tatar literature classics (1851-1928). The story of his personal and creative life, the evolution of his moral aesthetic views and the contribution made by him to the development of Tatar dramaturgy are also considered. M.Faizi's creative work is many-sided: he is a poet, a prose-writer, a translator, a publicist, a folklore researcher and a public figure.

Such factors as a traditional family upbringing, his literary, historical and cultural environment, a constantly changing public and political situation played a great part in M.Faizi' s formation as a personality and a writer. His literary and aesthetic views developed under the influence of the national literature traditions of pre-Tukai period, folklore aesthetics, moral and aesthetic achievements of Eastern, especially Turkish, Russian and European literature.

For the first time M.Faizi put his pen to paper in lyric poems. From the very beginning his literary activity developed under the influence of outstanding poets as G.Tukai, Sh.Babich, Dardmend and others. Being a Romantic poet M. Faizi described the emotional experience of a lyrical character, inspired by the beauty of a native nature and the beauty of a woman, the character endowed with an unquenchable love for life. His poetry is characterized by the variety of subjects, motives, genres and the wealth of poetic means, which create his artistic world.

His creative work in the field of dramaturgy was especially effective and it was accompanied by the scientific research of Tatar literature of 1910s. The writer praises love and greatness of man's soul, actively and in a new way using forklore traditions, folk songs and music. And his music drama "Galiyabanu" (1916) is one of the best works of Tatar classical literature and represents a new trend in the history of national dramaturgy.

In this textbook there is the list of themes for practical classes, different creative activities, questions for testing, the list of books recommended for reading,

several variants of tests on M. Faizi’ s creative work and also subjects for the research work of students.

**Эчтәлек**

Кереш сүз.........................................................................................................3
Әдипнең тормыш юлы һәм иҗатының өйрәнелү тарихы..........................................................................................................5
М.Фәйзи шигърияте.........................................................................................26
М.Фәйзинең 1910 еллар драматургиясендә конфликт һәм характерлар......................................................................................................43
М.Фәйзинең 1920 еллар драматургиясе: традицияләр һәм яңачалык.........................................................................................................60
Тестлар.............................................................................................................70
Фәнни-тикшеренү темалары...........................................................................83
Тестларга ачкычлар..........................................................................................86
Резюме (рус һәм инглиз телләрендә)..............................................................88